PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2019 ИЮНЬ № 6

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ҮСКӘЧ БЛОГЕР БУЛАМ

яңа мөмкинлекләр заманы

МӘХӘББӘТ БИР, РАББЫМ

ачыктан-ачык сөйләшәбез

КАМБОДЖА

әбиләр идарә иткән ил

Гөлсинә ГАЛИУЛЛИНА:

ИҢ ЯХШЫ ТӘРБИЯ ЧАРАСЫ – ЭШ...

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Фаил ШӘФИГУЛЛИН

* * *

Мин саргаям, имеш, синең өчен –
Елыйм, имеш, көн-төн, беткән көчем,
Коңгырт күзле кызый.
Гайбәтләргә берүк ышана күрмә,
Минем юлым илтә һаман үргә,
Коңгырт күзле кызый.

Һаман бунтарь әле минем йөрәк,
Аңа һаман биеклекләр кирәк,
Коңгырт күзле кызый.
Сөю көтми, сине көтми күңел,
Тик син булгач, үргә менү җиңел,
Коңгырт күзле кызый.

Син яшәгәч җирдә, тау күтәрәм,
Йолдыз ясыйм төнге яшеннәрдән,
Коңгырт күзле кызый.
Сөюем өчен сине өзелеп-өзелеп,
Бирдең, ахры, миңа үлемсезлек,
Коңгырт күзле кызый...

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны – шагыйрә Эльмира Шәрифуллина. 1970 нче еллар.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: КАнна Арахамия

Баш мөхәррир вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Гөлсинә Галиуллина
Фото: Анна Арахамия

Верстка:
Лариса Маликова

Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды:
03.06.2019 ел
Заказ О-1421
Тираж 5400

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002




ООО
НИВА


Фото: Илдар Закиров

Асия ЮНЫСОВА

Сабантуйга кайттым

Бик сагындым сезне, туганнарым,
Бик сагындым сезне, тауларым,
Бик сагындым сине, зәңгәр Ыгым –
Барыгызны өзелеп са-гын-дым!

Йөгерепләр генә кайтырмын күк,
Чыгармын күк яшел болынга.
Күлмәгемне зифа талга элеп,
Чумармын күк Ыгым суына.

Бөтен кеше миңа якын монда,
Танымаган – хәлем сораша...
Сабантуйда паспорт сорамыйлар –
Яшьлек белән картлык очраша.

Сагынуларны басар өчен генә
Узадыр ул Сабан туйлары.
Кайттым әле менә яныгызга –
Чынга ашты быел хыялым.

Яшьлегемне эзләп табар өчен
Мәйданнарны кат-кат урадым.
«Ул монда!» – дип, миңа ак шомыртлар
Әрәмәдән кулын болгады.

Сабан туйда гомер кабатлана,
Кабатланмый яшьлек, бер узгач...
Ә мин менә гел кайтырмын кебек...
Бер кайтырмын, өзелеп сагынгач...

Безнең тышлыкта



«Барысын да үзем булдырам, акча табам, миңа ир нигә дип яшәүчеләрне, гомумән, аңламыйм. Һәр хатын-кыз янында ир-ат булырга тиеш.»

26
Юллар кая илтә?
Чулпан Галиәхмәтова

Заман һәм без

6 Балаларны ничек якларга?
Чулпан Галиәхмәтова

Яңа кеше туа... 10
Рамилә Нотфуллина

14 Гомер озынлыгы дүрт ел
Гөлнур Сафиуллина

18 «Үскәч блогер булам...»
Альбина Гыйльметдинова

22 Шахтер Нурания
Лилия Гәрәева





Эчтәлек

Татар дөньясы



32
Дога
Гөлнур Хәсәншина

Мәдәни тормыш



38
Кире кайта торган юл булса...
Ләлә Сабирова

Яшәеш



44
Мәхәббәт күкләрдән генә иңми
Гөлнур Сафиуллина



52
Камбоджа
Рәмзия Кашапова


Хатын-кыз галәме



60
Мцвади – грузин шашлыгы



62
Файдалы десерт



«Безнең бурычыбыз – баланы гаиләдә калдыру.»

Фото: Анна Арахамия

БАЛАЛАРНЫ НИЧЕК ЯКЛАРГА?



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

1 июнь – Халыкара балаларны яклау көне. Тик нигә бер генә көн соң ул? Ел дәвамында бит 365 көн! Нәкъ 365 көн буе алар яклауга мохтаҗ.

Дөньяга ихластан елмайган, күңеле ап-ак кәгазьдәй чиста булган, бар нәрсәдән матурлык күреп, шатланып, чырык-чырык көләргә генә торган сабыйлар, үзләренә карата усаллык, рәхимсезлек, битарафлык тойса, күңелләре ташка әйләнә башлый. Үрнәк әти-әниле булып, алар дөрес тәрбия бирә алса, бала бу дөньяга ныклы адымнар белән басачак, үзенә ышанычы артачак. (Ә бу тормыш алып барыр өчен иң кирәкле сыйфатларның берсе!) Тик әти-әниләрне сайлап алып булмый. Бу дөньяга килгәндә кайсы гаиләгә эләгүеңне бары тик бер Ходай гына хәл итә. Ләкин ата-ана нинди генә булса да, бала өчен алар иң якыны, иң кадерлесе. Ул алардан яклау эзли!

Тик, кызганыч, балаларны читләрдән генә түгел, кайчак үзебездән – әниләрдән дә яклар чаклар бар. Анасы кулыннан җан биргән, җәбер-золым күргән, салкын хастаханә караватында ташлап калдырылган балалар азмыни? Матбугат андый җан өшеткеч хәлләр хакында сөйләп кенә тора. Әйтелми калганнары күпмедер тагын?! Тормыш авырлыгына чыдый алмас чиккә җиткәндә, ана кеше, мин бит ялгыз түгел, җәмгыятьтә яшим, дип ник уйламый икән? Тирә-якта аларга ярдәм кулы сузарга әзер шәфкатьле җаннар без уйлаганнан күбрәк югыйсә. Тавышыңны гына ишеттер. Дәүләт тә ярдәменнән ташламый. 2013 елда Россиядә авыр тормышта яки социаль куркыныч хәлдә калган балаларга, аларның гаиләләренә булышу максатыннан медицина-социаль ярдәмнең төбәк моделе булдырыла. «Азино» балалар сырхауханәсе базасында «Ышаныч» медицина-социаль ярдәм күрсәтү республика үзәге аның нигезендә ачыла. Анда эшләүче табиблар, психологлар, социаль хезмәткәрләр, юристлар балаларны ана карынында чакта ук яклый башлый. Әлеге үзәкнең җитәкчесе Динара ГОБӘЙДУЛЛИНА белән шулар хакында сөйләшәбез.

Динара Габделхаковна, бүгенге көндә республикада авыр тормыш хәлендә калган, ярдәмгә мохтаҗ балалар күпме?

– Узган ел мәгълүматлары буенча, Татарстанда 40 мең бала медицина-социаль исәптә тора. Бу – республикадагы барлык балаларның 5 проценты дигән сүз. Аларның 3 меңгә якыны – социаль куркыныч хәлдә калучылар.

Социаль куркыныч хәл белән авыр тормыш хәленең аермасы нәрсәдә?

– Ул категорияләр федераль канун белән билгеләнә. Авыр тормыш хәлендә калучылар: мөмкинлекләре чикләнгән, психик авырулы, опекада булган яки дәүләт учреждениеләрендә тәрбияләнгән балалар, ә 120 нче федераль канун нигезендә, әти-әнисе наркоман, эчкече булган, үз вазыйфаларын үтәмәгән, бала хокуклары бозылып, җәберләнеп көн итүчеләр социаль куркыныч хәлдә яши дип бәяләнә. Болар арасында эчкечеләр гаиләсендә яшәгән балалар күбрәк. Сукбайлыкта йөргәннәр дә әлеге категориягә керә.

Нигә балага ярдәм итә торган тиешле оешмалар бу хакта белеп тә, алар гаиләдә куркыныч хәлдә яшәргә мәҗбүр соң?

– Бала гаиләдә үсәргә тиеш. Ул аның өчен җир йөзендәге иң рәхәт урын. Шуңа күрә бөтен эш профилактикага юнәлтелгән. Әнисе – эчкече, әтисе аек икән, нигә баланы гаиләдән алырга? Ул ана белән бөтен хезмәтләр шөгыльләнә. Аны дәвалыйлар, эшкә урнаштыралар. Сәламәтләнүгә өмет бар, димәк. Һичьюгы балаларны вакытлыча әби-бабайга, туганнарына тәрбиягә бирәләр. Ата-анасы сәламәтләнү белән алар туган йортларына кайтарыла. Әлеге гаиләләр белән эшләүчеләрнең максаты балаларны дәүләт учреждениеләренә урнаштыру түгел: ничек кенә булса да, ата-ананы тәрбияләү юллары эзләү. Гадәттә, без мондый гаиләләрне бер ел буе контрольдә тотабыз. Алар, гадәттә, шул вакыт эчендә уңай якка үзгәрәләр. Өч ай саен, хәтта ай саен күзәтеп, чаралар күреп, ведомствоара җыелышлар үткәрелә. Кайбер очракларда икешәр ел да күзәтү астында тотабыз. Әгәр дә инде ата-ана өметсез икән, монда берни эшләп булмый: баланы алырга туры килә. Ләкин тагын бер кат кабатлыйм: хакимият баланы гаиләдә калдыру ягында. Моның өчен ата-ананың теләге булу гына кирәк.

Социаль куркыныч хәлдәге балалар саны динамикасы нindирәк? Ул кимүгә табамы, әллә артамы?

– Безнең үзәк күптән түгел – 2014 елдан бирле генә эшли. Шуңа күрә бу сан әлегә артып бара. Бөтен медицина хезмәткәрләре арасында аңлату эшләре алып барыла, авыр гаиләләр белән очрашкач, алар тиз арада безгә моны хәбәр итә. Димәк, ачыклау арта. Ә бу динамика үсешенә китерә. Социаль куркыныч хәл республика буенча чагыштырмача тотрыклы. Бу – ведомствоара хезмәттәшлек, профилактика нәтиҗәсе.

Нәтиҗәне төгәлрәк ясасак, ел буена исәптә торган ничә баланың тормышы җайлаша дип әйтә аласыз?

– Ел саен 500 дән 600 гә кадәр бала исәптән төшерелә. Димәк, аларның тормышына инде куркыныч янамый дигән сүз.

Динара Габделхаковна, сезнең үзәккә мөрәҗәгать итүче гаиләләр күпме?

– «Азино» балалар сырхауханәсен алсак, безнең микрорайонда 2 меңнән артык бала исәптә тора. Шуларның 38 е социаль куркыныч гаиләдә яши. Чагыштыру өчен: сырхауханәгә беркетелгән гаиләләр саны – 35 мең. Дөрес, 38 бала да аз түгел, аларга карата үтә игътибарлы булу таләп ителә. Кагыйдә буларак, безгә алар үзләре мөрәҗәгать итми. Табибка килгәч яки медицина хезмәткәрләре өйләренә баргач,



сабыйның социаль куркыныч хәлдә яшәве ачыклана. Балага мөнәсәбәт шундук күзгә ташлана. Ул яшәгән урынның билгеле бер кагыйдәләргә туры килмәвенә дә игътибар ителә: һәркайда җыйнаксызлык, пычрак... Андый гаиләне участок табибы күргәч, безгә хәбәр итә. Социаль хезмәткәрләр урынга барып, әлеге хәбәрнең дөреслеген раслый. Шуннан соң бу мәгълүматны карау өчен ведомствоара хезмәттәшлеккә тапшырабыз.

Авыр тормыш хәлендә калган ялгыз әниләр яки әтиләр дә бар бит әле. Алар сезнең үзәккә ярдәм сорап киләме?

– Әйе, андый берничә очрак булды. Бер хатын, мәсәлән, участок табибы аша безгә мөрәҗәгать итте. Ул башта сабыен бала табу йортында калдырып чыгарга теләгән. Аны бу уеннан кире кайтарганнар. Беренче патронаж вакытында яшь әни, табибка бала тәрбияләргә әзер түгеллеген әйтеп, аннан баш тарту мөмкинлеге хакында белешкән, гомумән, ярдәм сораган. Табиб тиз арада үзәк хезмәткәрләренә хәбәр итте. Без психологлар белән эшкә алындык, әлеге хатынга эшкә урнашырга ярдәм иттек. Түләүләрне рәсмиләштердек. Чынлап та, авыр хәлдә калган ананың шәһәрдә беркеме юк иде. Ярдәм вакытында күрсәтелгәч, бала гаиләдә калды. Тагын бер очрак. Ире юл фаҗигасенә очрап һәлак булгач, ялгыз калган булачак ана безгә авырлы хатын-кызлар белән профилактика курслары уздырганда мөрәҗәгать итте. Аңа да тиешле ярдәм күрсәтелде. Без – медицина ягыннан ярдәм итүчеләр. Башка ягын ведомствоара хезмәттәшлек кайгырта. Шуны ассызыклыйсым килә: республика хакимияте авыр тормыш хәленә тарыган булачак аналарны ялгыз калдырмый. Моның өчен төрле үзәкләр эшли. Йорт-җирсез калган хатыннарны (ире куып чыгарган, җәберләгән) сыендыра. Болар барысы да социаль ятимлекне булдырмау максатыннан эшләнә.

Әңгәмәләрнең берсендә сез, башка төбәкләргә караганда, Татарстанда балаларның социаль хәлен билгели торган критерийлар киңрәк, дип әйткән идегез. Белгәнебезчә, сезнең үзәк хезмәткәрләре аны тагын да киңәйтү инициативасы белән чыкты...

– Әйе, аны республика хакимияте кабул иткән очракта, йөзләрчә сабыйларны бәладән алып калырга мөмкин булачак. Мәсәлән, әни авыру баласын хастаханәгә салырга теләми. Дөрес, һәр ана федераль канун нигезендә баласын хастаханәгә салудан, прививкалардан да баш тарта ала. Тик өйдә калдырган очракта, табибка күренеп торалар, аның киңәше буенча дәвалананалар, дарулар алырга мөмкинлекләре бар. Әмма табибларны өйләренә кертмәүчеләр дә очрый. Ә бу – баланы социаль куркыныч хәлдә калдыру. Аның гомеренә куркыныч яный бит!

Безнең тәкъдимнәр арасында прививкаларны социаль әһәмиятле итү пункты да бар. Сүз бөтенесе турында түгел, социаль яктан куркыныч тудырган авыруларга каршы прививкалар хакында бара. Әйе, ата-аналар алардан баш тартырга мөмкин, ләкин, күрәсез, йогышлы авырулар килеп чыга башлады. Шул ук кызамыкны алыйк. Бу – йогышлы куркыныч авыру. Бала якты дөнья белән хушлашырга да мөмкин, ә әни прививкага каршы төшә. Туберкулез да шушы категориягә керә.

Кызым белән хастаханәдә ятканда шундый хәлнең шаһиты булдым: яңа туган авыру балага кан салырга кирәк иде. Ә әти-әнисе ниндидер сәбәпләр аркасында бу медицина ярдәменнән баш тартты. Табиблар ике ут арасында калды, хәтта әби-бабайларын да чакырып сөйләштеләр. Мондый очракларда табиблар нишләргә тиеш?

– Баланың социаль куркыныч хәлен билгеләгән яңа критерийлар кабул ителгән очракта бу хәлдән чыгу механизмы эшләнәчәк. Төгәлрәк әйтсәк, табиблар ялгыз булмаячак. Мондый очраклар ведомствоара хезмәттәшлек катнашы белән каралачак. Тиешле мәгълүмат туплангач, гаилә муниципалитет дәрәҗәсенә сөйләшүгә чакырылачак. Федераль канун нигезендә, ата-ана баласының сәламәтлеген сакларга бурычлы. Ә табиблар баланы беркайчан да ярдәмнәреннән ташламаячак. Монысына ышана аласыз!

Яхшы яшәгән гаиләләрдә дә балалар белән проблемалар, аңлашылмаучанлыклар килеп чыгып тора. Мондый гаиләләр сездән ярдәм сорыймы?

– Бездә бит гаиләдәге хәлне чыгарып селкергә яратмыйлар. Әмма, чынлап та, үз көчең белән чишә алмастай катлаулыклар да килеп туарга мөмкин. Махсус хезмәтләр бар – аларга мөрәҗәгать итүдән кыенсынмаска кирәк. Еламаган балага имезлек бирмиләр дигән кебек, алар сиңа ярдәм сорасаң гына булыша алалар. Гадәттә, андый гаиләләрдәге аналар, безгә ярдәм кирәкми, дип баралар. Безнең менталитет үз теләкләре белән медицина-психология буенча социаль хезмәтләргә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүнең актуальлеген аңлап бетерми әле.

Бала мәхәббәттә үссә генә бәхетле була, диләр...

– Минем уйлавымча, бала гаиләдә җылылык тапмаса да, яратудан барыбер мәхрүм булмаячак. Әби-бабайлар, туганнар бар бит әле. Бала дәүләт учреждениесендә тәрбияләнә икән, анда гаилә җылысы тудыра алган, ярата белгән хезмәткәрләр эшләргә тиеш. Яңа гаилә табу мөмкинлеге дә бар. Ятимсыз калган балалар булмасын иде. Безнең бурычыбыз да шул!

БАЛАЧАК – УЙНАР ЧАК...



Ихлас, эчкерсез, самими...

Балалар йөзендәге бу елмаюларны тасвирларга тагын нинди сүзләр табарга була икән? Җылы, ягымлы... Тагын – шаян, шук, хәйләкәр...

Алар шундай төрле! Фотосурәтләрдәге малай-кызларны әйтәм. Берәүләр – зуррак, икенчеләргә әле үсәсе дә үсәсе. Мавыгулар бер-берсенә охшамаган: кемдер пластилиннан ниндидер яңа уенчык әвәли, кемдер сәхнәгә тамашачы алдына чыгарга әзерләнә, ә кемдер туп тибеп арып, ял итәргә туктаган... Аларга карыйсың да, үзеңне күрәсең. Бер гамьсез, бер уйсыз бәхетле балачагыңны... Таганына кадәр канатлы булган балачагыңны... Күкләр биек һәм зәңгәр, кояш – якты, җилләр – җылы, дуслар – күп һәм тугры...

«Татмедиа» галереясында бу юлы «Салават күпере», «Ялкын» һәм «Сабантуй» журналларында иҗат итүче фоторәссамнар – Илназ Мөхәрләмов, Ринат Нәҗметдинов, Анна Арахамия һәм Владимир Васильев эшләре куелды. Якты, көләч фотосурәтләр! Фоторәссамнар тотып алган бу мизгелләрдә балаларның барысы да – бәхетле. Гел шулай булсын дип телисе килә: бала һәм бәхет сүзләре янәшә торсын!

Күргәзмә 31 майдан 10 июльгә кадәр эшләячәк.

Адресы: Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

PRESSA

ЯҢА КЕШЕ ТУА...



Фото: www.pixabay.com

Бала табучы хатын-кызның гомере кыл өстендә, диләр. Ходай шулай язган: тулгак ачыларына түзеп, үз аңында булып, бар кодрәтеңне бер учка туплап, баланы дөньяга китерергә кирәк. Баланың дөньяга килүе – үзе бер зур могҗиза. Һәм әлеге могҗиза табигать кушканча, табигый юл белән барса – хатын-кыз өчен тагын да зур куаныч.
Баланы аягүрә килеш табу да табигый юл дип санала. Аягүрә, ягъни вертикаль хәлдә бәбиләү, бу ысулның өстенлекләре хакында Казан шәһәренең 16 нчы хастаханәсенә караган бала табу йорты җитәкчесе Лилия ДӘҮЛӘТШИНА белән сөйләшәбез.



Рамилә НОТФУЛЛИНА

Баланы аягүрә килеш табуның үзенчәлеге нәрсәдә дип әйтә аласыз?

– Вертикаль килеш бала тапканда хатын-кыз актив хәлдә кала: үз-үзенә ярдәм итә ала. Тулгак аралары кыскара. Бала башы белән аналык җиңсәсенә басым ясау аркасында, аналык җиңсәсе җиңел һәм тиз ачыла. Нәтиҗәдә, бала табу процессының беренче өлеше, яткан көе тапканга караганда, ике-өч сәгатькә кыскара. Бу, үз чиратында, балага да, анага да уңай тәэсир итә. Чөнки гадәттә тулгак озакка сузыла, хатын-кызлар арый башлый, тулгак авыртуларын көтеп, куркуга бирелә. Тулгак вакытында балага да авыр – кислород килми тора. Вертикаль ысул белән бала тудыру махсус җиһазлар ярдәмендә дә, гадәти акушер караватында да башкарылырга мөмкин. Бездә моның өчен барлык шартлар да булдырылды.

Әлеге ысул бездә – Россиядә күптәннән кулланыламы?

– Гомер бакый бөтен дөньяда баланы шулай тапканнар. Кайбер илләрдә исә, аерым халык вәкилләре баланы чүгәләп тапкан, һәм әлеге ысул алар өчен традицион дип саналган. Россиядә, Европада, Латин Америкасы, Африка, Кытай илләрендә элек хатын-кызлар бәбиләгәндә аның иреген бүгенге кебек чикләмәгәннәр – аркада гына ятарга кушмаганнар. Киресенчә, алар хәрәкәттә булган. Кендек әбиләре аларга төрле физик күнегүләр ясаткан... Россиядә, гадәттә, баланы мунчада тапканнар. Әмма үзе өчен уңайлы торышны бәбиләүче хатын-кыз үзе сайлаган. Соңрак акушерлык кайчылары, хирургия чаралары, авыртуны баса торган ысуллар кулланылышка керә. Аларны исә бары яткан хәлдә генә куллану мөмкин. Имеш-мимеш кенәдерме, чындырмы – тарихи яктан расланмаган, әмма бүгенге көнгә килеп җиткән шундый сүз бар: француз короле Людовик XIV яраткан хатыны бәбиләгәнне үз күзләре белән күрәсе килгән. Патшага нәсел дәвамчысын каршы алу уңайлы булсын өчен, хатынны аркага яткыралар. Әнә шул вакыйгадан соң, имеш, хатын-кызлар аркасына ятып бала таба башлый.

XIX гасырның данлыклы этнографы А. Сухарев болай дип яза: «Хатын-кыз, гадәттә, салам өстендә, идәндә бәбиләгән. Татар авылларында бәбиләүче хатыннарга кендек әбиләре ярдәм иткән. Һәр авылның үз кендек әбисе булган. Үзенә якты дөньяга килергә ярдәм иткән кендек әбисенә бала гомере буе рәхмәтле булырга, аны кайгыртырга, олыларга, бәйрәмнәрдә котларга, ә үлгәннән соң рухына дога кылып торырга тиеш саналган. Кендек әбисе сабыйны дөрес итеп кабул иткән, баладан яңа котылган анага һәм яңа туган сабыйга кагылышлы барлык чараларны дини яктан да дөрес башкарган».



Лилия ДӘҮЛӘТШИНА: «Татар хатын-кызлары да гомер-гомергә өйдә бәбиләгән. Аның хәлен җиңеләйтү өчен, бу сәгатьләрдә туганнары, кардәшләре, Аллаһтан ярдәм сорап, дога кылган.»

Тик сездәге яңалыклар аягөсте бәбиләтү белән генә чикләнми бугай?

– Безнең бала табу йортында «Сакчыл туу» («Бережное рождение») концепциясе кабул ителде һәм аның нигезендә бәбиләүче хатын-кызның ирекле халәттә булуы уңай бәяләнә. Соңгы ике ел эчендә бу ысул үзен уңышлы яктан күрсәтте инде. Без Амстердамга, Мәскәүгә шушы ысулны өйрәнергә, белем алырга, тәҗрибә тупларга бардык. Хәзерге вакытта перинаталь психология буенча белемнәребезне чарлыйбыз. Ирекле халәттә бәбиләүгә вертикаль ысул гына керми. Бәбиләүнең беренче өлешендә хатын-кызларның хәрәкәтләрен чикләмибез, аларга ничек җайлы, шул позаны кабул итәргә кушабыз, сулыш алу техникасын башкарырга мөмкинлек бирәбез. «Сакчыл туу» концепциясе гипноз ярдәмендә бәбиләтү программасына нигезләнә. Безнең өлкәдә бу – яңа агым. Бәбиләүче хатын-кызны гипноз ярдәмендә ял иттерәбез. Аның хәлен җиңеләйтү, авыртуын даруларсыз гына басып тору өчен дөрес сулыш алу тәҗрибәсен дә кулланабыз. Югары категорияле акушер-гинеколог, медицина фәннәре кандидаты, психолог, Казан дәүләт медицина академиясенең акушерлык һәм гинекология кафедрасы ассистенты Мария Владимировна Ильченко кебек бәбиләттерүнең төрле ысулларын үзләштергән табибларыбыз бар безнең.

Мексика акушеркалары безне «ребозо» массажы ясарга өйрәтте. Тәҗрибәбездә аны да еш кулланабыз. Ул хатын-кызларга йөкле вакытта да, бала тапканда да авыртуларны җиңеләйтергә, киметергә булыша. Һәм сабый дөрес ятмаган очракта, инде табу процессында, аның торышын сак кына үзгәртү чарасы да булып тора. Бу куркынычсыз, нәтиҗәле юл, ә иң мөһиме – җиңел һәм авыртусыз башкарыла.

Баланы аягөсте табуның нинди уңай һәм тискәре яклары бар?

– Әлеге ысул белән бәби табучы хатын-кызның көчәнү вакытында корсак мускуллары, арка, оча сөяге төбе һәм барлык скелет мускуллары – барысы да бу процесста катнаша. Моңа өстәп, Җир шарының тарту көче дә ярдәм итә күрәсең. Шуның нәтиҗәсендә, бала тудырганда күзәтелә торган мускуллар киеренкелеге минимумга кала, оча сөяге төбе мускуллары максималь дәрәҗәдә йомшара – туу юллары буенча сабый җиңелрәк, артык көч чыгармыйча гына, табигый рәвештә хәрәкәт итә. Хатын-кызлар үзләре: «Баскан килеш тапканда, авырту белән идарә итеп була», – диләр.

Тагын бер уңай ягы – бәбиләүче хатын-кыз процесста актив катнаша, бала туганын үз күзләре белән күрә. Кендек бавы киселмәгән килеш үк сабыен әнисе үз кулына ала, күкрәгенә кыса. Ярты сәгать чамасы (кайчак күбрәк тә вакыт) сабый әнисе куенында була.

Баланы вертикаль ысул белән табу сабыйда гипоксия булу, ягъни кислород җитмәүдән, хатын-кызның башы әйләнү, аяк-кулларын өянәк тотудан котылырга ярдәм итә. Чөнки бала табучы хатын-кыз аркада ятканда аның аналыгы (ә ул карындагы бала һәм янындагы сулар белән бергә 6 килограмм тәшкил итә) корсак куышлыгына һәм кан тамырларына (йөрәктән чыгып барлык органнарга, тукымаларга кислородка бай кан илтүче төп кан тамыры – аортага һәм аскы кан тамырына) басым ясый. Шуның аркасында балага җитәрлек күләмдә кислород килми башлый. Аскы тамырга басым ясау исә канның йөрәккә таба аз килә башлавы һәм эчке органнарда, шул исәптән аналыкта да, тамырларда кан йөреше акрынаюга китерә. Нәтиҗәдә, баланың һәм аналыкның кан әйләнеше начарая. Ә хатын-кыз басып яки абаланып торганда, зур кан тамырларына аналыктан килгән басым кими, кан йөреше рәтләнә, гипоксия булмый.

Теләгән бөтен хатын-кызга да аягөсте бәбиләргә рөхсәт ителәме?

– Монда теләк кенә аз. Соңгы сүзне табиб әйтергә тиеш. Әйтик, хатын-кызның кан тамырлары киңәюе күзгә үк күренеп торса, оча сөяге тар булса, бала арт белән килсә, йөклелек катлаулы узса, тулгак вакытыннан алда башланса, ана карынында чакта ук яралгының үсеше тоткарланса, бала туу бик тиз барса, кайбер сәбәпләр аркасында бала буыла башласа, вертикаль ысул белән бала табу рөхсәт ителми. Шулай ук, анатомик үзенчәлекләре булган хатын-кызларга да баланы болай табарга ярамый.

Аягүрә бәбиләргә җыенган хатын-кызга махсус әзерлек кирәкме?

– Баланы ничек кенә табарга җыенса да, хатын-кыз моның хәстәрен алдан ук күрергә тиеш. Әлеге әзерлекне тулгак вакытында дөрес суларга һәм мускуллар киеренкелеген йомшартырга өйрәнүдән башларга кирәк. Бала тапкан вакытта хатын-кызның тән мускуллары ирексездән кысыла. Шуңа күрә хатын-кыз көчле, түзеп булмастай авырту тоя да инде. Әлеге киеренкелекне йомшартып җибәрү тулгак вакытында булган авыртуны киметәчәк. Гимнастика тубына утырып тору да җиңеллек бирә.

Баланы ирегез белән бергә табарга җыенасыз икән, әзерлек курсларына да икәү йөрергә тырышыгыз: сезгә кайчан, ничек булышырга икәнен ул белергә һәм вакыты җиткәч, ярдәм итеп җибәрергә тиеш. (Элек янда кендек әбисе булмаса, кендек бавын да әти кеше үзе кискән. Яңа туган сабыйны атасының җылы күлмәгенә төреп куйганнар. Шушы гадәтне искә алып, без дә көтеп алган нарасыйларын әтиләрнең түшенә салабыз.)

Бала тапканда кулланылырга мөмкин булган уңайлы позалар белән танышудан тыш (чүгәләп утыру, абаланып басып тору, тезләнү һәм башкалар), вертикаль килеш бала табарга әзерләнү башкалардан әллә ни аерылмый. Шулай ук йөклелек вакытында даими рәвештә гинекологка күренеп тору, кайда, нинди клиникада, кайсы табиб белән табарга җыенганыңны алдан ачыклау кирәк.

Ә бу ысул бала өчен уңайлымы соң?


– Әнисе аягөсте булганда, балага туу юллары буенча хәрәкәт итүе күпкә җайлырак. Статистика мәгълүматларына карасак, сабый әлеге ысул белән дөньяга килгәндә (хәтта авырлыгы зур булган очракта да), туганда булырга мөмкин катлаулыклар ун тапкырга азрак күзәтелә. Бу ысулның отышлы якларын иң беренче булып педиатрлар искәртә: вертикаль ысул белән туган сабыйларның Апгар шкаласы буенча сәламәтлек күрсәткечләре югары, неврологик авырулары сирәк, алар беренче айларда ук тернәкләнеп китә, авырлыкны тиз җыя, тизрәк үсә.

Психологлар, табиблар бу балаларның алдагы тормышын да күзәтеп килә. Алар яхшы укый, игътибарлы, тырыш, араларында сәләтле балалар да күп.

Яңа ысул белән бала табарга йөкле хатыннар җиңел ризалашамы?

– Бу – ирекле эш, без үз чиратыбызда төрле ысуллар тәкъдим итәбез. Ә инде иң уңайлысын сайлап алу (әлбәттә, сәламәтлеккә зарарсызын) – хатын-кызның үз ихтыярына бәйле. Бездә бала тудыру процессын индивидуаль рәвештә алып баручы табибны сайлау мөмкинлеге дә бар. Ул килешү нигезендә башкарыла. Әмма кизү торучы һәр бригада сезгә ничек уңайлы – баланы шулай кабул итәргә әзер. Бу безнең бала тудыру йортының концепциясенә бәйле. Коллективыбыз даими рәвештә камиллеккә ирешергә һәм яңалыкка омтылырга тырыша.

WORLDSKILLS КӘТТӘ ЭШМӘКӘРЛӘР ҮСТЕРӘ



«Эшмәкәрлек – канда. Йә сәүдәгәр булып туасың, йә юк» дигән фикер хәзерге инновацион заманда тамырдан үзгәрде инде. Танылган икътисадчы, XX гасырның менеджмент теоретигы Питер Друкер болай дигән: «Сез эшмәкәрлек хакында ишеткән мәгълүматның күбесе дөреслеккә туры килми. Ул тылсым да, геннар белән дә бәйле түгел. Эшмәкәрлек – фән, аны өйрәнергә кирәк». Worldskills хәрәкәтендә эшмәкәрлек компетенциясе булу да шуңа ишарә. Сәүдәгәрлек серен кемнең генә чишәсе килми икән. Worldskills хәрәкәтендәге әлеге компетенция буенча барлык җиңүләрне яулап бетергән Карина ХАЛЕЕВА да шундый максат белән килә. Һәм ул аңа ирешә. Эшмәкәрлеккә өйрәнү җиңелме? Әнә шул сорауга җавап эзләп карыйк әле.

Карина узган ел Будапештта узган EuroSkills чемпионатында җиңү яулап кайта. 25 яшькә кадәрге яшьләр арасында һөнәри осталык буенча Европада иң масштаблы ярыш ул. Мәскәүдән Анастасия Якушина белән алар эшмәкәрлек компетенциясендә бердәнбер хатын-кыз командасы булалар. Әйләнә-тирә мохитне саклау һәм чүп эшкәртү буенча бизнес проект төзеп, Европаның яшь эшмәкәрләре арасында иң яхшысы булып танылалар. Бер сәгать ярым эчендә инглиз телендә инвесторларга тәкъдим итә алырдай тулы бер бизнес план төзи алар. Җиңү пьедесталына менеп баскан Карина, хыялына таба дөрес баруын аңлап, икеләтә сөенә. Ә хыялы... Ул үзен кечкенәдән үк зәвыклы костюмнар киеп йөргән бизнесвумен итеп күз алдына китерә. Дөнья икътисадын анализлау өчен төпле белем алырга кирәклеген аңлаган кыз мәктәпне тәмамлагач, Тимирясов исемендәге Казан инновацион университетының менеджмент һәм инженер бизнесы факультетына укырга керә. Икенче курста укыганда WorldSkills хәрәкәтенә кушыла. Вуздагы, республикадагы ярышларда беренчелекне бирмәгән Каринаны Краснодарга һөнәри осталык буенча Бөтенроссия чемпионатына җибәрәләр. Анда беренче урынны яулап, илнең җыелма составына керә. Бер ел буе Европада үтәчәк чемпионатка әзерләнә ул. Европада бизнес алып бару Россиягә караганда үзгәрәк. Шуңа күрә Европа менталитетына җайлашырга туры килә. Моның өчен планлаштырылганнан артыграк та өйрәнергә кирәген яхшы аңлый кыз. Тәүлегенә 20 шәр сәгать әзерләнгән вакытлары була. Тырышулары бушка китми: Европада чираттагы җиңүен яулап кайта.
Бу вакытка инде ул шактый шомарган, чарланган була.

– Ярышларда катнашу миндә стресска каршы торучанлыкны үстерде, – ди кыз. Берничә ел элек тренерның катырак әйткән бер сүзеннән дә елап җибәрә торган булса, хәзер анда олимпия тынычлыгы: һәр мәсьәләне салкын акыл белән хәл итәргә өйрәнә. Үзенә ышаныч та арта. Бу – профессиональ яктан үсү билгесе.

Осталыкның югары дәрәҗәсен күрсәткән Каринага Европадан кайту белән эш тәкъдим итәләр. Университетның эшмәкәрлек компетенциясен үстерү үзәге җитәкчесе урынбасары ул хәзер. Сертификатлы эксперт. «Үзем укыган вузда студентлар лигасында идем, студентларның фәнни җәмгыяте рәисе булдым. Җәмәгать эшләрен бик күп башкардым, хәзер рәсми рәвештә теркәлеп эшли башладым», – ди ул гади генә. WorldSkills ярышларына әзерләгән укучыларына профессиональ булу өчен һәрвакыт үсештә булырга кирәклеген аңлата. «Worldskills – кәттә белгечләр әзерләүче зур мәктәп», – ди Карина. Әлеге хәрәкәттә катнашып, бик күп дуслар таба, яңа шәһәрләр күрә, ә иң мөһиме: белемен арттыра. Worldskills аңа Сингапурда бизнес мәктәбендә укырга мөмкинлек бирә. Быел җәй шул ук максат белән Германиягә җыена. Аны министрлыклар, төрле ведомстволар эшкә чакыра. (Резюмесында мәртәбәле чемпионатларда җиңү яулау хакындагы мәгълүмат зур роль уйнамый калмый, билгеле!) «Бертөрле эш яратмыйм», – ди Карина. Камиллекнең дә чикләре юк бит әле. Балачак хыялына да хыянәт итәсе килми.
Ул һичшиксез бизнесвумен булачак. Белә: моның өчен нигез салынган инде.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

ГОМЕР ОЗЫНЛЫГЫ ДҮРТ ЕЛ

Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Бау түгел, нигә скакалка сайлаганмындыр, анысын белмим... Ничектер бер күзем төшеп: «Менә бит миңа кирәк әйбер», – дип уйлаганым истә...





Шуннан соң ул гел күз алдымда ятты. Үзе – кызыл, тоткалары зәңгәр төстәге скакалка... Интернеттан кереп карадым: әни кеше үлсә, карынындагы бала 15-20 минут кына яши, дигәннәр. Юк, бу вакыт эчендә генә мине әле тапмаячаклар, дим. Үземне генә түгел, баланы да үтерәм бит дип тукталдым. Тагын азрак көтәргә булдым... Бала туды, аны өйгә кайтарып салдым. Ирем өйдә юк, каядыр киткән иде. Теге скакалканы алдым да сарайга чыктым. Кереп бастым, тагын берничә минут, секунд һәм... Шул вакыт Искәндәрнең: «Әни! Әни!» – дип кычкырган тавышы ишетелде. Мине эзләп чыккан... Ул да түгел, килеп, сарай ишеген шакырга кереште: «Әни!» Искәндәр ул гел шулай – минсез бер минут тора алмый. Шул балам коткарды мине... Кинәт айнып киткәндәй булдым. Дүрт баламны кемгә калдырам соң мин? Аларны миннән башка кем караячак? Үз-үзенә кул салган кешеләрнең хәлен аңлыйм хәзер: нindидер күзгә күренмәгән бер көч йөртә аларны. Бу адым бөтен проблеманы чишәчәк дип ялгыштыра...

Шул көн барысын хәл итә.

Кечкенә улына өч ай булгач, балаларын җитәкли дә өйдән чыгып китә Альбина. Бернәрсәсез! Аңарчы олы улы белән киңәшләшә: «Мин башкача болай яши алмыйм, улым... Йә үз-үземә кул салам, йә без китәбез...» Тугызынчы сыйныфта укучы Илнар ике дә уйламыйча: «Җыен, әни, күчәбез!» – дип җавап бирә.

Сәбәбе... Без Альбина белән ул хакта сөйләшмибез. Дүрт бала белән (!) хатын-кыз билгесезлеккә таба атлаган икән, моңа, әлбәттә, җитди сәбәпләр булгандыр. Унҗиде ел буе җыелган, өсте-өстенә өелгән сәбәпләр...

Кеше почмагына барып керәләр. Начар гына йорт, шартлар юк диярлек.

– Ипотекага таш йорт алып, аны ремонтлап кергән идек бит. Балаларның һәркайсының үз бүлмәсе иде. Ә монда... Элина бик елады инде. Бер сүз әйтми, елый гына... Аңа карап мин елыйм... Тик берсе дә: «Кире кайтыйк», – димәде... Балалар бик иртә өлкәнәйде минем. Барысы да...

Кесәсендә күпме акча булды икән ул чак? Шул начар гына фатир өчен алты мең түләгәч, биш җанга ай буе яшәр өчен ничә сум калды икән? Кышын ул фатир хакы 12 меңгә кадәр җиткән бит. Ә Альбинаның декрет акчасы нибары 11 мең... Бала азрак исәюгә эшкә чыгам дигән өметләре дә кинәт киселә: хезмәт урынындагы кайбер үзгәрешләр аркасында ул эшсез кала.

Менә шулай: эшсез, акчасыз һәм торыр урынсыз.

– Әле ярый тамада эше бар иде... Мин өйдән шуңа ышанып чыгып киттем дә. Атна саен улым белән без банкетта: ул аппаратура артында утыра, мин алып барам. Яңа ел алдыннан тоташ ике атна эшләдек. 29 декабрь көнне аңымны җуеп егылганмын. Арудан, ашамаганнан бугай... Күз алдыгызга китерәсезме, бу бит әле дүрт ел элек кенә булды! Нибары дүрт ел элек...

Үземә соңгы тапкыр нәрсә алдыммы? Хәтерләмим... Барысы да – балаларга!

Әңгәмәбезне бүлеп, телефон шалтырый. Альбина аны басып куя: «Искәндәр эзли... Әйтәм бит, ул минсез тора алмый. Көнгә егермешәр тапкыр шалтырата. Күземә генә карап тора. Аз гына кәефем төшкәнне дә сизә: «Син нигә күңелсез? Ни булды?» – ди.

– Бүгенгедәй исемдә... Агач идән иде ул фатирда, шунда утырып торам. Янымда кечкенә улым йөри. Аның яңа тәпи киткән чагы иде. Аны үстерү авыр булды ла... Гел чирләде ул. Бер-ике тапкыр чак үлемнән алып калдым мин аны. Аллергия аркасында тын ала алмый башлады берсендә. «Ашыгыч ярдәм» безнең күршедә генә иде – күтәреп шунда йөгердем. Үзем чабам, үзем баланы күкрәгемә кысып: «Улым, үлмә! Зинһар, үлмә!» – дип ялварам... Шулай каты кысып, ясалма сулыш алырга ярдәм иткәнмен күрәсең. Өстәлләренә кертеп салдым... «Балаң исән, өлгердең», – диделәр... Читкәрәк киттем. Идәндә утырган килеш, Аллаһы Тәгалә белән сөйләшәм: «Миңа балаларны аякка бастырырга кирәк бит... Нәрсә эшлим соң? Бу сынаулар нинди гаепләрем өчен?» – дим. Кеше рәнҗеткәнем юк минем. Кая ул, талаша да белмим. Кемгәдер каршы сүз әйткәнче кайтып елыйм гына... Бер кафены арендага бирергә җыенуларын ишеткән идем. Арендага 50 мең сорауларын да белә идем. Кесәмдә бер тиенем булмаса да, хуҗасына, Рузалия апага шалтыратып та карадым. «Юк, әле бирмим, уйлыйм», – диде. «Нишлим?» – дип Ходай Тәгаләгә ялварганда, миңа шул Рузалия апа шалтыратты. «Кафены бирергә булдым әле. Әйдә, килеп кара. Тик акчасын хәзер үк тапшырырсың», – диде...

Илле мең акчаны ул чакта Альбина бер дус кызыннан сорый. «Кайчан кире кайтарачагымны белмим, әмма, һичшиксез, бирәчәкмен», – ди. Кафены шул көнне үк кабул итеп ала. Икенче көнне инде иртән плитә янына барып баса. Юлда килгәндә макарон, салат ясарга дип кәбестә сатып ала. Ите өйдә була. Ә төш вакытында кафе ишеген ачып, алты (!) кеше килеп керә! Шәһәр читендәрәк урнашкан бу кафега ничек юллары төшкән? Якын-тирәдә бер оешма да юк бит... Шулай эшләп китә. Март башы була бу. Ә 6 март көнне аңа бер апа банкет үткәрергә языла. 60 кешегә! Чакырган кунакларның барысы да килә. Альбинаның кулына 60 мең акча керә. «Үземне ул чакта миллионер итеп тойдым! Ир белән яшәгәндә дә акчага туйган вакытым булмады бит. Юклыктан, җитмәгәнлектән тотынып нәрсә генә эшләмәдем: кемгә салым оешмасы өчен декларация тутырдым, кемгә тектем, диплом яздым, торт пешердем, клоун булып йөрдем...» – ди ул.

Фото: Анна Арахамия

Өй өчен бурычым юк, «үземнеке!» дип кайтып керәм.

Иң авыр чакта арендага кафе алуы да юкка түгел: нинди эшне яхшы белә, шуңа тотынуы. Альбина Казан дәүләт технология университетының Бөгелмәдәге филиалын, «Азык-төлек технологияләре» факультетының кичке бүлеген тәмамлый. Ә көндез повар-кондитерга укый – монысы торырга тулай торак кирәк булганга. Тормыш кына аны моңарчы алган һөнәреннән гел читтә йөртә: салым инспекциясендә эшли, бухгалтер һөнәрен үзләштерә.

Беренче банкеты әйбәт уза аның. Кунаклар рәхмәт әйтеп китә.

Кафедагы иң беренче мәҗлесләрне искә төшерә башласа, әле дә күзенә яшь тула. Банкет көнне, башта үзенә булышырга чакырган аш-су остасы Рузалия апа белән плитә янында янәшә басып пешерә, аннан ризыкларны табынга тезә. Кунаклар килгәч, мәҗлесне ачып, тамада ролен башкара. Тәнәфестә, кухня ягына кереп, биленә алъяпкыч бәйләп, савыт-саба юып чыгарга өлгерә. Залга чыгып, кабат кунакларны җырлата, биетә, уйната... Соңгы кунак артыннан ишек ябылуга, әле генә җырлап торган Альбина кабат юучы, җыештыручыга әйләнә: барысын да тәртипкә салып китәргә кирәк – иртәгә яңа көн, яңа клиентлар көтә. Нәрсәдер онытып, кире борылып керүчеләрнең: «Әллә бу сезме?» – дип, аптырап, гаҗәпләнеп әйткән чаклары байтак була аңа.

– Эскәтерләрне өйгә алып кайтып юам, өйдә үтүклим. Ул җәйне суларга да вакытым булмады. Балаларны күрмәдем дә диярлек... Халык кафега иялләште. Заказлар күбәйде. «Сез – иң яхшы аш-су остасы», «Сез – иң яхшы алып баручы» дип язалар. Тик мин билсез калдым, кан басымым уйный... Берүзем барысына да җитешү һич мөмкин түгел иде. Безнең Азнакайда табынның мул булганын яраталар. Башта жульен чыгарабыз, аннан – аш, икенчегә – икешәр төрле ризык, шуларга өстәп голубцы яки манты, өч-дүрт төрле салат... Банкет көннәрендә официант кызлар чакыра башладым.

Аннан арендага тагын бер кафе ала Альбина. Монысы инде – Азнакайның уртасында: халык йөри торган җир. Кул астында эшләүчеләре дә күбәя.

– Һәрвакыт беренче урынга сыйфатны куйдым. Кеше арасында танылырга, аларны үземә ияләштерергә кирәк иде. Ә моңа бары тик шушы юл белән генә ирешеп була. Кафенең үземнеке түгеллеген белә идем: бүген булмаса, иртәгә хуҗасы мине чыгарып җибәрәчәк. Башка җиргә күчсәм, халык исемемә ияреп килергә тиеш иде. Кешегә ярый алсаң, ул сиңа кабат киләчәк. Күңелемне салып эшләдем! (Акча өчен генә эшләсәң, гомумән, акча эшләп булмый.) Үз клиентларым бар – туган көн, туй, юбилей җитсә, мине эзләүчеләр...

Бүген Альбинаның арендага алган кафесы берәү генә. Кул астында эшләүчеләрнең саны исә кимемәгән – җидәү. Ә үзенең эше... Юк, юк, анысы да һич кимемәгән. Соңгы вакыт аның бик зур бер хыялы чынга ашкан – ул укыта башлаган.

Әңгәмәбез бүленә – телефон шалтырый. Искәндәр! «Улым, әлегә мин буш түгел. Үзем шалтыратырмын», – ди Альбина.

– Узган көз интернеттан Азнакай политехника техникумына укытучы эзләүләрен белдем. Нәкъ минем юнәлеш! И-и, кызыктым! Тик мине алмаслар шул, белемем юк бит дип уйлыйм. Казан педагогика институтыннан имтихан биргән җирдән кайтып киттем бит. Әни: «Син мәктәптә балаларны тыңлата алмассың», – дип шалтыратты. Йөргән егетемне дә сагынган идем... Ә хыял күңелдә барыбер калды! Шул көннәрдә эш белән район Башкарма комитетына барырга туры килде. Бу хакта сүз чыкты. «Ә син барыбер барып кара әле», – диделәр. Тәвәккәлләдем. Алдылар! «Ә бизнесыңны нишләтәбез?» – ди директор. Район зур түгел бит – бездә кеше бер-берсен белә. «Ул җайга салынган инде, эшкә комачау итмәс», – дим. Миңа бит ничек тә шушы кара такта янына барып җитәргә кирәк! «Ә тамада эшен?» – ди янә директор. «Анысы бит аның гел кичке якта», – дим... Беренче уку елымны тәмамлыйм менә. Канәгатьләр шикелле. Аннан ДОСААФ оешмасыннан: «Бездә «бухучет» укыта алмассызмы?» – дип мөрәҗәгать иттеләр. Ә нишләп укытмаска – белгән эшем бит... Бу – минеке! Үземне таптым!

Студентлары турында ул «балалар» дип сөйли. (Гаиләсе ишәйгән!) Алар аның кафесында практика уза, эшләп кала. «Һәрвакыт алар урынына үземнекеләрне куеп карыйм: минем улымны шулай каршыласалар, кызыма шулай әйтсәләр... Ишетеп беләм, күпләр әнә кафеда хезмәткәрләргә ашарга рөхсәт итми, йә моның өчен акчасын тотып кала. Ә минем банкет әзерләгән көнне Рузалия апага иң беренче соравым гел бер: «Балаларны ашаттыңмы?» Студентларымның әниләре миңа рәхмәтләдедер...» (Альбина кул астында эшләүчеләр, гомумән, аннан зарланмыйдыр: кырыс җитәкче түгел ул. Кешегә «эх» дип тә әйтә алмый. Нәрсәнедер дөрес эшләмәүчегә, аның үзе генә ишетерлек итеп: «Икенче юлы менә болайрак кирәк булыр», – ди. Башкача булдыра алмый: кешене уңайсыз хәлгә куюдан тартына. Булган инде, аның бу йомшаклыгыннан файдаланучылар да булган. Бер таяк колбасаның яртысын, бүлеп, үз сумкасына салучылар, савыт-саба юарга алып килгән «Fairy»ның яртысын савытка бушатып өенә алып кайтып китүчеләр. Күрсә дә эндәшмәгән – анысы ул кешеләр намусында калсын.)

Телефон шалтырый. Икебез дә елмаябыз: Искәндәр! «Ярый, улым, чык урамга, уйнап кер», – ди Альбина.

«Тормышым тоташ могҗизадан тора», – ди ул.

Бүген ике катлы зур йортта яшәүләре үзе могҗиза түгелмени?! Урамда калган җирдән... Алты ел элек, 2 яшьлек Искәндәр белән паркта йөргәндә ике хатын белән таныша ул. «Читтән кайттык. Монда сатасы өебез бар, бәяләрне белмисезме?» – диләр. Риэлтор булып эшләп алган кеше торакка бәяне ничек белмәсен?! Аннан ире белән торуларының рәте юк – ул бит гел күңеленнән кая чыгып китү турында уйлап йөри. Сатыласы йортның кибеттән ерак түгел икәнен белгәч, эзләп табып, карап та кайта. Ә дүрт ел элек, инде кеше почмагына күчкәч, әлеге йорт хуҗаларының телефон номерын эзләп таба. «Ике миллион ярымга бирәбез», – диләр. Кереп яши башлый торган йорт түгел бит, күптән каралмаган, тәрәзәләренә кадәр ватык. Су юк, уңайлыклары – урамда... «Ә син күпмегә алыр идең?» – дип кызыксына хуҗалар. «Миллион ярымга», – ди ул. Ә үзенең кесәсендә бер тиен акча юк! Әле кафеда да эшли башламаган чагы. «Юк, бу бәягә сатмыйбыз», – дип баш тарталар. Кыш уза. Йорт сатучылар язын Себердән тагын кайталар. «Син әйткән бәягә без риза, аласыңмы?» – диләр Альбинага. Хакын тагын 500 мең сумга төшерәләр һәм... кабат китеп баралар. Йорт янынннан узган саен аның белән сөйләшә ул: «Аз гына көт, мин сине алам! Тагын аз гына...» Җәй җитә. Йорт хуҗалары кабат кайтып төшә. «Мине хәзер йортка кертегез, ә акчасын киләсе елга бирәм», – ди Альбина бу юлы. Килешәләр. Тау кадәр ул бер миллионны кайдан ала – анысын әле белми, әмма табасын белә!

– Ике ай эчендә йортка ремонт ясап кердем! Үзем кредит алдым, әни... Йортка өстәп, янкорма салдык, барысын бер түбә астына керткәч, икенче кат барлыкка килде. Ваннага плитканы үзем ябыштырдым. Идән җәйдем. Декоратив ташларга кадәр үзем ясадым. Теләсәң, бөтен эшкә дә өйрәнеп була... Күчеп яши башладык, ә минем кулда йортка бер документ юк! Бер ел буе йокым йокы булмады, тамагымнан ризык үтмәде... Әни – бер яктан, таныш-белешләр икенче яктан: «Алдарлар дип курыкмыйсыңмы? Ничекләр кешегә шулай ышанырга мөмкин? Бу йортны алар хәзер 5 миллионга сата ала», – дип әйтеп тордылар. Кайтып, урамга чыгарып җибәрсәләр дә бернишли алмый идем. Өстемдә никадәр кредит!

Телефон. Әлбәттә, Искәндәр! «Нинди батарея дисең? Ярый, ал, утыз сум акча ал, улым», – ди Альбина. Аннан миңа борыла: – Иң күп ачулану шушы балага эләгә. Гел кул астында булгач соң. Үпкәләми тагын.

– Әле бит түләргә акча да тапмаган... Ленарга банктан: «600 мең бурычыгыз бар. Йә түләгез, йә ипотекага алган йортыгызга арест салына», дигән хат килүен ишеттем. «Балалар хакына, зинһар, сатыйк, сиңа – яртысы, миңа яртысы булыр», – дип ялындым. Миңа ул чакта да Ходай булышты. Таш йортыбызны 3 миллионга сатып җибәрдем. Ул арада үземнең өй хуҗалары кайтып төште. Нотариуста утырганда елыйм гына бит. Ышана алмыйм... Ниһаять! Балаларым урамда калмаячак!

Тормыш инде бер көйгә салынган. Илнары быел Самара медицина колледжын тәмамлый. (Искәндәр артыгын шукланса, әниләре гел олы улына шалтырата: «Энең белән сөйләш әле!» Алар йортында абый сүзен барысы да тыңлый.) Элина – әнисенең иң зур таянычы: Эмильне бакчадан алу, ашату-эчертү, йокларга яткыру – барысы да аның өстендә. (Аларда: «Нигә бу эшне мин эшлим, башкалар түгел?» дигән сүз бөтенләй юк.) Элина белән Искәндәр абыйлары тәмамлаган музыка мәктәбендә дә укып йөриләр. («Кирәге чыгар! – ди әниләре. – Минем үземә тормышта алган бар һөнәрнең дә бер кирәге чыкты менә».) Альбина Мөбарәкшина быел «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесендә катнашты, «Хатын-кыз – эшмәкәр» номинациясендә җиңү яулады. Ә нибары дүрт ел элек...

Без тагын шул көннәргә кайтабыз.

– Мин Ленарны бик нык яраттым. Башка берәү дә беркемне шулай яратмагандыр... Юмаган идәнгә дә бастырмадым. Аннан башка ашарга да утырмадым. Бәлки, хәзер дә ярата торганмындыр... Тик аның янында бүген бәхетсез булыр идем. Мин белгән Ленар юк инде ул, монысы аның башка кеше... Ә, бәлки, мин яраткан Ленар хыялымда гына булгандыр?! Начар кеше түгел ул, ләкин без – төрле. Ул да мине яратты, ләкин бу якын итүне күрсәтүе генә үзенчәлекле иде... Яраткан кешең рәнҗетсә, күпкә авыррак. Бизәсең икән... Бик сизгер, нечкә күңеллемен шул – мине күз карашы белән дә үпкәләтергә, хәтеремне калдырырга була. Әмма аңа беркайчан начарлык теләмәдем. Кайберәүләр «башы бетсен» дип тели, ә мин: «Берәр хатын табып чыгып китсә иде», – дия идем... Мин бүген бик бәхетле. Янымда таянырлык ир-ат булмаса да. Хәер, нигә булмасын, әнә өчәү бит алар минем. (Аннан, әни бар бит минем! Тиешле булса, ачулана, кирәк чакта тынычландыра белә. Кая барсам да борчылмыйча чыгып китәм, чөнки ул һәрвакыт балаларыма күз-колак.) Бер ун елга алданрак китмәгәнмен дип үкенәм... Нигә түзелгән, белмим. Тик ул чакта балаларым дүртәү булмас иде. Барысын да табып бетермичә китеп булмады шул... Ленарга мин алар өчен бик рәхмәтле. Шундый көчле булырга өйрәткән өчен дә рәхмәт аңа. Аның аркасына ышыкланып, иркәләнеп яту эләкмәде миңа. Аерылышуыбызда минем дә гаеп бар. Һәрвакыт үзем алдан чаптым. Ә ул шуңа ияләште. Минем башкалардан алданрак яшисем килә – алар миңа тигезләнсен. Балаларга да шулай дим, үзегездән яхшыраклардан үрнәк алыгыз, дим.

«Елаганда яшем чыкмый, җаным гына елый иде минем. Көлгәндә дә шулай. «Бигрәк сабыр, кычкырып көлми дә», – диләр иде минем турында. Хәзер рәхәтләнеп көлә башладым», – ди Альбина.

Аның тормышындагы тагын бер матур яңалык, әйеме?

PRESSA



«Үскәч блогер булам...»



Альбина
ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА

Әниләр һәм бәбиләр темасын дәвам итәм. Декрет ялындагы әниләргә кайдан өстәмә керем табарга һәм бүгенге көндә нинди яңа һөнәрләргә өйрәнергә була – сүзем шул хакта.

Бала туып ярты ел чамасы узгач, күз алдындагы томан тарала төшә, һәм син әкренләп элеккеге тормышка кайта башлыйсың. Бу чакта яшь әниләр нәрсәләр турында уйлана, нинди адымнар ясый соң?

Кемдер спортзалга языла, гардеробын яңарта, ә кайберәүләр исә үзләренә берәр хобби таба. Игътибар иткәнегез бардыр, күпчелек хатын-кызлар хәзер нәкъ менә декрет ялында утырганда үзләрен яңа яктан ача, көтмәгән-уйламаган эш белән шөгыльләнә башлый. Баштарак әлеге шөгыльләре хобби – мавыгу гына булса, соңрак күпчелек әниләр өчен ул өстәмә керем чыганагына әйләнеп куя.

Яшермим, мин үзем дә декрет ялына чыгу белән бераз акча эшләү турында уйлана башладым. Яшь әниләр белә: социаль иминиятләштерү фонды пособиене балага бер яшь ярым тулганчы гына түли. 2019 елда аның максималь күләме 26152 сум иде. Беренче карашка, өйдә утырган кеше өчен аз акча түгел бу. Тик нәни баланың аяк киеме дә 2500–3000 сум торганын исәпкә алсаң, әлеге пособие бер дә күп булып тоелмый башлый шул... Ә инде балага яшь ярым булганнан соң, аның күләме, гомумән, 50 сумга гына кала. Бер айга бу! Мондый акчага балага нәрсә сатып алып булганын тиз генә уйлап әйтү дә кыен... Тик бүген сүзем бу хакта түгел әле.

Яшь әниләргә кулай эш нинди булырга тиеш? Беренчедән, аны баладан аерылмый гына өйдә торып башкарып булсын. Икенчедән, ирекле график булуы бик мөһим. Мондый эшләрне хәзер кайдан эзлисе билгеле инде – әлбәттә, интернет аша.

Интернет челтәре бүген шактый кызыклы яңа һөнәрләр тәкъдим итә. Аларның иң популярларына тукталып узам.

БЛОГЕР Блогерның эше билгеләнгән темага билгеле бер вакытта зур булмаган язма – пост чыгарудан гыйбарәт. Пост фотосурәт белән бергә чыга. Димәк, блогер фотоны да, язманы да әзерләргә тиеш. Блоглар төрле социаль челтәрләрдә яки махсус сайтларда урнаштырыла һәм төрле темаларга багышлана: әниләр һәм бәбиләр, сәяхәтләр, дөрес туклану, спорт, дизайн... Кыскасы, темалар чикләнмәгән. Иң мөһиме: үз аудиторияңне булдыру һәм алар өчен иҗат итү. Кешеләр синең блогыңны укып барсын, фикер алышуларда катнашсын өчен шактый тырышырга кирәк. Блогерлар арасында конкуренция үсә барган саен, аларга таләпләр дә арта – фотоларның сыйфаты югарырак, текстлары мәгънәлерәк һәм кызыклырак булырга тиеш. Әйтик, хәзер блогны бер стильдә ясар өчен, фотоларны да бертөрле төсләр палитрасында төшерергә тырышалар. Яшь әни буларак, үзем кебек әниләр турында язучы блогерларны укыштыргалыйм. Әйтик, бер әнинең блогы яшькелт-соры төсле фотолардан тора. Ул әлеге төсләрне бозмас өчен өенә дә шундый төстәге җиһазлар, хәтта балаларына бары яшькелт-соры уенчыклар гына ала! Беренче карашка, монысы артыгraктыр да бәлки. Тик нишлисең – блогның таләбе шундый.

Интернет тәкъдим иткән яңа һөнәрләр тормышыбызга бик тиз килеп керде.

Әниләр-бәбиләр темасын яктырткан бу блогерларның балалары меңләгән кешелек аудитория күз алдында үсә. Бала кая барган, нәрсә ашаган, нинди кием кигән – барысы хакында да блогта сөйләнә. Кайчандыр «Шоу Трумана» дигән фильм миндә зур тәэсир калдырган иде. Анда Труман фамилияле төп герой үзе дә белмәстән бер шоуның герое булып китә, һәм кешеләр гомер буе аны күзәтеп яши. Хәзер исә кемнәрдер үзләре теләп шундый «трумannарга» әверелә: читләргә үз тормышларын карап барырга рөхсәт итә. Бу үзенә күрә кыюлык та, тәвәккәллек тә сорый, минемчә. Тормышыңны күпләр күзәтерлек кызыклы шәхес булу, шул ук вакытта билгеле бер чикләрдән узмау – шактый катлаулыдыр.

Мондый «ачык» тормышның уңай яклары да җитәрлек: аудиторияң никадәр зуррак булган саен, блогыңда реклама да шулкадәр кыйммәтрәк торачак.

СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘР АДМИНИСТРАТОРЫ ЯКИ SMM МЕНЕДЖЕР Әлеге һөнәр ияләре социаль челтәрләрдәге төрле группаларга «баш» булып тора: фотоматериаллар әзерли, текстлар яза, шул группаны рекламалау өчен төрле ысуллар эзли... Шактый креатив идеяләр сорый торган эш. Бүген барлык кибет һәм сәүдә нокталарының социаль челтәрләрдә үз «бит»ләре булганлыктан, мондый һөнәр ияләренә эш табу кыен түгел.

Әгәр дә инде барлык эшләрне бергә алып барырга – фотога да төшәргә, текстлар да язарга, PR белән дә шөгыльләнергә теләмисез икән, сезнең кебекләр өчен бераз таррак профильле профессия бар. Копирайтер дип атала ул. Әлеге һөнәр ияләре бары тик текстлар язу белән генә шөгыльләнә. **КОПИРАЙТЕР** берәр социаль челтәрдәге группага тематик пост яисә берәр оешмага реклама текстын яза һәм шуны аларга сата.

Сез **ТЕТА-ХИЛИНГ**ның (ThetaHealing) нәрсә икәнен беләсезме? Кыскача һәм бик гади итеп әйткәндә, ул – позитив фикер йөртү нәтиҗәсендә җанны һәм тәнне дәвалаучы махсус методика. Тормышында кичергән шактый зур сынаулардан соң, Америкада яшәүче Вианна Стайбл дигән рәссам һәм язучы ханым уйлап тапкан. Үз күңелендә эзләнеп, күп кенә эмоциональ проблемаларны хәл итеп, авырулардан терелеп була диләр әлеге методика тарафдарлары. Нининдидер кырыкалдарлар уйлап тапкан әкият диярга ашыкмагыз. Күпчелек өйрәнүләр әлеге

Фото: www.pixabay.com

Белемле, ышанычлы тренер тапкан очракта, шактый кирәкле күнекмәләрне үзләштерергә мөмкин.

методиканың дөреслеген фәнни яктан раслый. Шунысы кызык, бүген әлеге методика бездә дә бик популяр. Күпләр башта махсус курсларда укый, аннан үзләре башкаларны шуңа өйрәтә, укыта башлый. Методика үзе шарлатанлык булмаса да, аны укытучылар арасында җиңел генә акча эшләргә теләүчеләр җитәрлек менә. Әйтик, бер танышым өч көн дәвамында тета-хилинг буенча курслар узды. Әлеге укуы өчен 15 мең сум акча түләде. Инде шул өч көн эчендә алган «белеме» белән башкаларның күңелен «дәвалый». Ул да һәр кешедән 15 әр мең сум җыя.

Интернетта **КОУЧ,** ягъни тренер булып башкаларны үзе яхшы белгән әйбергә яки һөнәргә өйрәтү дә еш очрый. Күпчелек очракта ул марафон дип атала. 20 көнлек марафон дәвамында сезне ябыгырга, дөрес тукланырга, үз-үзеңне яратырга, тормыштан тәм табып яшәргә һәм башка бик күп төрле файдалы гамәлләргә өйрәтергә мөмкиннәр. Андый марафоннарның күбесе түләүле. Монда иң мөһиме – алда әйтеп үтелгән алдакчы-аферистларга юлыкмау.

Әниләр-бәбиләр темасына багышланган блогларны укыйм дидем. Бала үстергәндә сораулар туса, гадәттә, әниләр педиатрларга мөрәҗәгать итә. «Иде элек», – дип өстисе килә бу урында... Хәзер бала үстерү белән бәйле белгечләр күбәйгәннән-күбәя бара. Әйтик, бала имезү буенча махсус белемле белгечләр бар. Алар ничек итеп баланы озак һәм проблемаларсыз имезергә, аннары баланы имидән ничек аерырга өйрәтә. Түләүле консультация кирәк булса, өйгә дә киләләр, баланы ничек тотарга, бала имезгән чорда әнигә ничек дөрес тукланырга – барысын да аңлаталар. Баланы дөрес ашату, йоклату буенча да махсус белгечләр бар хәзер. Аларның ни белән шөгыльләнүен күз алдына китерү кыен түгел: беренчеләре баланың рационын төзергә ярдәм итә, икенчеләре бәләкәчне ничек итеп көйсезләнми генә йоклату серләренә төшендерә.

Интернет-һөнәрләр темасы белән кызыксына башлагач, мин үзем дә шушы һөнәрләргә өйрәтүче берничә марафонда катнашып карадым. Әлеге марафоннар күбесе бушка үткәрелә, аларга һәр көнне билгеле бер вакытта ноутбук яисә телефон аша кушылырга гына кирәк. Тик бушлай сырның кайда булганын барыбыз да белә: бу марафоннар күпчелек очракта берничә атналык (яисә айлык) курсларның кереш өлеше генә булып тора. Аңлагансыздыр, дәвамы – түләүле.

Тагын бер интернет-керем төрен атап үтмичә булмый, чөнки алар хәзер гаять популяр. Бу – **ЧЕЛТӘРЛЕ МАРКЕТИНГ**. Социаль челтәрләрдә: «Бер ай эчендә керемегезне 100 мең сум итәм», – дип чакырып торучы танышларыгыз, бәлки, сезнең дә бардыр. Күпләр аларга ышанмыйча карый – 90 нчы еллардагы финанс пирамидаларын искә төшерә башлый. Барлык нечкәлекләргә тукталып тормыйча, челтәрле маркетингның финанс пирамидасыннан төп аермасын гына әйтәм, ул – реаль продукт, һәм максат – аны алга җибәрү. (Ә пирамидада керем яңа килгән клиентларның әгъзалык өчен түләү хисабына туплана.) Пирамидадан аермалы буларак, маркетинг – легаль. Ә уртак яклары – тегендә дә, монда да бизнеска яңа клиентлар табу. Күбрәк табу! Әлеге бизнеска кушылу өчен синдә кешеләрне ышандыру, күндерү һәм мотивацияләү сәләте булу шарт. Ул чакта, дөрестән дә, югары нәтиҗәләргә ирешү мөмкинлеге бар.

Тагын **СТОРИЗ-МЕЙКЕР** – махсус кыска видеолар төшерүче, **ТАРГЕТЛЫ РЕКЛАМА БУЕНЧА БЕЛГЕЧ, ОНЛАЙН-КОНСУЛЬТАНТ, БЛОГ ДИЗАЙНЕРЫ** кебек һөнәрләр дә бүген актуаль. Шундый профессия ияләрен эзләүчеләр сайтына язылган идем, атна саен почтама яңа вакансияләр килә – димәк, интернет-профессияләргә ихтыяҗ үсеп тора. Ә андый сайтлар интернетта бихисап.

Әйе, бүген интернет безгә әби-бабайлар, хәтта әти-әниләрнең төшенә дә кермәгән гаять зур мөмкинлекләр ача. Вакытың, теләгең һәм, әлбәттә, мөмкинлегеңнән чыгып, өйдә утырып кына да, теге 50 сум янына өстәп акча эшли аласың хәзер.

Танышларыбызның әле мәктәптә дә укымаган кызлары инде әнә: «Үскәч блогер булам», – дип сөйли, телефонына ниндидер видеолар төшереп уйный. Үзем дә яшь әни булганга, мине бер сорау борчый: бу хәлгә замана баласының мавыгуы дип кенә карарга)мы, әллә чаң суга башларгамы? Чөнки мәсьәләнең икенче ягы да бар бит.

Бүгенге көн балалары күптән инде космонавт булырга хыялланмый, алар тормышларын табиб яисә укытучы һөнәре белән бәйләргә дә атлыгып тормый. Соңгы елларда әти-әниләре шикелле юрист яки икътисадчы булырга теләүчеләр дә кими бара. Бүген Юрий Гагарин түгел, ә Юрий Дудь модада.

Ә бит кешеләрнең кайбер ихтыяҗлары мәңгелек булып кала бирә. Кемдер кием тегәргә, ипи пешерергә дә тиеш. Киләчәктә бу эшләрне кем башкарыр? Бәлки, сүзем бераз пафослы яңгырар, әмма балаларда эшкә һәм эшче профессияләргә дөрес мөнәсәбәт булдыру безнең буын алдында торган бурычларның берсенә әйләнер, мөгаен. Җиңел акча артыннан куучы түгел, ә аңлы һәм уйларга сәләтле буынны нәкь менә без тәрбияләргә тиеш.

ФОТОБӘЙГЕ:
«ОБЪЕКТИВТА – ӘНИ»



Фото: Екатерина Жданова. Париж.

«Объективта – әни» бәйгесе дәвам итә. Аның оештыручылары – «Сөембикә» журналы редакциясе һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы. Фотосурәтләрегезне 31 октябрьгә кадәр җибәрә аласыз.
Исегезгә төшерәбез: иң уңышлы дип тапкан эшләр журнал битләрендә дөнья күрәчәк, ә көзгә – Әниләр көнендә – Казанда, «Манеж» күргәзмәләр залында алардан күргәзмә оештырылачак.
Җиңүчеләрне планшет, кесә телефоны кебек кыйммәтле бүләкләр көтә.
Конкурсның нигезләмәсе һәм шартлары белән сайтыбыздан таныша аласыз: www.syuyumbike.ru.

PRESSA

Ярты сүз дә русча белмәгән 16 яшьлек Нуранияләре шахтага чыгып киткәндә Гайфулла абый белән Сәрвәрҗиһан апаның йөрәге парә-парә телгәләнгәндер.



Лилия ГӘРӘЕВА



ШАХТЕР НУРАНИЯ

Китә җаныем,
китә җаныем,
Китә җаныем Донбасска...

«Нәбиулла Донбасска киткән икән. Шахтада эшләгәнгә, аталарына налог өчен льгота биргәннәр», – ди әткәй беркөнне. Үзе кулындагы салым кәгазьләренә карап еламый гына. Ите, сөте, мае, йомыркасыннан тыш, тагын 700 сум түләргә дип язганнар. Авыл кешесенең каян аның кадәр акчасы булсын соң инде?» – 86 яшьлек Нурания апа бармак очлары белән генә күзләренә кагылып ала, ул еллар күптән үтсә дә, әрнүләре һаман җанында әле.

«Шахтага китеп эшләсәм, әткәемне бу түләүләрдән коткарыр идем инде... Эх, ничек кенә барасы икән соң ул шахта дигән җирләргә?» – уналтысы яңа тулган кызның бар хыялы әнә шул хәзер. Аларның Урман Тәвелдесеннән дә шахтада эшләүчеләр бар үзе, ләкин берьялгызың гына чыгып китү куркыта шул. Аннан соң... кем әле сине колхоздан җибәрсен, ди, каядыр китәр өчен паспорт кирәк.

Алай да, хыялы тормышка аша бит Нуранияның. Шахтада эшләүче авылдашлары кунакка кайтып төшә берзаман. Инде колхоз рәисен генә ризалатасы кала, ничек тә белешмә язып бирсен инде ул, җибәрсен кызны шахтага. Аннан башка да әти-әнисенә биш бала бит, аларны үстерешергә дә булышыр иде...

Хәтирә һәм Оркыя апаларына ияреп, гыйнварның өздергән суык бер көнендә Себер якларына китеп бара әнә Нурания. Игътибар белән тыңласаң, поезд тәгәрмәчләренең тавышы ул яраткан «Шахта көе» белән охшаш икән лә. Тик аларның Донбасска түгел, Кузбасска юл тотулары. Хәтерли әле, дәресне тыңлап утырмаган өчен укытучы апасы әрләгән иде аны. «Сезнең ул Кузбассыгыз миңа ниемә? Анда барып яшисем бармы?» – дигән иде ул шул чагында. Хәзер менә шунда китеп барышы.

«Абау, 16 гына яшьмени? Юк, юк, нинди шахта ди әле сиңа?!» Инде ничә тапкыр шулай дип боралар да чыгаралар, боралар да чыгаралар

Нуранияне идарәдән. Аптырагач, хастаханәгә йөк ташучы булып урнаша. Ләкин аңа ничек итеп булса да шахтага төшәргә кирәк, әтисе анда белешмә көтеп калды бит. Әле ярый беркөн Оркыя апасы урамда Кайбыч кешесен очрата. «Күчтәнәчегез булса, урнаштырып була ул», – дип өметләндерә тегесе.

Шахталарга син төшәрсең, Җырлап күмер кисәрсең...

Җир астындагы беренче көнен бер дә онытасы юк: башына каска, аягына чүни (кунычлы галош), өстенә телогрейка бирделәр. Каскага фонарь да эләсе икән. Янбашында – противогаз... Октябрьнең унысы булуы да хәтерендә. «Шахтага төштем дә, каранып йөрим. Берәрсе очраса, справка сорарга ниятем. Очрады бит берәү, кем булгандыр инде ул, бер гади шахтердыр инде. «Миңа справка кирәк», – дим. «Какая справка?» – ди бу, урысчалатып. Ә мин урысча белмим. «Для льготы что ли?» – дигәч, и куанганнарым: «Әйе, әйе, льгота өчен!» Ул кеше каян аласын өйрәтеп җибәргәндер инде, тәки кулга төшердем бит мин ул кадерле кәгазьне. Шул көнне үк почтага барып, әткәйләргә хат белән салдым. Әткәй инде салым акчасын түләгән булган, алай да шушы белешмә аркасында яртысын кире кайтарып биргәннәр. Шулкадәр куанганнар бичаракайларым».

Прокопьевск шахталарында сигез ел эшли Нурания апа. Күмерен дә чаба, вагонеткаларны да этә. Беренче мәлләрдә «осланцевание» хезмәтен башкарырга туры килә аңа: метан газы шартламасын өчен сланец тузаны сибә, шахтаны җилләттерә... Бер еллап эшләп, инде тәҗрибә дә туплагач, шартлатучы итеп алалар. «Шахтадагы күмерне бораулап керәсең дә, шунда капсулалар куеп, шнурлар белән тоташтырып, шартлатасың. Аяк астында җир тетри, шахталар гүләп тора. Яшьлек белән куркуны да белмәгәнмен. Бик яратып эшләдем». Шартлатучы эше – җаваплылык һәм тәҗрибә сорый торган хезмәт. 16 гына яшьлек булуын белгәч, эштән дә чыгармакчы булалар үзен. Аны якларга бөтен бригада куба: «Эшен бик белеп башкара, тимәгез, калсын».

Шахта – куркыныч җир. Анда ишелгән, монда таш баскан... «Берсендә шулай күмер шартлатырга дип асылмалы трапка менгән идем, тотынды өстән таш ишелергә. Трапта асылынган килеш, таш яңгыры астында калдым. Өстән кычкыралар: "Аннушка, ты жива?" «Жива, жива», – дим, баштагы каска саклап калды ул чакта. Таш ишелү туктагач, трапта тартып алдылар. Хәтәрлекләр күп иде, Аллаһы Тәгалә саклаган икән алай да, дим.

Бик үкенечлеләре дә булды. Өйрәнчек биргәннәр иде. Ул көнне ни сәбәпледер эшкә бераз соңгарак калдым. Мине көтеп тормаганнар, шартлатырга шул стажерны төшереп җибәргәннәр. Бик игътибар сорый торган эш бит, ә бу – яшь кенә кеше, капсулаларының барысының да шартлап бетүен тикшереп тормаган. Бер-икесе күмергә батырган килеш калган. Шулар соңыннан шартлап, бер шахтерның күзен чыгарган иде. Исемен оныткамын инде, Кырым татары булуын гына беләм. Берсендә кибеткә кердем дә, сөйләшеп торабыз. Бу кеше, тавышымнан танып, яныма килде, ике күзе дә дөм сукыр үзенең. «Ул көнне син булсаң, бу хәлгә калмый идем бит», – дип, мине кочаклап елады, бичарам».

Ни сорасам, шуны бирде язмыш. Миншәфыйкны күрүгә, миңа насыйп булсын, дигән идем. 47 ел яшәдек.

Минем җаныем шахталарда Күмер чабадыр инде...

Кешене ашар ризыгы белән эчәр суы йөртә, диләр. Никах вәгъдәсе дә йөртми микән инсаннарны чит туфракларда? Әлки районының Салман авылы егете Миншәфыйк белән Апас кызы Нурания шахтада очрашмасалар, тагын ничек табышырлар иде икән?

Дүрт ел яратышып йөреп, 1956 елны өйләнешә алар. «Бер күрүдә ошаттым, – дип серле елмаеп куя Нурания апа. – Кап-кара чәч, зәңгәр күз... «Эх, бу чибәр егет миңа насыйп булса иде», – дип теләдем



■ Татарстанда туып-үскән ике татар баласы Себер шахталарында очрашмаса, тагын кайда табышырлар иде икән?
Сулда: 16 яшьлек шахтер кыз. 1950 ел, 20 ноябрь.



■ Миншәфыйк Бәдертдинов. Кемерово өлкәсе, Прокопьевск шәһәре.

Фото: Анна Арахамия

PRESSA

Хәзер уйлыйм: яшь чакта бөтенләй куркуны белмәгәнмен икән. Балаларым да үзем кебек: тәвәккәлләр.

шул чакта. Тәки үземә язган икән. 47 ел яшәдек, кырык җиде көн кебек тә булмады...» 1999 елның җәендә, туган көнендә вафат була Миншәфыйк абый. Шунысына куанып бетә алмый Нурания апа: газизенең кабере туган якта. Себер якларында да, Уралда да бар хыяллары туган якта гомер кичерү була бит аларның. Хәер, 1958 елны кубарылып бер кайталар әле. 1957 елда СССР Министрлар Советының «Хатын-кызларның шахтада авыр эш башкаруын тыю турында»гы указы чыккач, Нурания апаны да эштән кыскарталар. Менә шул чакта Прокопьевскидагы йортларын сатып, уллары Әсгатьне җитәклиләр дә... Әмма җыяр ризыклары тагын чит якларда була, күрәсең. Миншәфыйк абыйның чиреннән ылыслы һава булыша, дигәч, Уралга кузгалалар.

Буланаш бистәсе меңьяшәр наратлар шаулаган кап-кара тайгага терәлеп утыра. Шушында уллары Әдип белән кызлары Асия дөньяга килә. Аларның туу шатлыгын да, Әсгатьләрен югалту хәсрәтен дә шушында кичерә алар. Буланаш урамнарын бер итеп йөгереп йөргән 9 яшьлек малайга кинәт кенә нидер була. «Стресстан», – диячәк табиблар соңыннан. Бер-бер артлы җиде баласын җирли ул җәйне Буланаш халкы. «Берсеннән-берсе матур, тупырдап торган балалар иде. Ничек җир кабул итте икән аларны, дим. Җидесендә дә лейкоз таптылар», – елап җибәрмәс өчен, чытырдатып күзен йома ана. Улларының гына түгел, кайната-кайнаналарының да соңгы йорты шушында – алар 26 ел гомер иткән Урал якларында.

Миншәфыйк абыйның сәламәтлеге инде шахталарга төшәрлек булмый, тормыш дилбегәсен үз кулына алырга туры килә Нурания апага. «Уралмаш»ның Артемовский заводына токарь булып урнаша ул. Шунда алган яралары кулларында бүген дә беленә әле. «Бораулау установкалары өчен детальләр кыра идек. Станок ватыла да, кыра торган деталең кулыңнан ычкынып китеп, берәр җиреңә китереп бәрә. Куллар киселүгә артык хафаланмыйсың да, иң мөһиме – күз исән дип куанасың», – дип искә ала ул чакларны героиням. Сүзгә балалары да кушыла: «Әнине атналар буе күрми идек», – ди кызы Асия ханым Нигъмәтуллина. Бүген ул инде үзе дә ике бала анасы. «3 нче икмәк заводы»нда «ОТК һәм лаборатория» мөдире булып эшли. – Әни киткәндә әле йокыдан да тормаган булабыз, ул кайтканчы тагын йокыга китәбез. Без күбрәк әти белән идек, бакчага да ул илтте, дәресләрне дә ул әзерләште... Бигрәк бала җанлы, гаилә җанлы кеше иде ул. «Әниегез кайтышка бәрәңге булса да пешерегез, балалар», – ди иде. Уллары Әдип тә армиягә киткәнче ел ярымлап Буланаш шахталарында эшли әле.



■ «Иң рәхәт көннәрем картлыгыма калган икән», – ди Нурания апа. Ике баласына дүрт оныгы, дүрт туруны бар аның. Әле бүген дә уразасын, намазын калдырмый ул.

Бик сагынсаң, бик саргайсаң, Йөрәккәең тынмаса...

Арча районының Кәче авылы – Бәдертдиновлар гаиләсенең өченче тукталышы. Чын бәхетнең туган якта гына була алуын монда кайткач аңлый алар. Урамга чыксаң – үзеңнекеләр, кибеткә керсәң – туган телең... Кайчандыр Миншәфыйк абыйның буп-буш кырга утырткан шомырт-миләшләре, чыршы-наратлары инде күптән буй үстергән. Шушы чыршыларга аларның үз гомерләрендә өченче тапкыр җиткергән иркен йортлары сыенган.

Килене Фирдинә һәм улы Әдип гаиләсендә бик бәхетле картлык кичерә Нурания апа. «Ул миңа әни урынына да, әти урынына да булды. Әле дә аның сүзе, аның киңәше белән яшибез, – ди Фирдинә кайнанасын хөрмәт белән олылап. – Балалар үстергәндә әле ярый ул булган, дим. Дефицит заманы иде бит. Әни тота да Мәскәүгә чыгып китә. Әйберне берәмтекләп ала белми иде ул, төргәге белән генә ала. Ә иң яратканы – бакча эшләре. Әле дә чыгып эшләр иде, үзебез генә тыябыз. Әзлегерсең, дибез».

Бу нигездә өч буын килен тату гомер итә. «И балалар, татулыкка ни җитә соң!» – шахтер әбинең гел әйтә торган сүзләре бу.

Чиста сулы тылсымлы коега тиңләр идем Әбекәйне: ярату-шәфкать хисе һич кимеми. Безгә ул әтине алыштырды. Ә аның үзен алмаштырырдай беркем юк дөньяда. Ул – бердәнбер!



Айгөл
КАСЫЙМОВА

«ЗУРЙӨРӘК»

«Һәммәбездән олы ул, өебезнең нуры ул, тәмле ашлар пешерә, бөтен эшкә өлгерә!» Безнең әбекәй ич бу, дисәгез, гаҗәпләнмим. Бу шигъри юлларны кем генә ятламаган да, янына кояш, чәчкә рәсеме ясап әбисенә бүләк итмәгән?!

Иң әйбәте – нурлы йөзле, шәфкатьле-миһербанлы, ягымлысы – безнең әби диюегезгә ышанам. Күңеле киң, сүзе тәмле, шуңа күрә якын, кадерле алар безгә. Әбисе белән үскән бала үзгәрәк: нечкә күңелле, хыялыйрак була диюләре хак.

Әбекәй диюгә минем дә күз алдымнан дәү әни сөйләгән тылсымлы әкиятләр йөгереп үтә. Икәүләп хәстәрләгән мул табыннар, чигү-тегүгә өйрәнгәнем истә. Хәтер төпкелендә истәлек, хатирәләр байтак сакланган. Һәр эшебезгә чын күңелдән сөенгән, ихлас яраткан, авырсак жәлләгән, шифалы үләннәр белән дәвалаган тагын кем бар? Әти, әни, апа-абый... дип санап китсәк кенә инде.

Ә без әтисез үстек. Бәла көтмәгәндә килә: абыемны юл читендә машина бәрә. Аңа – 6, игезәк туганым Алсу белән миңа 3 әр яшь була. Баш сөяге чәрдәкләнгән, аягы сынган, паралич суккан сабыен аякка бастыру өмете белән әниебез хастаханә, тернәкләндерү үзәкләреннән атна-айлар буе кайтып кермәде дисәк тә була. Ә әти... әти яңа яр тапты – безне ташлап чыгып китте. Гаепләвем түгел, үз хатасы, ялгышы өчен һәркем үзе җавап тотачак. Таяныч-терәксез калган әни авыру бала багарлык, өч ятимне тәрбияләрлек көч, егәр, ризык каян табар иде, дигән сорауны үземә бер генә бирмәгәнмендер. Әгәр әнинең әнисе – Әбекәй булмаса, кая тәгәрәр иде язмыш йомгагы – белгән юк. Сынауларга түзми ир-ат сынганда да, бирешми, сабыйларын яклап утка керә, таш стена – терәк булып баса алган берәү – ул бар әле ярый дип, шөкер итеп яшәдекме? Әллә шулай тиеш дип белдекме? Аны соң кем уйлап торган, көн дә ризык кирәк, кием, җан җылысы! Бәбкәләрен канат астына җыеп җил-давылдан саклаган ана каздай сыендырырга, ярый, ул булган! Югыйсә үзе дә күргән... Әниебезгә – 8, сеңлесенә 3 яшь чакта бабай вафат була. 33 тә тол калып, бер көн эштән калмый, кызларын үстерә. Аннан без... Әбекәй, батыр син, дисәм дә исе китми, тыйнак: «Гап-гади авыл кызы мин. Әлләкем түгел, үткенлегем дә чамалы, буйга да бәләкәй, – ди. – Йомшактыр, бер ханым җебегән, дип



тә «зурлады». Әрсезлек бирмәгән табигать аңа, көчле рух, игелек, мәрхәмәт белән бүләкләгән. Хезмәт төбе – хөрмәт, дип яшәгән. Безне дә гел баштан сыйпап, иркәләп-назлап кына тормады: «Алма пеш, авызга төш, дип яткан ялкау-хөрәсән булмагыз, эш мәне белми үсмәгез», – дип ачулана да иде. Беләм, кырыслыгы – тормыштан: акыл-тәрбия бирергә теләүдән.

«Үзең сөйләгән әкият герое «стойкий оловянный солдатик» кебек син! Әллә «Зурйөрәк» дигән кушамат тагыйммы, йөрәгең зур бит синең», – дисәм: «Әбекәй дисәң, шул җиткән», – ди. Иң яраткан сүзе – «Эшләгәнегез – минем өчен, өйрәнүегез – үзегезгә!» Мич ашы пешерә башласак: «Кулларың килешеп тора, бәлеш читен бөрерсең, яме», «пилмәннәрең матур, җыйнак», «токмачны нәзек, оста кисәсең», дип мактап-хәйләләп, салпы якка салам кыстырып эшләтә белә. Кем өйрәтә соң безне, дим. Балачакта караңгыда йокларга курка идем: кыен чакта Аллага сыен, дип, догалар өйрәтте. Караңгыдан курыкмыйм хәзер, дога шифалы булуга ышанам. Ә җәй көне бакчага бару маҗаралы сәяхәткә тиң! Гөлләр дә ярата аны. Бакчаны ямьләп нәрсис, лалә, чалмагөл, пәйгамбәр тырнагы гүя нур чәчеп тора. Үзенең исеме дә гөлчәчәк, оҗмах бакчасы дигәнне аңлата, шуңа җирдә казынудан тәм таба ул. Бергәләп эшләп арыгач, ипи, чәй дә ләззәтле, тәмлерәк икәнен каян белер идем, әгәр ияртеп бакчага йөртмәсә. Җирне, көнне яратыгыз дия-дия, үзен яраттырган Әбекәйгә Ходайдан мин озын гомер сорыйм.





Тышлыкта һәм язмадагы фотода Гөлсинә Галиуллина «Александр Богданов» бренды киемнәреннән.
Фото: Анна Арахамия



ЮЛЛАР КАЯ ИЛТӘ?

Кешенең гомере – олы бер юл аның. Кемнекедер ул туп-туры, кемнеңдер – бормалы. Янында ышанычлы, якын кешеләрең булса, юлың сизелми дә. Шуңа да һәркем дөньяга үз парын эзләп килә! Сайлаган юлдашың синең белән бер уйда булып, әйтәсе килгән сүзеңне күзләреңнән аңласа, читкә сукмаклар салмыйча, кулыңнан җитәкләгән килеш атласа, ярдәм итәргә торса, әллә нинди үрләргә дә күтәрелергә мөмкин. Ул яктан Гөлсинә ГАЛИУЛЛИНА бәхетле хатын. Янында – ышанычлы Айраты! Ансыз бүгенге тормышы болай матур булыр идеме?! Айраты хупламаса, туксанынчы елларда Түбән Камада беренче эшмәкәр булып китә алыр идеме...

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Яшьлек юлы

Ул еллардан соң 25 ел узган инде. Быел көмеш туйларын уздыралар. Ә күңел һаман да яшь. Гаиләдә гармония булса, хатын-кыз яшьлеген дә, матурлыгын да саклап кала ала-дыр. Бер-берсенә йомшак кына эндәшкән Галиуллиннар – бөтен Түбән Камада үрнәк татар гаиләсе. Гөлсинәнең иренә «әтисе» дип кенә эндәшүен күреп, башкалар да шулай дәшә Айратка. Әти кеше – гаилә башлыгы. Аларда ул – язылмаган канун. Менә инде чирек гасыр буе Айраты аның терәге, киңәшчесе. Капка төбендә танышкан кичтән соң инде күпме гомер узган. Бүгенге көнгә килеп җиткәнче нинди генә юллар аша үтмәде алар...

...Ибраһим абый белән Әлфия апаның төпчекләре – бишенче баласы Гөлсинә. Аны әнисе 39 яшендә таба. Үзеннән алда туган апасы белән яшь аермасы – 8 ел. Гөлсинә үсеп җиткәндә һәрберсе гаиләле була инде. Кыз үз юлын үзе яра. Мәктәпне тәмамлагач та, монда барып укы, бу шәһәргә бар, дип киңәш бирүче булмый аңа. Өч дус кыз – Лилия, Миләүшә һәм Гөлсинә яңа төзелгән шәһәр – Чаллыга юл тота. Әти-әнисе дә каршы килми. (Гомумән, авылда алар хакында үзләре институт тәмамламасалар да, балаларын дөрес юл сайларга өйрәткәннәр, тиешле тәрбия биргәннәр дип сөйлиләр.) Кызлар сәүдә-кулинария училищесына укырга керә. Бер урында тик торырга яратмаган Гөлсинәне тиз күреп алалар. Җәмәгать эшләре йөклиләр: төркем старостасы, училище, тулай торак советы әгъзасы... Училищега укырга кергән елны ноябрь бәйрәмнәренә авылга кайталар. Өч дус кыз кичен клубка чыга. Керүгә үк өч кунак егетенә игътибар итми калмыйлар, әлбәттә. Егетләрнең дә аларга күзе төшә. Кич буе биеп, кайтыр юлга чыккач, кунак егетләре кызлар артыннан иярә. Бераз баргач, кызларның юллары аерыла. Егетләрнеке дә. Гөлсинә Айрат белән капка төбендә генә таныша. Шул кичтән соң Түбән Кама егете кыздан бер адым да калмый. Башта Чаллы юлын таптый, аннан – Әлмәтнекен, чөнки училищены кызыл дипломга тәмамлаган Гөлсинә, остазлары киңәшен тотып, Әлмәткә китә. Абруйлы сәүдә техникумына укырга керә. Нефтьчеләр шәһәренә ялгызы гына киткән Гөлсинәнең тулай торакта моңсуланып утыруын теләмәгән, үзе дә сагынуына түзә алмаган Айрат Әлмәт юлына тузан кундырмый. Читләр күз салудан курыкмый анысы. Чарасын күрә.

– Яшьлек бит инде... Укыган вакытта кызлар белән дискотекаларга йөри идек. Кызлар артыннан егетләр килә, ә минем арттан – юк... Шуңа бик аптырый идем. Еллар үткәч кенә белдем. Баксаң, Айрат, егетләр белән танышып, минем кем белән дус булуымны танытып куйган. Әнә шулай, беркемне дә якын китертмәде ул миңа. Бик куркыныч заманнар иде бит әле. Урам төркемнәре, шәһәр шәһәрне яратмый. Айрат та кайчак минем янга бер төркем дус егетләре белән генә килә иде, – дип сөйли Гөлсинә яшьлек хатирәләрен яңартып.

Гөлсинә институтта белем ала башлагач, Айратның юл йөрүләре тукталган кебек була. Кыз Түбән Камада ачылган икътисад, идарә һәм хокук институтына читтән торып укырга керә. Айраты да монда, Шәмсегөл апасы да гаиләсе белән шушы шәһәрдә төпләнгән. Җизнәсе «Түбән Кама Нефтехим»ның ярдәмче хуҗалыгына эшкә урнашырга ярдәм итә Гөлсинәгә. Кечкенә генә кибеттә сатучы була ул. Завод эшчеләренә көненә әллә ничә тонна ит сата. Эштән соң да калып эшли. Эшчеләргә генә түгел, Түбән Каманың башка халкына да хезмәт күрсәтә. Бөтенесен тигезлисе, беркемне дә үпкәләтәсе килми аның. Талон күтәреп килгән (90 нчы еллардагы талон заманын беркем дә онытa алмас!) берәүне дә кире борып җибәрми.

Эшмәкәрлеккә юл

Яшьли сөйгән ярлар алты ел очрашып йөргәннән соң, ниһаять, өйләнешә. Айратның әти-әниләре үзләре яшәгән йорттан фатир алып бирсәләр дә, яшьләр күченергә ашыкмый. Ике бүлмәле фатирда бергәләп яшәгән чакларын әле дә сагынып искә ала ул. Әти-әнисенә (кайната-кайнана дип ялгышып та сөйләми алар хакында!) рәхмәте зур аның. Уллары Айдарны да күкрәк баласы чагыннан ук әнисе караша. Яшьләр, тормыш йөгенә җигелеп, киләчәккә юл яра башлый. Ә ул аларның туксанынчы еллар башына

«Нинди генә зур эш башкарсак та, «мин», дип яшәү хатын-кызларны бизәми», – ди Гөлсинә.

туры килә. Демократия, үзгәртеп кору җилләре халык өчен иркенлек алып килә килүен, тик... аның артыннан башкалары да иярә: кыскартулар, яртышар ел хезмәт хакы алмаулар... Укымышлы, зыялы кешеләрне дә чарасызлыктан базарга чыгарып бастырган вакытлар бу. Менә шул елларда кемнәрдер язмышка үпкәләп, зарланып яшәүдән ары китә алмый. Ә тәвәккәлләргә исә юл ачыла. Казан төзелеш институтын кызыл дипломга тәмамлап, Алабугада эшләгән Миңнегөл апасы, хезмәт хакы түләми башлагач, ни чарадан бичара булып, челноклар сафына басу идеясен әйтә. Гөлсинә бу тәкъдимне күтәреп ала. Айраты да каршы төшми. Бөтен булган акчаны җыештырып, хатынына тоттыра. Дөрес әйтмәдем, Төркиягә җитәкләшеп чыгып китәләр. Гөлсинәнең ике апасы да ирләре белән юлга кузгала.

Истанбулга килеп төшәләр дә, шаккаталар: монда киштәләр сыгылып тора, күзләр камаша... Киемсалым да, тукыма да, пәрдәлекләр дә җыялар. Алып кайтуын алып кайталар, инде товарны ничек сатарга? Беренче эш итеп, икеләнә-икеләнә генә, шәхси эшмәкәр булып Гөлсинә теркәлә. Түбән Кама зур түгел, халык бер-берсен белә. Базарга чыгып басарга кыенсына Гөлсинә. Кеше танып алса оятын кая куярсың! Айрат белән уйлашалар да, тагын юлга кузгалалар. Товарларын төяп, Чистай базарына чыгып китәләр. Бу базарда заманында әбисе шәл саткан. Балык Бистәсенең Котлы Бөкәш авылы кешеләре – танылган шәлчеләр. Гөлсинә дә кечкенәдән үк өйрәнә бу эшкә. Студент чагында ук шәл бәйләп сата башлый. Күрәсең, эшмәкәрлек аның канында була.

Икенче юлы Төркиягә ирләрсез генә китеп баралар. Бу юлы инде күз төшкән бөтен товарны җыймыйлар. Белеп баралар: челтәр-пәрдәләр алачаклар. (Илдә-көндә ни генә булса да, һәр хатын-кызның кулыннан килгәнчә өен ямьлисе килә.) Пәрдәләр сатучы сәүдәгәр Айхан белән танышалар. Гел аннан гына сатып ала башлыйлар. Берничә тапкыр зур йөкләрен үзләре күтәреп кайта әле алар. Челнокларның төп атрибутикасы булган шакмаклы олы сумкаларны шул вакыттан ук яратмый Гөлсинә. Сәүдә транспорты хезмәте барлыкка килгәч, эш бөтенләй җиңеләя. Сәүдә гөрли! Ял көннәрендә Айрат белән Чистай базарында саталар (төп эш урынын да ташламый әле). Сәүдәне туктатырга ярамый, Айдарын әнисенә ышанып тапшыра да, тагын Төркиягә чыгып китә. Әле улын күкрәктән дә аермаган килеш. Товар җыеп, базарда йөргәндә күкрәккә сөт төшеп тула. Тиз генә кунакханәгә кайтып сава да, тагын базарга чыгып китә. Әйе, төрле чаклар була. Әмма эшләргә кирәк – артка юл юк. Гөлсинә, эшеннән китеп, бары тик эшмәкәрлек белән генә шөгыльләнә башлый. Түбән Кама белән Чистай арасындагы юлның һәр сикәлтәсен хәтерли ул. Кечкенә «Ока»сына ике төргәк пәрдә сыя. Ире машина тәгәрмәче алыштырырга өйрәтә. Ул юлларда хәтсез алыштыра ул аларны. (Түбән Камада беренче эшмәкәр генә түгел, беренче машина йөртүче хатын-кыз да әле ул!)

Биналарны арендага бирә башлагач кына сәүдәсен Түбән Камага күчерә Гөлсинә. Берничә сату ноктасы ача: челтәр-пәрдәләрне Төркиядәге кебек матур итеп элеп куеп сата башлый. Апалары белән Төркиягә айга ике тапкыр йөриләр. Инде җаен белеп бетерәләр – туры фабрикага баралар. Югалтуларсыз гына булмый, билгеле. 2000 елда зур суммага сатып алган товары юлда югала. Транспорт компаниясеннән акча даулап йөрми, хәер, алай эшли белми дә ул. Әлеге проблемага фәлсәфи күзлектән генә карый: чыгасы акчалар булган. Әлегә кадәр фәлсәфәсе шундый аның: исән-сау гына булыйк, эшләрбез дә табарбыз!

Йортларны өлешкә кереп төзи башлагач, үз кибет бинасы турында уйлана башлый Гөлсинә һәм хыялын тормышка ашыра. 2004 елда портьерлар салоны ача. Һәм әлегә кадәр аның сәүдәсе адресын үзгәртми. Чит илләрдәге сәүдәгәрләр кебек, кибете урнашкан йорттан ук зур фатир да алалар. Сатып кына калмыйлар, челтәр-пәрдәләрне инде тегеп тә бирәләр салонда. Шунда ук тегү цехы ача Гөлсинә. Үзенә хезмәткәрләр эзләп, колледжга бара. Мастерлардан яхшы билгеләргә укыган кызларны үзенә практика узарга җибәрүне сорый. «Мин аларга түлиячәкмен», – ди. Кызлардан бары туры җөй тегә белүләрен генә таләп итә. Технологиясен үзе өйрәтә. Пәрдә тегү өчен сызымнар алып кайтып, өлгеләрен дә ясый. Тегүчелек сәләте тумыштандыр, күрәсең. Гөлсинә кечкенәдән үк бөреп-бөреп, кровать япмалары тегә. Студент чакта да пиджак-күлмәкләр тегеп кия. Әнисенең тегү машинасы – хәзер дә өенең түрендә.

Юлын белгән адашмас

Үзгәртеп кору елларында илнең икътисадын үстерүгә зур өлешләрен керткән «челноклар» чоры инде үтте. Авырлыклар аша узып та бирешмәгәннәре – бүген мәртәбәле эшмәкәрләр. Гөлсинә дә дөньяның төрле почмакларына күргәзмәләргә йөри. Хәзер Төркия җитештерүчеләре үзләре килә аңа. Сату-алуда кагыйдәләрне хәзер ул куя. 24 ел буе бер өлкәдә эшмәкәр булу эре заказчиклар алдында да дәрәҗәсен күтәрә Гөлсинәнең Хәер, ул үзе дә элекке кебек куркып-оялып кына сөйләшкән эшмәкәр түгел инде. Эшеңне яратсаң, тәҗрибәң бар икән, үзеңә ышаныч туа ул. Хәзер Гөлсинәнең һәр көннең ямен табып, бәхетен тоеп яшәгән вакыты. Акча дип тормыш куган чаклар артта калды. Күңел өчен, эштән тәм табып эшли ул. Тегелгән матур пәрдәләрдән клиентлары гына түгел, үзе дә канәгать калырга тиеш.

Гаиләсе – терәге бар. Үз кибетен ачканнан соң дөньяга килгән кызы – Азалия дә алтынчы сыйныфны тәмамлый. Уллары КФУда икътисадчы белгечлеген ала. Балаларын назга төреп үстерә Гөлсинә, бигрәк тә улын. Сере бик гади: өйләнгәч, хатынына ягымлы булсын өчен. Зирәк хатын аңа нәкъ шундый мөнәсәбәт белән җавап бирәчәк. Бер-беренә ягымлы булу – гаиләдә тынычлык чыганагы ул. «Кияүгә чыгарга бервакытта да соң түгел, ә менә бала табарга соңарырга мөмкинсең. Балаларны бер-бер артлы табыгыз», – дип киңәш бирә ул якын-тирәдәгеләргә. Яши-яши генә аңлыйсың икән: дөньяда иң кыйммәтлесе – гаилә. Оя таркалса, яшәү яме югала. Утны-суны кичкән, бүгенге көндә аягында нык басып торган эшмәкәр Гөлсинәнең күңеле тулы наз. Ире аның өчен әле дә 25 ел элек капка төбендә сөйләшеп басып торган серле кунак егете. Наз да, мәхәббәт тә, дәрт тә сүнмәгән. Киресенчә, көчәйгән генә бугай.

– Барысын да үзем булдырам, акча табам, миңа ир нигә дип яшәүчеләрне, гомумән, аңламыйм, – ди Гөлсинә ханым. – Һәр хатын-кыз янында ир-ат булырга тиеш. Нәрсә генә булса да, гүзәл затка иң элек үзенең оясын кайгырту мөһим. Хатын-кыз зирәк булмый икән, ир күпме генә акча эшләмәсен, аның бәрәкәте булмаячак. Ирләрне үсендереп тору да – безнең төп бурыч.

Аларның гаиләсендә ике эшмәкәр. Иренең дә үз бизнесы. Түбән Кама «Нефтехим»да эшләгән Айрат кыскартылуга эләгә. Төрле эштә эшли ул: күп катлы йортлар да буйый, шофер да була. Сәүдә эшен алып барган Гөлсинә ул вакытларда да ирен үсендерә. Бәлки, хатынының теләктәшлек белдерүе, аңа ышанып каравы Айратка үз эшен башлап җибәрергә ярдәм иткәндер.

– Ирем берни эшли белми, акча тапмый, дигәннәрдән мин: «Ә иreң тырышсын өчен үзең ни булса да эшлисеңме соң?» – дип сорыйм. Булдыксыз дип әйтәсең икән, син аның бәясен генә төшерәсең. Ә үз бәясен белмәгән кешеләр бу дөньяда берничә ирешә алмый! Шуңа күрә белмәгәнен дә, ирем эшли, булдыра, дип сөйләргә кирәк читләргә.

Балаларның башлы-күзле булыр вакытлары да килеп җиткән. Кайнанасының: «Айратның синең белән дуслашып йөргәнен белгәч, бик куандым», – дигән сүзләренең мәгънәсенә хәзер генә төшенә ул. Булачак килененең бөтен нәселнәсәбен белгән ул, шуңа шатланган. Ә хәзер яшьләрнең аралашу мохите бик киң. Нинди кешегә насыйп булырлар бит. Гомерлек ярларын дөрес сайласыннар иде дә соң... Гаиләдә алар татарча гына сөйләшәләр. Милли традицияләрне, гореф-гадәтләрне саклыйлар. Милләт җанлы Гөлсинәнең «Ак калфак» иҗтимагый оешмасының Түбән Камадагы бүлеген җитәкләргә алынуы да – изге максатлардан. Тормышында җыелган тәҗрибәне башкалар белән уртаклашасы килә аның. Татар яшьләре тамырларын онытмасын иде. Шәһәрдә генә түгел, якын-тирә татар авылларында да оешмаларын булдыралар. Милли традицияләрне саклап калуны балалар бакчасыннан ук башлыйлар. Сабыйлар өчен кичке уеннар оештыралар. Балачакта, әнисенә ияреп кич утырырга йөргәннәрен хәзер дә онытмый Гөлсинә. Ул вакыттагы өлкәннәрнең зирәклегенә торып-торып соклана ул. Кич утырырга алып йөреп, балаларын үзләренә дә якынайтканнар, аларны эшкә дә өйрәткәннәр бит. Эш – иң яхшы тәрбия алымы. Эшләп үскәннәр тырыш була. Ә тырышлык – тормыш тәгәрмәче. Моны Гөлсинә белә!

«Түбән Кама хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасына чакыргач та рәхәтләнеп ризалаша. Аларның изге эшләрен күптән ишетеп белә. Үзе дә ул үстергән Гөлсинә күңеленә «Солдатка – әни пирогы» акцияләре бигрәк якын. Автобусларга утырып, Түбән Кама егетләре хезмәт иткән хәрби частьларга чыгып китәләр. Солдатлар янына әниләрен, тәмле итеп пешерелгән өй ашларын алып баралар. Аларның күңелләрен күтәреп, бераз булса да сагынуларын басып, артистлар белән барып, концерт куеп кайталар.

Үзләре үткәргән «Авыл хуҗабикәсе» бәйгесенә баладай сөенә ул. Гөлсинә белә: авыл хатын-кызлары бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр һәрвакыт эштә, бәйрәм итәргә вакытлары юк. Ә бу бәйге алар өчен Сабантуй кебек. Көтеп торалар! Рәхәтләнеп күңел ачалар.

Менә шулай, җәмәгать эшләрендә кайнап, бизнестагы мәсьәләләрне хәл итеп бетергәч, ялга гаиләсе белән бакчаларына китә Галиуллиннар. Матур күл буенда урнашкан ул. Иртән торып, каһвә эчә-эчә веранда тәрәзәсеннән су өстен күзәтергә ярата Гөлсинә. Күл өсте кебек үк, күңеле дә тыныч. Менә кайда алып килгән бит аларны гомер юллары – парлы бәхетле тыныч тормышка.



Дизайнер
Александр
БОГДАНОВның
тормыш кагыйдәләре





ALEXANDER BOGDANOV
Казан, «SUVAR PLAZA», 1 нче кат
тел: 8 (843) 267 17 37
alexanderbogdanov.com

УҢЫШ СИНЕН ҮЗЕҢНӘН ГЕНӘ ТОРА

БӨТЕН ЗУР ӘЙБЕР ГАДИДӘН БАШЛАНА. Минем өчен ул 1988 елда апамның бәйләү машинасыннан башланды. Берчак аның төрле төстәге матур фактуралы бик күп бәйләм йомгакларын күреп алдым да, башка бер шәп идея килде. Йомгакларны төсле буяуларга манып, төрле әйберләр бәйләсәңме?!. Ул елларда бөтен нәрсә дефицит иде бит. Әйтик, мохер җепләр табар өчен, Алтайга барып бартер ясарга туры килде: мин бер әйбер бирәм, алар – икенчене. Аннары әбием кулдан җеп эрләде, ә мин шуларны төрле төсләргә мандым. Хәзер генә ул бар да бар, дөньяның теләсә кайсы җитештерүчесе безнең белән эшләргә әзер, фабрикалар сиңа кирәк төскә буяп бирә...

Бәхет гел елмаймый. **УҢЫШ – БӘХЕТТӘН БИГРӘК, ЗУР ХЕЗМӘТ УЛ**. Һәм ул җиңел генә килми. Тырышлык куйсаң, үз эшеңне башкаларныкыннан яхшырак башкарсаң, тормышта күп нәрсәгә ирешергә мөмкин, минемчә. Әйе, күтәрелүләр дә, түбән тәгәрәүләр дә булачак анысы – бу котылгысыз. Ләкин туктап калырга ярамый. Дөрес нәтиҗәләр ясыйсың, көчеңне чамалыйсың, дистанцияне күзаллыйсың һәм юлыңны дәвам итәсең.

СӘНГАТЬ, САННАР ҺӘМ САЛКЫН ИСӘП АРАСЫНДА БАЛАНС САКЛАУНЫҢ ӘЗЕР РЕЦЕПТЫ ЮК. Миңа һәрчак ике әйбер ошый иде: үз кулың белән нидер ясау һәм коммерциягә тәвәккәллек. Нәрсәдер иҗат итеп, базарның шуңа реакциясен күзәтү кызык бит. Шуны аңладым: уңыш бары тик синең үзеңнән генә тора.

Мин картиналар ясарга яратам. Берара моңа гел вакытым җитми иде. Хәзер кабат сынлы сәнгать дөньясына кайттым. Рәсемнәремдә – пастель, акварель буяулар, соңгы вакытта акрил техникасы белән мавыга башладым. Һәртөрле сызымнар, төзү эшләре, кием дизайны – болар барысы да минеке. Йолдызнамә буенча су билгесе булгангадыр: суда сәяхәт итәргә яратам. Тынычландыра, рәхәтлек бирә. **КАЙСЫ ИҖАТ КЕШЕСЕ ДРАЙВ, АДРЕНАЛИНСЫЗ ТОРА АЛСЫН!** Чын ир-атлар хоббие уяна шул чакта: ауга чыгып китәм.

Мин, гадәттә, киемнәр коллекциясенә багышланган урыннарда фотосессия уздырам. Масштаблы проектлар эшләр өчен бөтен иҗат төркемен шунда алып китәм. **ХАТЫН-КЫЗ НӘКЪ ШУЛ УРЫНДА СИН КҮЗАЛЛАГАН КИЕМНӘРДӘН БУЛСА, ЭМОЦИЯ ҺӘМ ЭФФЕКТНЫҢ КӨЧӘЯСЕН ДИЗАЙНЕР БӨТЕН БАРЛЫГЫ БЕЛӘН ТОЯ.** Соңгы ике коллекция, мәсәлән, Италиядәге Ломбардиягә һәм Лигуриягә мәхәббәт одасын җырлый. 2020 елның көзге-кышкы һәм язгы-җәйге сезоннары өчен лукбукларны Франциядә төшерәчәкбез.

МИҢА ХАТЫН-КЫЗ КИЕМНӘРЕН ИҖАТ ИТҮ ОШЫЙ. Ирләр коллекциясе турында да уйланганым бар, ләкин хатын-кыз образы өчен коллекцияләрем дә тулысынча ачылып бетмәгән. Бизнес ягыннан караганда, халыкара базарны ныклап торып өйрәнәсем бар. Россия базары безнең өчен тар инде, Европаны яулаганнан соң, Америка һәм Кытайны сынап карыйсыбыз килә. Аннары инде ир-атлар линиясе турында уйлансаң да була.

ХАТЫН-КЫЗГА НИНДИ КИЕМНӘР КИЛЕШКӘНЕН АҢЛАРГА МУЗАМ – ХАТЫНЫМ БУЛЫША. Аның фикеренә колак салам, күп әйберне аңарда сынап карыйм. Ул бик сизгер, маркам героинясына хас барлык сыйфатларга ия.

Кая җыенуыма карап, киенү стилен үзгәртәм. Берәр чарага барырга кирәк булса, мин классик стильне сайлыйм. **ҺӘР КИЕМДӘ ДИЗАЙНЕР ИДЕЯСЕ ЧАГЫЛЫРГА ТИЕШ!** Образда кэжуал элементын һәм спорт стилен рәхәтләнеп кулланам. Чаманы гына узып китмәсен, мин нәзберек дизайн тарафдары. Чамасызлык һәм эпатаж – минеке түгел.

СӘЯХӘТЛӘР – МИНЕМ ӨЧЕН ИЛҺАМ ЧЫГАНАГЫ. Башка илләрнең мәдәнияте, гореф-гадәтләре белән танышып, һәр сәфәремнән энергия алып кайтырга тырышам. Аннары киемнәр аша шул эмоцияләрне җиткерәм. Ул хисләр әйтерсең бренд белән бергә сәяхәт итә. Безнең фирма кибетләренә керсәгез, мине нәрсә илһамландырганын күрерсез. Һәркайсының кабатланмас тарихы бар.


ФИРМА КИБЕТЛӘРЕ АЧЫЛУ ГАДӘТИ ҮСЕШ ПРОЦЕССЫН КҮРСӘТӘ. Алай да Мәскәү, Санкт-Петербург һәм башка шундый зур шәһәрләрдә Alexander Bogdanov салоннары күренә башлау зур вакыйгага тиң ул. Бүген безнең марка башкала шәһәрләренең барысында да булсын иде.

РАЦИОНАЛЬ НИГЕЗДӘ ҺӘРВАКЫТ БЕР ЭМОЦИОНАЛЬ ТӨСМЕР БАЛКЫП КИТСЕН. Юкса ул әйберне сатып аласы килми. Мин кызыклы әйберләр ябатам. Ләкин алар башка таләпләргә дә җавап бирерлек булырга тиеш: комфорт, күп функцияләрне үтәү, яхшы сыйфат... Дизайнер буларак кием образын тудырганда, әнә шул якларына да игътибар итәм. Гардеробымда да шундый кием эленеп торуын телим.

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

ДОГА





Гөлнур
ХӘСӘНШИНА

Раилнең ул көндәге халәтен күз алдына китерү авыр түгел. Читләр генәме, үз-үзе шаккатарлык хәл – «мәчет төзим» дисен әле! Әле кайчан гына Аллаһ йортының ишеге кайсы якка ачылганын да бөтенләй белмәгән кеше!

– Мин бу буш урында цехлар төзергә – үз эшемне ачарга җыендым. Токарьлык, агач эшкәртү эшенә тотынмакчы булган идем. Кәҗәләр дә үрчетергә иде исәбем. Цехка дигән материаллар да инде байтак алынган иде. Алар әле бүген дә ята – сатылып бетмәгән... Бер егет миңа бетон блоклар китерде. «Урыныгыз зур, иркен икән, монда нәрсә төзергә уйлыйсыз?» – ди. «Мәчет салам», – дим. Кайдан телемә килде, ничек әйттем бу сүзне – белмим! Үзем дә сизмәдем... «Ярый, андый ниятегез булып тотынсагыз, без дә булышырбыз», – ди бу. Аны озатып өйгә кердем дә уйга калдым. Мәчет төзим, дидем бит... Моңарчы күңелгә кергән уй түгел иде. Аллаhыдан ният алдым, димәк... «Кирәкми бернинди бизнесың. Җитмиме әллә сиңа?! Йортың, кәҗәң, тавыкларың бар», дигәндер... Тәвәккәлләдем. «Чынга аша торган эш икән – юлын күрсәтерсең, Ходаем», – дидем.

...Армиядән соң туган якларына әйләнеп кайтырга ашыкмый ул: диңгезче булып китә. Диңгезчелек буенча институтка укырга керә, югары белем ала. Ун елы диңгез-океаннар гизеп уза. Латин Америкасы, Аляска, Канада, Куба... Аларның балык тота торган траулеры барып чыккан һәм ул аяк баскан илләрнең кайберләре бу. Ә аннан туксанынчы еллар җитә. Илдә барысы да бутала... Әтисе авырып киткән Раилгә туган нигезгә кайтып төпләнергә туры килә. Төпчек балаларның язмышы шундый...

Төпләнә дидем дә... Дәрьялар чиксезлегенә ияләшкән сәйяр җанны, илгизәр күңелне коры җирдәге тар кысаларга сыйдыру бик җиңел түгел бит ул. Аныкы да сыймый... Янәшәгә шундый ук дуслар җыела... Ахыры... Әйе, начар тәмамлана. Утырталар... Әйе, аның тормышында мондый хәл дә була. («Туганнан туган абыем район башлыгы урынбасары булып эшли иде ул чакта. Алып кала ала иде. «Утырсын, бәлки, акылына килер», – дигән. Дөрес эшләгән...»)

Иреккә 2000 елны чыга ул. Гомер китабының бер өлешен шул чакта яба. Элеккеге дуслар белән бөтен элемтәләрне өзә. Йортлар төзи башлый. Казанда, Әлмәттә, Чаллыда... «Моңа кадәр тотынып эшләгән эшем түгел иде», – дисә дә, бабалары, әтисе балта остасы булган кешенең бу һөнәргә кулы, күңеле ятып торуы гаҗәпмени?!

Инде ничек итеп дингә килүе хакында.

– Эшлекле дусларым арасында мөселманнар да байтак иде. «Ә нигә син җомга намазына йөрмисең? Җомгага бөтен ир-атлар да барырга тиеш», – дип аларның да әйткәләгәне булды. Ә аннан бер муллага йорт төзетергә туры килде. Аның белән соңыннан да аралашып тордык. Ул да: «Җомга намазына булса да мәчеткә кил әле», – дип чакырды. Баш тарта алмадым...

Раил дөрес әйтә: йөрәгебезнең Ходайга кайчан ачыласын без беребез дә белми... Биш вакыт намаз укый башлавы белән «мәчет салам» диюенең арасы исә кул сузымы гына була.

Гаҗәп: бернинди киртә булмады! Кая, кемгә мөрәҗәгать итсәм дә, бар да уңай килеп торды...

Һәм аның тормышында могҗизалар башлана!

– Интернет-кибетләрдән арматура эзлим. Берсен таптым да, шалтыратам: «Миңа 16 миллиметрлы арматура кирәк иде. Метры ничә сум?» – дим. «Ә сезгә нәрсә өчен ул?» – диләр. «Фундамент өчен кирәк иде», – дим. Тагын сорау бирәләр: «Ә нәрсә төзисез?» – диләр. «Мәчет...» – дим. «Ә килеп карасак буламы?» – диләр. Чаллыдан бит бу! Кич килеп тә җиттеләр. «Санадыгызмы, күпме кирәк?» – диләр. Һәм... бушлай китерәчәкләрен әйтәләр! Күз алдына китерәсезме: интернет-кибеттән әйбер сайлыйсыз, ә аны сезгә бүләк итәләр. Хәтта кулыгызга китереп тоттыралар!

Бер танышымның йөк машинасы бар. «Кирәк чакта мөрәҗәгать итегез, булышырмын», – дигән иде. Киров өлкәсеннән мәчеткә такталар алып кайта алмассыңмы, дип сорадым. Шоферы авырый икән – рульгә үзе утырып чыгып китте. Соңыннан сөйли: «Машинага документларым үзем белән юк иде бит. Бер урында, йөк машинасына узарга ярамый дигән билгене күрмичә, туры юлга кереп киткәнмен. Ни күрим: каршыда – ГИБДД хезмәткәрләре. Хәзер туктаталар, штраф салалар инде, дип уйлыйм. Үзем белгәннәремне укыйм... Ә алар, мин килеп җитәргә 10–15 метр калгач, машиналарына утырдылар да китеп бардылар!» – ди. 40 тонна кирпеч төяп кайткач та шаккатты ул. «Тәгәрмәчең шартларга мөмкин, дигәннәр иде. Ничек кайтып җитәрмен дип уйладым... Исән-сау кайтарып җиткездем менә. Кая барсам да юллар ачык – бу мәчетең нишләтә безне?!» – ди.

Мәчет төзелеше белән бәйле могҗизаларны бик озак сөйли ала Раил. Бер бабайның иң кирәк чакта 250 мең сум акча китереп бирүе әллә могҗиза түгелме?! Ә икенчесенең инде ике тапкыр: «Мин биргәнне берәүгә дә әйтмә, Ходай гына белсен», – дип, аның кесәсенә кырыгышар мең салып калдыруы? Пенсиядән өзеп җыйган акчалары бит... Интернет аша кайбер оешмаларга ярдәм сорап хатлар юллагач, берсеннән 300 мең сум акча килеп төшүе дә аның өчен могҗизага тиң. «Сезнең акчага үземнең 100 меңемне куштым да, плитәләр алдык. Исемегезне китапка кертергә телибез, сез ризамы?» – дип язган хатка җавап бирмәүләре дә... (Ә минем үземә Раилнең әнисе – 85 яшьлек Рәйсә апаның бөтен пенсиясен, оныклары калдырган сәдака акчаларын мәчет төзелешенә биреп баруы да могҗиза кебек тоела. Хатыны Гөлназның мәчет төзелешендә эшләүчеләрне ашатырга өлгерүе дә.)

– Кемгә ышандым, кемнәргә өметләндем, берсеннән дә ярдәм күрмәдем, – ди ул. – Хәтта классташлардан да... Булышабыз дигән эшмәкәрләр дә булышмады. Ярдәм гел көтмәгән яктан килә...

Фото: Анна Арахамия

PRESSA

Мәчетне ачудан бигрәк, яшәтеп җибәрү авыр: аның булачак имамына – элекке укытучысы Вәгыйзь абый Шакировка бик ышана ул.

Мәчет бик күпләрне үзгәртә.

Менделеевскида туып-үскән бер ир-ат (җитәкче кеше!), узган җәй Мәскәүдән кайтып, бер ай мәчет төзелешендә эшләп китә. Бер көнне «үзем өчен» дип килә, икенче көнне – «хатыным өчен», дип, өченче көнне – «әнием өчен», дип...

Үзенең кул астында эшләүченең берсе – христиан егете – мәчет төзелешендә катнашканнан соң, ислам диненә күчәргә хәл итә.

Бер ир-егет 52 яшендә генә дингә килә һәм иң беренче эш итеп «Хөсәен» мәчете өчен утеплитель ала. Озак та үтми йөрәк өянәгеннән кинәт вафат була. Аның белән ахирәтенә барасы догасы – тау кадәр ул дивар җылыткычлар мәчет ишегалдында үз чиратларын көтә.

Тик мәчет төзегәндә бөтен шайтаннар шул урынга җыелыр дигән сүз дә бар. Төзелеш әлегә туктап тора, чөнки күршеләрнең берсе: «Син безгә кояшны капларга җыенасың. Тиешле булганнан, 30 сантиметрга безгә якынрак сала башлагансың», – дип тавыш чыгарган. Мәсьәләне хәл итү өчен, хәзер күршедәге ул участокны сатып алырга җыеналар. Моның өчен акча бирергә вәгъдә иткән кеше инде табылган. Йортын – имам йорты итеп үзгәртергә, бәрәңге бакчасы урынында хәләл балалар бакчасы төзергә хыялланалар (әлегә андый теләге булган ата-аналар балаларын Чаллыдагы хәләл балалар бакчасына йөртергә мәҗбүр). Ә арттарак... анда парк булачак! Дөресрәге, аның бер өлеше инде бар: зәңгәр чыршылар, наратлар инде утыртылган.

– Бистәбездә яшәүче әби-бабайлар бик борчыла, – ди Раил. – Узган ел бу эшкә алар бик ышанып бетмәде бугай. Нигезенә таш салырлар да туктарлар дип уйладылар, күрәсең. Җәй эчендә мәчетнең беренче каты күтәрелгәч, аларда да өмет уянды. Кулларын артка куеп, гел мәчет тирәсен урап китәләр. Аның янында торган тартмага да күпмедер акча салып калдыралар. «Шушы мәчеттән азан тавышы яңгыраганын ишетеп өлгерергә иде», – диләр. Елыйлар... Үземнең әни дә шулай дип елый...

«Ә мин борчылмыйм. Мәчетне барыбер салып бетерербез – Ходай булышыр. Мәчетне бит ул төзи, без сәбәпче генә. Миңа шулай тоела», – ди ул.

Иң зур ышанычы – «Татнефть» берләшмәсендә. Алар өметләндергән. (Хәер, нигә Раил генә, моңа бөтен Менделеевск өметләнә!) Түбә астына кертергә, коммуникацияләр уткәрергә ким дигәндә 5-6 миллион сум кирәк әле. Ә мәчетнең эчке эшләре... аларын ул хатыны Гөлназ белән эшләп чыгарга да әзер! Ул инде барысын да уйлаган: мәчет белән янәшә цех төзиячәк, аны егетләргә арендага бирәчәк – анда ипи пешерәчәкләр. Хәләл балалар бакчасы да ачылса... Арендадан акча керә икән, мәчеттә ут һәрвакыт яначак, анда җылы булачак, су агып торачак. Теләгән кеше теләсә кайсы вакытта кереп намаз укый алачак. Әйе, йөрәкләрнең кайчан ачыласы Ходайга гына мәгълүм...

– Гөлназ сезнең мәчет өчен күпме акча тотканны беләме? – дип сорыйм сак кына.



■ – Мәчет төзелешендә без «бригада подряды» белән эшлибез, – дип шаярта Раил. – Әни, хатыным, мин... Бистәбез өстенә азан тавышы яңгыраячак көнне һәркем үзенчә якынайтырга тырыша.

– Аны мин үзем дә белмим, чутламыйм, – дип шаккаттыра ул. – Йортлар әле дә салгалыйм бит. Бар тапканым – мәчеткә, әлхәмдүлилләх... Дөрес, соңгы вакытта халыктан кергән акчаны язып барырга куштылар, берәр фетнәгә эләгә күрмә, диләр. Сәдака бик чиста, нечкә әйбер бит ул. Кешеләр аның хакында белсә, ул пычрана кебек тоела миңа. Күптән түгел бер сәдакам турында бөтен кеше алдында: «Анда бит син дә булыштың», – дип кычкырып әйттеләр. Һәм ул сәдакам сулган кебек тоелды, йөрәктән рәхәте китте... Уң кулыбыз күпме биргәнне сул кулыбыз белмәскә тиеш бит. Дөрес, кайчак башкаларга үрнәк булу өчен әйтәсе дә килә.

Тәрәзәгә карап тынып калабыз. Икебез дә бер үк нәрсә турында уйлый бугай: тиздән алар тәрәзәсеннән мәчет күренеп торачак. Манаралары 29 метр биеклектәге матур мәчет. Үргә урнашкан бу Аллаһ йорты борынгы бистәнең – Бондюгның күркенә әйләнәчәк. Иншалла!

– Берничә ел элек миңа: «Син тиздән намаз укыячаксың, мәчет салачаксың», дисәләр, ышанмас идем. «Юк, бу реаль түгел», – дияр идем... Башкалар кебек мин дә дөнья кудым. Әни белән икәү 10–12 шәр баш мөгезле эре терлек – сыер, үгезләр асрадык. Иртәдән кара төнгә кадәр эштән кайтып кермәдем. Ә Аллаһы Тәгалә кешенең тормышын менә шулай да үзгәртә ала икән... Әмма үткәннәр өчен үкенергә, дөрес яшәлмәгән диярга ярамый. Начарын, гомумән, искә төшерергә тырышмыйм. Аны искә төшереп сөйләсәң, бигрәк тә азарт белән сөйләсәң, барысы да яңара... Кайчак уйлый башлыйм да, әйтерсең, алар инде минем белән булмаган кебек тоела...

Үзеңә үпкәли башласаң, бер туктамый үпкәләп утырырга, үткәндә казына башласаң, үзеңне юкка чыгарырга да була. Моның өчен сәбәпләр дә бар... Юлны һәрвакыт үзебез сайлыйбыз бит. Минем дә сайлау мөмкинлегем бар иде. Татар кызына да өйләнә ала идем, ә мин башка якка авыштым. Анысы бит барысын да рөхсәт итә иде... (Үзебезнең кызга өйләнсәм, әкрен генә, җай гына агар иде, бәлки, тормышым. Бер-береңә татарча дәшәр идең. Ә монда туган тел онытылып бетте диярлек.) Балалар туды, өйләнештек. Шушы юлдан киткәнгә күп нәрсә дөрес булмады да. Аллаһы Тәгаләгә бер генә юл алып бара, ә аңа янәшә юллар бик күп һәм аларның һәркайсының башында шайтан утыра, диләр... Кызларны миңа каршы котырттылар. Аерылыштык, әмма балалар хакына дип кабат кушылдым. Тик Розалина белән Римманы барыбер миннән аердылар... Римма Рязаньда яши, академия тәмамлады, тик сату эшен сайлады. Ә Розалинада анорексия... Мәскәүдә, Малаховның «Пусть говорят» тапшыруында да катнашып кайтты. Кызларым Аллаһы Тәгаләгә якынайса иде дип көн дә дога кылам. Кем белә... Әмма бөтен кешегә дә бу юл ачык түгел шул.

Аннан Гөлназ белән очраштык менә. Очраштык та, бергә калдык... Аның да беренче никахы уңышлы булмаган. Минем арттан ул да, аның улы да намазга бастылар, шөкер. Тормыш шулай кызык ул...

...Әйе, безнең алда торган юллар күп, әмма иң мөһиме: иртәме-соңмы аның дөресенә, турысына чыгудыр. Раил Хөсәенов бу юлга чыккан. Чыга алган!

Ислам дине буенча, дога ул – кул күтәреп Аллаһыга ялвару, аннан нидер сорау гына түгел. Дога ул – яхшы сүз дә, кулның хәрәкәте дә, дога ул – баштагы фикер дә. Мәчет төзү дә – дога.

P. S. «Мәчет төзергә уйласагыз, булышырбыз», – дигән рус егете Раилгә чыннан да булыша: ике КамАЗ төзелеш материаллары китерә.



Ирек хәзрәт НУРИЕВ, Менделеевск районы имам-мөхтәсибе:

– Раил абыйның дингә басуы да үзенә күрә бер могҗиза аның... Мәчеткә килеп керде дә: «Хәзрәт, Аллаһы ризалыгы өчен мәчеттә эшлим әле», – диде... Аны хәзер моннан тартып та чыгарып булмый... Аннан бер көнне: «Хәзрәт, мин мәчет төзергә телим», – диде... Үзенә дип алган участокны мәчет төзелеше өчен бүләк итте. Узган ел Ураза гаете көнне «Хөсәен» мәчетенә нигез ташы салынды. Районыбызда 12 мәчет бар. Шәһәрнең үзендә моңарчы берәү генә иде, монысы икенчесе булачак... Раил абыйның бу эшкә тотынуы вакыйгага әйләнде – халыкны кузгатып җибәрде. Күпләр җәрия сәдакасы биреп калырга ашыга.

...Кыямәт көнне сезне Аллаһ хозурына чыгарырлар ди пәйгамбәребез. Аннан әйтерләр: «Бармы бу бәндә тарафыннан рәнҗетелгән кешеләр?» Андыйлар бер рәт булып төзелер: «Әйе, ул безне рәнҗетте», – диярләр. Һәм алар, дога кылып: «Йә Рәсүлүллаһ, рөхсәт ит аның изгелекләрен үзебезгә алырга», – дип сорарлар. Аллаһ бу бәндәнең изгелекләрен – намазын, уразасын, зәкятен, хаҗын алырга рөхсәт итәр. Ә рәнҗетелгән кешеләрнең саны һаман бетмәс... Алар янә: «Йә Рәсүлүллаһ, рөхсәт ит үзебезнең начар гамәлләрне аңа тапшырырга», – диярләр. Аллаһ кабат ризалашыр. Инде бер аягы белән җәннәттә булган бәндә, шулай итеп, җәһәннәмгә эләгер... Ә җәрия сәдакасы чишмә кебек агып тора, кимеми. Мәчет төзелешенә өлеш кертү дә – җәрия сәдакасы бирү. Бу мәчет җимерелгәнче – тарихтан юкка чыкканчыга кадәр кешегә аның савабы килеп торачак.

PRESSA



Зәй якларында туып, Түбән Кама заводларында эшләп, Казаннарда укып, Биектау, Сарман төбәкләрендә укытып, Җәлилләрдә яшәп, янып-ялкынланып иҗат итүче Рухия Ахунҗановадан редакциябезгә бер шәлкем багышлаулар килеп төште. Гади багышлаулар гына түгел алар. Һәркайсыннан халкыбызның йөзек кашы булырдай асыл кызларын танып алабыз: затлы хатын-кызлар, зур шәхесләр, талант ияләре. Баянчы Оркыя Ибраһимова, җырчылар Гөлсем Сөләйманова, Зифа Басыйрова, шагыйрәләр Саҗидә Сөләйманова, Флёра Гыйззәтуллина... Күпләр, бик күпләр! Ул багышлауларның берничәсен сезнең игътибарга тәкъдим итәбез. Ә авторның үзен 60 яшьлек юбилее белән котлыйбыз, иҗат уңышлары телибез.

Рухия АХУНҖАНОВА

БАГЫШЛАУЛАР

Шигъри чигү

Лена Шагыйрьҗан истәлегенә

Шигъри сүздән
Чигү чикте.
Ничек күзләр тимәде!
Такыя күк
Үрде аны –
Гади сүзләр димәде.

Урыннарын
Белеп кенә
Рифмаларын уйнатты.
Нәфис шигырь
Үрнәгендә
Бәрәкәтле уй ятты.

Шигырь гали –
җәнабына
Багышлады ул үзен:
Пьедесталдан
Торып әйтте
Илгә кирәкле сүзен!

Милләт гаме

Саимә Ибраһимовага

Милләт, халык гаме белән
Кемдер тиеш янарга.
Тумыштан шундый миссия
Бирелгән бит аңа да.

Татарны илгә таныту
Фикере белән яна.
Ике телне камил белү
Бик ярап куя аңа.

Урыс, чит ил әдипләрен
Татарча «сөйләштерә».
Әдәби күперләр салып,
Барысын берләштерә.

Журналистка хас сыйфаты –
Омтыла яңалыкка.
Геройлары арасында –
Беренче космонавт та!

«Сөембикә ханбикә» дә
Уза йөрәге аша...
Иҗат ялкынын сүндерми,
Балкый Саимә апа!

Җыр чишмәсе

Гөлшат Зәйнашева истәлегенә

Синең «Җәйге урман»ыңны
Моңланмый тыңлый алмыйм.
Ул урман – серләр дөньясы,
Анда гел кошлар сайрый.

Үзең кайтып киләсең күк,
Җырлап, шул борма юлдан.
Гүя аланда йөртәсең
Житәкләп безне кулдан.

«Урман юлында» җыры да –
Шул хисләрнең дәвамы.
«Җир җиләгенә чык түгел»,
Күз яшьләрең тамамы?

«Китмә, китмә, сандугач, – дип
Ялвардың, – туган илдән».
Әзер идең син сакларга
Җыр кошын салкын җилдән.

Былбыл кошкай – сандугачның
Серкәйләрен алдың син.
Дусларыңа җырлар өчен,
Җырын отып калдың син.

Теләдең Урал тавының
Басып кыя ташына,
Кушылып җырларга үзең дә
Шул бөркетләр таушына.

Татарны бар халык белән
Иш иттерәсең килде.
Урал тауларыннан җырлап
Ишеттерәсең килде.

Син бәхетле, җырлар яздың
Туган җирең турында.
Аны өзелеп сөюеңне
Әйтә алдың җырыңда.

Кадерле син халкыңа

Зөһрә Сәхәбиевага

Олы иҗат белән юл салгансың
Җыр-моң дигән изге тәхеткә.
Халкың мәхәббәтен казанып син
Ирешкәнсең иң зур бәхеткә.
Җидегән чишмәләрнең челтер көе
Җырларыңа биргән кайтаваз.
Көзләреңдә булган кошлар моңы,
Саф хисләрең булып кайткан яз.
Аккош тугрылыгы саклагансың
Җырыңа һәм сөйгән халкыңа.
Милләтеңнең былбыл кошы бит син,
Һәм җырың да аның хакында.
Йөрәгеңнән чыккан җырың аша
Безнең күңелләргә дәшкәнсең.
Тал-тирәкнең сайрар кошы кебек
Халкың күңелендә яшәрсең.
Җырың-моңың белән еллар кичеп,
Ерак гасырларга барып җит.
Керсез күңелеңнең саф җырлары
Милләтеңә шифа-дәва бит.
Зур бәхетләр насыйп булсын сиңа,
Өмет-хыялларың аклансын.
Халкың кадерендә яшә, җырчы!
Аллаһ сине Үзе сакласын.



Шагыйрә Клара Булатова укучысы... Заманында Саҗидә Сөләйманова, Равил Фәйзуллин, Зөлфәтләр бу кызның үзенчәлекле шигырьләренә игътибар итә. Әлмәт Язучылар оешмасы аны махсус юллама – комсомол путевкасы белән Казан университетына озата. Укырга кергәндә сочинениесен шигырь белән язып, имтихан кабул итүчеләрне таң калдыра... Студент елларында Клара апасына хатларын шигырьләтә генә юллый... «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре», «Ялкын», «Идел», «Азат хатын» кебек басмаларда әледән-әле шигырьләре күренә. Аннары инде балалар газетасында, Фәннәр академиясендә, район мәгариф бүлегендә, Әлмәт, Нурлат редакцияләрендә эшләү... Игътибарыгызга Камәрия Җамалетдинова шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Камәрия ҖАМАЛЕТДИНОВА

ШИГЪРИ ХАТЛАР

Язмыш

Меңәр еллык әхлак кануннары
Табалмаган шуннан яхшысын –
Кыз озаткан чакта теләгәннәр:
«Төшкән нигезендә таш булсын!»

Без дә шулай килен булып төштек,
Төшкән җиребездә таш булдык.
(Кайчак «авыл күрке» – гайбәтчегә
Бер кабарлык йомшак аш булдык.)

Булгалады җанның чарасыздан
Ташка әверелгән таңнары.
(Үрмә гөл күк балкып ачылырга
Бер җылы сүз җитте аннары!)

Булды кайчак, булды таш бәгырьдән
Саркып кына чыккан үпкә дә...
(Малай кадәр малай үстерүче
Кайнанада йөрәк юк мәллә!)

Төшкән җиребездә таш булганга,
Тамды кайчак сагыну яшьләре...
(Юатырга беркем табылмады,
Ялгыш күрүче дә дәшмәде...)

Уттан суга, судан утка салып
Чыныктырды язмыш башларны.
Улым, кызым җитте. Бигрәк газиз!
Кая ташлар язмыш ташларны?..

Кайтам дигән иде

Фронтлардан исән кайткан әти
Җитә алмады хәтта җитмешкә...
«Йөрәк шаяргалый, кызым!» – дигәч,
Хәл белергә кайттым бер кичкә...
«Сугышларны узган йөрәк бит ул,
Шаярганнан нигә куркырга?!
Умарталар чыгарыр чак җитте,
Җибәрермен диде доктор да...»
Әтидән соң утыз бер яз узды,
Шомырт чәчәк атты шул тапкыр...
Һәм ел саен буяп яңартылган
Капка мыгырданды: ул – кайтыр!
Әтидән соң утыз бер җәй килде
Җиләкләре белән мөлдерәп...
Тормыш рәхәтенә өлгермичә
Китеп барды әти... Түз, йөрәк!
Көтә-көтә әни китеп барды,
Көтеп алалмыйча әтине...
Һәм мин бүген – соңлап тусам да бит,
Фронт узган җанның ятиме!
Әтидән соң утыз бер көз килде,
Саргаюлар артты мең тапкыр!
Әти төшкә керде: «Вәгъдә – иман,
Без кайтмабыз, балам, Моң кайтыр!..»

Гомер көзендә

Көзләрнең яфрак-хатлары
Яшьлектән килгән кебек.
Пырдымсыз әрсез яңгыры
Битләрдән ала үбеп.
Яфраклар – тансык сәламнәр
Җавапсыз коелалар.
Мәңгелек дигән хисләр дә
Яңгырда юылалар.
Яфраклар – җавапсыз хатлар –
Юлларда ята аунап.
Кичерә алмаганнарга
Җавапсыз калу – Җавап!

«Яшьлек дәфтәре»ннән

* * *

Миңа сөю унҗидедә килде...
«Мәңге бергә!» диеп ант бирештек.
Шигырь язып берчак хушлаштык та
Егерме ел үткәч бер күрештек.
Яшьлектәге зәңгәр күзле кызый
Төртмә телле ханым булып җиткән.
Шат күңелле көяз егетне дә
Тормыш агай арбасына җиккән.
Унҗидедә килгән шул сөюдән
Шигырь белән тулы чишмә калган.
...Унҗидедә түгел, җитмештә дә
Кемнең узганы бар язмышлардан?!..

* * *

Тот та як шуларны утка,
Кичерсен яшьлек еллар.
Сакласаң-сакламасаң да
Барыбер күңел елар.
от та як шуларны утка,
Оныт та сагынганны.
Утка каршы утлар ягып
Туктатыйк янгыннарны.
Тилегә сабышкан йөрәк
Бер елар да бер көләр.
Язмыш безне гафу итсен,
Үзебез гаеплеләр.

* * *

Җилләргә сердәш идем,
Гөлләргә көндәш идем.
Бергә булсак, чын бәхетне
Гомердә белмәс идем.
Өзелеп елар идем,
Ялганың йолар идем.
Бу дөньяның бәхетсезе –
Мин диеп уйлар идем.
Ходай безне яраткан,
Яраткан да тараткан:
Бер юләргә – бер тилене
Насыйп итеп караткан...
Гөлләргә тиңдәш идек,
Кемнәргә көндәш идем!
«Юләрем – бердәнберем!» – дип,
Соң шунда эндәш идең!..



КИРЕ КАЙТА ТОРГАН ЮЛ БУЛСА...

(Хикәя)



Ләлә Сабирова

– Җәймәне болайрак тартыйк, урыны тигез түгел.

– Каударланма, компотны түгәсең бит!

– Наил, ашамлык тутырылган тартманы алып кил әле, табынны хәстәрли торыйк.

Шау итәләр, берәү дә тик тормый. Алинәнең генә кәефе юк. Монда да атлыгып килмәде. Гадәткә кергән инде – халык җәйге ялга тарала башлаганчы, бүлекләре белән шулай табигать кочагына чыгып керәләр. Башка елларны мондый күңел ачуларда Алинә башлап йөри иде – быел сүрелде. Соңгы вакытларда ире белән аралары суынып китте. Шул күңелен кимерә. Әнвәр эшеннән соңарып кайта башлады – сәбәбен әйтми, шулай кирәк булды, ди. Әйтмәгәч, шикләнми хәл юк бит! Кичә хәйран тавышландылар. Әнвәр:

– Ник канымны кыздырасың, болай да җайсыз вакытларым! – дип дулады.

– Ник җайсыз? Ник мин аны белергә тиеш түгел?

– Белеп нишлисең? Эш буенча бит ул! Җайга салынса, әйтермен.

Алинә аңа карап тынычланмады. Иртән дә кара янып чыгып китте...

* * *

– Табынга утырганчы әллә бер чумып чыгабызмы?

Кемнеңдер шулай дәшүе булды, дәррәү күл буена төшеп киттеләр. Алинә ялгызы утырып калган иде, үзен этә-төртә дигәндәй, ул да иптәшләре артыннан кузгалды. Коенырга дип әзерләнеп килмәгән иде, чүәкләрен генә яр буенда калдырды да, итәкләрен күтәрә төшеп, яланаяк суга кереп басты.

Халык күл эчендә чыр-чу килә, бала-чага диярсең. Ни кызыгы бардыр инде!
Алинә күңелсез генә иптәшләренә карап торды.

– Ә син нишләп кермисең, чибәркәй? Йөзә белмисеңме әллә? Әйдә, үзем өйрәтәм!

Алинә сискәнеп куйды. Чит ир икән. Коенып чыккан да, яр кырыенда ял итеп утыра. Бигрәк тәкәллефсез инде! Яратмый хатын шуның ишеләрне. Моңа да җавап биреп тормады, төксе генә карап куйды да, читкәрәк китте. Теге ир аңламый торганнардан түгел икән, кабат дәшмәде, йөгереп килеп суга чумды.

Алинә аннан күзләрен алмый карап торды. Колачларын киң салып, ышанычлы итеп йөзә. Гәүдәсен дә кояш хәйран алган. Үзе дә чибәр генә күренә... Судан чыккач, ир аның яныннан читкәрәк атлаган иде, Алинә үзе дәште – алдан тупасрак кыланганы өчен читенсенеп куйды:

– Шәп йөзәсез!

– Әйтәм ич, сезне дә өйрәтәм дип!

– Кермим әле... Нәрсәдер кәеф китеп тора...


Рәсем: Наталья Васильева

– Сизендем инде... Узар. Вакыт үзенекен итә ул.

Алинәгә әллә нәрсә булды – яңа танышы шундый да үз, якын булып тоелды. Якынрак килеп, янәшәсенә чүгәләде.

– Ел саен шушы вакытта киләбез без монда. Кышкы тузаннарны кагабыз...

– Кышын да тузан буламыни?

Икәүләп көлештеләр. Ирнең көлүе ихлас, дәртле. Әнвәр гомердә алай булдыра алмый – соңгы вакытта чырае аеруча караңгы. Алинәнең күңеле йомшарды, яңа танышының иңенә башын саласы килеп китте – алай да түзде, үзен тотып кала алды.

Табынга дәштеләр. Алинә теләр-теләмәс кенә торып басты.

– Анда барып утырасым да килми хәтта! Иптәшләрнең ачуын гына китерермен кебек.

– Килмәгәч, ник үзеңне азапларга? Теләсәгез, кайтып китәбез. Минем машина, әнә, тегендә генә.

Алинә уйланып алды. Ә нигә шулай эшләмәскә?

Шау итеп торган компания аның юкка чыгуын сизми дә калды.

* * *

Әнвәрнең кирле-мырлы сөйләшеп йөрүенә Алинәнең тамчы да исе китми хәзер. Дөресрәге, ул аны ишетми, йөзгә-йөз килеп сөйләшсәләр дә, күрми. Күз алдында да, күңелендә дә гел – Салихҗан. Аны уйлый-уйлый саташа бугай инде. Ярый очраттым әле мин сине, дип куана. Чын яратуның ни икәнен дә белми калган булыр идем, ди. Салихҗан да аны күрми түзә алмый шикелле. Көненә бишәр шалтырата. Эштәгеләр дә сизенәдер, чыш та пыш килешәләр. Алинәнең анысына да исе китми.

Баштарак читенсенә иде – хәзер үзенең эштән соңарып кайтуына да аптырамый Алинә. Әнвәргә ярый, аңа – юкмы? Ирен әүвәлгечә килделе-киттеле сораулары белән дә йөдәтми, кирәген генә әйтә. Кичен тегесен-монысын тиз-тиз генә карый да караватына кереп чума. Элек Әнвәрдән алда кереп яту гадәте юк иде. Тегесе аптырый, хатынындагы үзгәрешне үзе аркасында дип аңлый.

– Син ни... Минем кәеф юкка аптырама инде. Ходайга шөкер, проблемалар хәл ителергә тора...

Алинә аңа елмаеп карый, дәшми. Дөресрәге, ул аны күрми, күңеленнән Салихҗаны белән сөйләшә.

Хатын үз-үзен аңламый, аңларга да теләми. Кая китереп чыгарыр аны бу тилерткеч мәхәббәт? Алда аны нәрсә көтә? Мондый хәтәр уйлар аның башында озак тоткарланмый, Алинә алардан ераграк йөрергә тырыша.

Бер көнне эш телефонына чит хатын шалтыратты.

– Сезне минем ирем белән күргәннәр... Дөресме?

Алинәнең бөтен гәүдәсе оеп китте. Тамагы кипте.

– Ялгышканнар алар... – дип кенә әйтә алды. Шундук трубканы куйды.

Ул көнне Салихҗан аны каршыларга килмәде. Хатынның дөньясы караңгыланды. Кайткач, тиз-тиз генә кичке ашын әзерләде дә, үзе кабып та карамады, караватына бөгәрләнеп ятты. Бәгыре каткан иде, елый да алмады хәтта.

Әнвәр, гомер булмаганча, вакытында кайтты. Күңеле күтәренке иде. Алинәнең вакытсыз караватта аунаганын күргәч, аптырап китте.

– Ни булды? Ә мин шатлыклы хәбәр белән кайттым! Сөенечемне уртаклашмассыңмыни?

– Уртаклашам... Тик... башым чатный, чирләп киттем, ахры...



– Соң, авыруыңны кочаклап ятсаң, аза гына бит ул! Аннан дәваланырга кирәк!

Дәваланырга... Белмим инде, мәхәббәттән дәва юк диләр бит...

Икенче көнне Салихҗан аңа әбәт вакытында шалтыратты. Гадәттә очраша торган бакчага килергә кушты.

– Болай булмый... – диде, Алинәне кочагына алып. Хатын бу сүзләрдән өшеп китте, утыргычына ныграк сеңде. – Мин синнән башка яши алмыйм. Син дәме? Кайчанга хәтле качып йөрергә була? Кирәк кеше барыбер сизәчәк. Җиткерәчәкләр. Нокта куйыйктыр, мөгаен.

– Нинди... нокта?

– Синең бәйләп торучы балаларың юк. Минем малай үсеп беткән инде, минсез дә яши ала. Безгә... бөтенләйгә бергә булырга кирәк.

Алинә бу сүзләрдән тәмам изрәде. Салихҗанның кочагына тагын да ныграк сеңде.

– Кайчан әйтәбез? Әнвәргә, синең хатыныңа...

Салихҗан бераз уйланып утырды.

– Өч көннән минем малай лагерьга китә. Аның алдында аңлашасы килми. Дүшәмбе кич әйтик дисәм...

Өч көн... күбрәк инде ул. Әнвәр алдында икейөзләнеп йөрергә кирәк бит әле.

– Аңа хәтле күрешмичә түзәргә кирәк инде ничек тә. Тындылар дип уйласыннар. – Монысын Салихҗан үз-үзен үгетләгән шикелле сөйләнде.

– Түлке шул дүшәмбедән дә калмыйбыз, яме, Салихҗан!

Ир аны ике куллап кочаклап алды.

Алинә өчен өч көн бик авыр узды. Әнвәр алдында үзен җайлы-җайсыз тотты. Әле башы, әле эче «авыртты»...

Дүшәмбе көнне кичке ашны бик тырышып әзерләде. Өстәл артына матур күлмәген киеп утырды. Ире белән ягымлы сөйләшергә тырышты. Әнвәр аптырады:

– Әллә берәр бәйрәмме бүген? Мин генә белмимме?

– Белмисең... Ә син аша, аша. Аннары әйтермен.

Әнвәр ашыга-ашыга ашады, үзе хатыныннан күзләрен алмады. Ни әйтергә тели икән соң ул?

Алинә сүзен ерактан башлады – сөйләшүгә ныклап әзерләнгән иде.

– Мин сиңа бик рәхмәтле, Әнвәр... Бер борчу күрми яшәдем. Яратканмындыр да... Тик ятуның икенче төрлесе дә була икән. Мин бүтәнне очраттым... Кичерә алсаң, кичер, зинһар... Гаугасыз гына аерылышыйк...

Әнвәр башка сүз көткән иде. Йөзе башта куе кызыл, аннары әкренләп зәңгәр төскә керә барган кебек тоелды. Көрәктәй куллары белән эскәтер читен йомарлап алды да чытырдатып кысты. Алинә каушап торып басты. Өстенә ташланмагае. Моңа кадәр кул күтәргәне булмады үзе, шулай да, белмәссең...

Менә ир акрын гына кузгалды, хатынына авыр итеп озаклап карап торды. Алинә куырылып килде. Әнвәр йокы бүлмәсенә кереп китте, шактый вакыт тавышын ишетелмәде. Аннары ишекне каерып ачып килеп чыкты, ике кулына ике юл сумкасы тоткан иде, аларны зал уртасына атып бәрде:

– Бүгеннән үк чыгып китсәң генә! Синең белән бер фатирда төн уздырачагым юк!

Чыгып китеп... кая барырга? Торыр урыным бар диген иде Салихҗан. Ник анысын да алдан сөйләшеп куймадылар соң? Ул да бүген хатыны белән сөйләшкән булырга тиеш, аңа да бүген китсә була бит!

Күтәренеп, ишек төбенә чыгып баскач кына шалтыратты Салихҗанга. Әллә ничә тапкыр тырышып карады. Тегесе йә трубкасын алмый, йә телефонын бөтенләй өзеп куя. Сөйләшкән вакытларыдыр инде, җае юктыр.

Такси тотып, әнисе яшәгән йортка килеп җиткәндә төн уртасы җиткән иде. Әнисе ишекне бик озак ачты. Каушаган, борчылган. Борчылмыйча! Төн ярып, кисәтми-нитми килеп керсеннәр әле өеңә!

Аннары да тиз генә ятып булмады, икесенең дә йокысы качкан иде инде.

– Нәрсә дияргә дә аптыраш! – Әнисе кулындагы тастымалын бер куя, бер ала. – Нәрсә җитмәгән иде соң сиңа! Әнвәрдән юньлерәген табам дип уйлыйсыңмы?

– Юньле дип... Сөйләшкәнебез дә юк бит безнең. Мин биш җөмлә әйтсәм, ул бер сүз белән җавап бирә...

– Шул да булдымы сәбәп!

– Яратам дигәне дә булмаган икән ничә ел торып. Яшәлгән дә яшәлгән инде.

– Әйтмәсә! Яратуын эше белән күрсәтеп тора ич! Гел гаилә дип яши.

– Яшибез инде... Уен-көлке юк, кунакка да сирәк йөрибез...

– Әйсәнә! – Әнисе кулын селтәп китеп үк барды.

Икенче көнне эшенә барып җиткәнче телефоны кулыннан төшмәде Алинәнең. Салихҗаннан хәбәр юк – нәкъ кичәге кебек. Икенче, өченче көнне дә шул хәл кабатланды. Хатын үз-үзенә урын таба алмый өзгәләнде. Бер-бер хәл булмагандыр бит инде?! Исән-имин генә була күрсен, Ходаем!

Түзмәде, Салихҗанның эшләгән җиренә китте. Эзләп тапты, кочагына атылудан үзен чак тыеп калды – исән икән, җае гына чыкмаган, күрәсең!

Салихҗанның йөзе сүрән иде. Башын аска иеп кенә сөйләште. Киң җилкәләре дә тараеп калган кебек тоелды. Озын зифа буена, куе бөдрә чәчләренә сокланып туймый иде Алинә – хәзер аның янында әнә ничек бөкрәеп басып тора, чәчләрен дә юньләп тарамаган...

– Беләсеңме, Алинә... Әйтә алмадым мин аңа. Алмаячакмын да... Китә алмыйм мин гаиләмне ташлап. Юләрләнеп алдык, җитәр дип уйлыйм.

...Их, баскан урыныңда ереп кенә юкка чыга алсаң икән! Һич булмаса, Салихҗан белән танышканнан соң булган вакытны сызып атып булса икән! Алинә аңа күзләрен тутырып-тутырып карады. Әнвәре белән чагыштырырлыкмы – Салихҗаннан да ямьсез, аннан да мәхәббәтсез кеше бармы икән бу дөньяда?!

Хатын үкчәсендә зырылдап әйләнде дә, төз атларга тырышып, ишеккә таба юнәлде.

Гәүдәсе генә төз, бәгыре өзгәләнә, җаны айкала иде.

Ике якын кешесен гомергә әйләнеп кайтмаслык итеп берьюлы югалткан булып чыкты ул.

ИСРАФ ИТҮ



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН,
«Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Исраф дигәндә, ислам дине нәрсәне күз алдында тота?

– Исламда «исраф» һәм «тәбзир» дигән сүз бар. Исраф – кирәк әйбергә акча күп тоту, тәбзир – кирәкмәгән әйбергә акча тотуны аңлата. Күргәнебезчә, хәтта кирәк әйбергә дә күп итеп акча тотарга ярамый. Бу дөрес булмый.

Исраф сүзе бөтен нәрсәгә дә кагыла: ашау-эчүгә, киемгә, йортка, машинага, вакытка, сәламәтлеккә, яшьлеккә... Ягъни кеше нәрсә кулланса – шуңа. Пәйгамбәребез хәдисләрендә кешедән кыямәт көнендә бөтен нәрсә турында (әйтик, вакытын, яшьлеген ничек үткәрүе, малын кайдан алып, кая куюы һ.б.) соралыр ди. Җавап бирәсе булгач, без аларны әрәм-шәрәм итә алмыйбыз. Хәтта Пәйгамбәребез (с. г. в.) тәһарәт алып торган сәхабә янына килеп: «Нишләп суны әрәм итәсең? Бу – исраф», – ди. «Су күп бит», – ди сәхабә. Пәйгамбәребез (с. г. в.): «Әгәр елга буенда тәһарәт алсаң да, барыбер суны аз гына тотарга кирәк», – ди.

Әрәм итү дигән сүз нәрсәне аңлата? Ихтыяҗыңнан артык тоту, димәк. Ә безнең ихтыяҗыбыз бик аз. Кеше аны үзе дә белә, әмма чаманы гына югалта. Әйтик, ризык, су аз булса да, җитә безгә. Кием дә шулай. Артык зур йорт та кирәкми. (Пәйгамбәребез (с. г. в.): «Үзеңә кирәгеннән артык йорт салу – акчаңны җиргә тыгу», ди.) Тик кешенең акчаны карап тотуын саранлык белән бутарга мөмкиннәр. Анысы – чир аның. Үз ихтыяҗың канәгатьләнсә, калган акчаң белән кешеләргә ярдәм ит, дип өйрәтә динебез. Монысы – икенче юл.

Малыңны нәрсәгә иркенләп тоту исраф дип саналмый? Син күпме генә акча кертсәң, никадәр изге эшләр эшләсәң дә, әрәмгә китми торган очраклар бар. Бу – рухи байлык. Кешеләргә ярдәм итү, вакытка килгәндә – намаз, Коръән уку. Белем, гыйлем алу. Болар өчен тотылган вакыт барысы да савап санала.

Кеше хәзер балалары өчен бик күп чыгым тота...

– Балага артык тотылган акча шулай ук исраф санала. Балаларыма дип, миллиардлар җыючылар бар. Андыйлар – күз алдыбызда... Балага дип күпме салсаң да кереп китә ул. Аннары оныклар дип тырыша башлый кеше. Тик моның чамасы булырга тиеш. Яшьлекләре туксанынчы елларга килгән буын башта үзләренә, аннан балаларына йорт салды. Ә ул балалар нәрсә эшләр? Аларга бит бөтен нәрсә җиңел килде. Үз балаларына йорт салырлармы?

Пәйгамбәребез (с. г. в.) үзеңне бөлгенлеккә, хәерчелеккә төшерерлек итеп сәдака бирүдән дә тыя. Исраф итмәс өчен, ул бөтен әйберне дә максималь рәвештә кулланырга куша. Әйтик, киемне. Пәйгамбәребез (с. г. в) үзе дә, сәхабәләр дә ертылган киемне дә ямап кигән. Гомәр хәлиф (ягъни, патша) җомга вәгазе сөйләргә чыккач, янында утырган берәү аның чапанында унике ямау саный... Ә без, «модасы чыкты» дибез дә, ташлыйбыз – бәрәкәтсезлек китте.

Пәйгамбәребез ашап бетергәч, ипи белән тәлинкәне сөртеп, ипине кабып, бармагын ялап куйган – валчыгын да калдырмаган. Ислам дине буенча, җиргә ризык төшсә, аны ташларга ярамый. Пәйгамбәребез: «Шул ризыкны алып капсаң, ул ашказанына төшкәнче синең гөнаһларың кичерелә», – ди. Шайтанга да ризык калмый. Шушындый ризыкны да ташларга ярамагач, табындагы ризыкны ничек ташларга ярасын?! Әлбәттә, юк.

Табында ашалмыйча калган ризыкны һәрвакыт хатын-кыз җыештыра, ул ташларга мәҗбүр. Бу очракта ризыкны кем исраф итә дип санала: бөтен гаиләме, әллә хатын-кыз гынамы?

– Исраф итүче хатын-кыз була. Пәйгамбәребез (с. г. в): «Һәрбер кеше дә көтүче, ягъни нәрсәдер өчен җаваплы», – ди. Ир кеше хатыны, балалары өчен җаваплы. Ә көнкүреш өчен акчаны исламда хатын-кыз тота. Ул тота белмәсә, әрәм-шәрәм итсә, акчаны эшләп җиткезеп булмаячак. Әйтик, нәрсәдер ала, ошатмый һәм яңаны чыгып ала. Яисә ала һәм кулланмый. Хатын-кызның таләпләре бар – ул күп сорарга мөмкин. Әйтик, бер мисал. Безнең әниләргә почмак якта бер пычак җиткән – алар шуның белән барысын эшләгән. Ә хәзер хатын-кызга ун төрле пычак кирәк. Кашык-чәнечкеләр дә шулай. Элек бер тәлинкәне ашка да, боткага да тотканнар. Бүген исә... Боларның бит барысын хатын-кыз көйли. Өйгә ризык алып кайтканда да, ул аның бераз бәрәкәтле, озаграк саклана торганын сайлый ала. Акча аның кулында: күзе көн саен шоколадка төшәргә дә мөмкин... Кибеттә әйбер бик күп. Бөтенесе кирәк кебек: алмасы да, бананы да, башкасы да. Ә бит безнең әби-бабайлар ничә гасырлар банансыз да яшәгән... Хатын-кыз ашсуны әзерләгәндә үк исраф булмасын дип уйларга тиеш. Ризыкны җитәрлек кенә күләмдә, калып бозылып ятмаслык итеп пешерергә кирәк. Кичәге ризык калган икән, яңаны пешереп иреңне, балаларыңны куандырасың килсә дә, башта табынга кичәгесен куярга кирәк. Ияләштерсәң, нәрсә куйсаң – шуны ашаячаклар. Хәтта көнкүреш техникасын ватмыйча тоту, исраф итмәү дә хатын-кызның аны куллана белүенә бәйле. Болар да – аның җаваплылыгында. Шуңа күрә гөнаһысы да аңа була. Тагын бер нәрсә бар: савыт-саба вакытында юылмаса, идәнгә ризык валчыклары төшсә, болар шайтанга ризык булып тора. Шуның аркасында гаиләдә авырулар, тынычсызлык килеп чыгарга мөмкин.

Димәк, көнкүрештә исраф, ирләргә караганда да, хатын-кызга күбрәк кагыла.

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Без – Казан шәһәренең Тынычлык (Мирный) бистәсендә гомер итүчеләр, табиблар кытлыгын күп еллардан бирле үз җилкәбездә тоеп яшәдек.



Халкы ун меңгә якын булган бистәбезгә нибары бер терапевт һәм бер шәфкать туташы гына хезмәт күрсәтте. Аларының да эшләгән урыны – хәрабә хәлгенә калган бер авыл йортында иде. Без бит шундый – сырхаулап киткәч, берничә көн, үтәр әле, дип йөрибез. Табибка да түзмәс чиккә җиткәч кенә барыла. Ул исә хәлеңне сораштыра, кан басымыңны үлчи, йөрәк тибешеңне тыңлый да, Казанның Һади Такташ урамында урнашкан хастаханәнең лабораториясенә анализлар бирергә юллама тоттыра. Сырхау булсаң да, икенче көнне көч-хәл белән барып, анализларыңны тапшырасың. Кайсы – бер, кайсы өч көннән әзер булган ул анализларыңны да үзең барып аласың. Шулай итеп, табибка кабат өч-дүрт көннән соң гына эләгә аласың. Бу вакытта инде авыруың йә бетеп китә, йә көчәя. Әле аягыңны сузып куюың да бар.

Ниһаять, күпме тавыш чыкканнан соң, Тынычлык бистәсе халкына да бәхет елмайды – 3 нче сырхауханә ачылды. Шатлыгыбыз зур иде. Инде вакытында табибына да күренербез, вакытында дәваланырбыз дисәк... Яңа сырхауханә белән яңа проблема – кадрлар юклыгы калкып чыкты. Үзебездә яшәүчеләр арасында табиблар юк, ә шәһәрдә яшәүчеләре Казаннан читтәге бистәбезгә эшкә килергә атлыгып тормый. Сер түгел, табибларның күбесе тормышын бөтәйтү өчен ике эштә эшли. Автобуслар вакытында йөрсә, бистә белән шәһәр арасында йөреп торучы маршрутлар күбрәк булса, бу проблема, бәлки, тумас та иде. Әмма 69, 69 а маршрутлары 2012 елдан ук бетерелде. Бер автобустан икенчесенә күчеп утырып эшкә йөрү кесәгә шактый суга шул. Дүрт транспортка утырып йөри башласаң, көненә – 216 сум, айга 6 мең 500 сум чыга. Әнә, шулай итеп, яңа сырхауханә төзелсә дә, табиблар булмагач, аның рәхәтен бик күрә алмадык. Табиблар булган очракта да, тәҗрибәле, үз эшенә чынлап бирелгәннәре очрамады, дисәң дә, ялган түгел.

Менә хәзер безнең урамга да кояш чыкты. Тынычлык бистәсенә терапевт итеп тирән белемле, тәҗрибәле, кешеләргә игътибарлы, кешелекле табибны Аллаһы Тәгалә үзе җибәргәндер. Макарова Нурия Габделбари кызы табиб булам дип кечкенәдән ук хыялланып үсеп, 1986 елда Казан Дәүләт медицина университетын тәмамлап, шул ук елны үз белгечлеге буенча эшли башлый. Чын табиб теле белән, сүзе белән дә дәвалый, диләр. Нурия Габделбариевнаның мөлаем йөзе, күркәм сабыр холкы үзе бер дәва чарасы кебек. Авыруларны турсаеп түгел, елмаеп каршылавы гына да үзе ни тора! Татар әбибабайлары белән – чатнатып татарча, урыс кешеләре белән рәхәтләнеп урысча аралаша табибә. Аның янында сырхавың да онытыла хәтта.

Чиләгенә күрә капкачы дигәндәй, аның белән бергә эшләүче шәфкать туташы Галләмова Лилия Әнәс кызы да – чын шәфкать иясе. Ул да авыруларга бер караңгы чырай күрсәтмәс, һәркемгә дә игътибарлы.

Фото: Газинур Хафизов

Яраткан «Сөембикә» журналым аша табибә Нурия ханымны, шәфкать туташы Лилия сеңлемне, сырхауханәдә эшләүче башка хезмәткәрләрне – чын табибларны медиклар көне белән тәбрик итәм. Сезгә исәнлек-саулык, бәхетле озын гомер, эшегездә һәм тормышыгызда зур уңышлар телим.

Рәшит НУРГАЛИЕВ.
Казан шәһәре, Тынычлык бистәсе.



Әтием Усманов Гыйният Усман улы сугышның беренче көннәреннән үк фронтка китеп, 1946 елны гына кайта. 9 Май – Җиңү көнен Венгриядә каршы ала.

Элеккеге Чүриле (хәзерге Саба) районының Иске Мичән авылында 1916 елның 6 мартында дөньяга килә ул. 1921 елгы ачлык һәм тиф чире әтисен һәм тагын ике абыйсын алып китә. 5 яшьлек әтием үзе дә чактан гына җан бирми кала. Аңын югалткан баланы, инде үлде, дип, салкын ноябрь аенда өйалдына чыгарып куялар. Сәхәргә дип торган әнисе баласының башы селкенгәнен сизеп алмаса, шунда туңып үлгән дә булыр иде. Әти савыга, салкын һава аңа тифны җиңәргә ярдәм иткәндер, күрәсең. Гаиләдә бердәнбер ир заты булганга, аңа кечкенәдән үк җигелеп эшләргә туры килә. Ләкин уку теләге дә бик көчле була, көн саен 10 чакрымны җәяү йөреп, Саба урта мәктәбен тәмамлый. Башта хисапчы, аннары Шыңар урта мәктәбендә укытучы булып эшли. 1937–1941 елларда армиядә хезмәт итә. 1941 елның маенда мобилизацияләнеп кайткан гына була әле, июньдә инде сугыш башлана. Беренче көннән үк әти фронтка китә.

Өлкән сержант Гыйният Усманов радист, радиостанция башлыгы булып Беренче һәм Икенче Украина фронты, Белоруссия фронты составында фашистларга каршы көрәшә. Кавказны, Көнчыгыш һәм Көнбатыш Украинаны, Польша, Чехословакияне азат итүдә катнаша. Яу кырында күрсәткән батырлыклары өчен ике Кызыл Йолдыз ордены, «Бөек Ватан сугышы» ордены, күпсанлы медальләр белән бүләкләнеп, 1946 елны гына кайта әти.

Сугыштан соң Казан авыл хуҗалыгы институтына читтән торып укырга керә. Аннары ике еллык Югары партия мәктәбен тәмамлап, гомере буе партия-совет органнарында: Чүриле, Дөбъяз, Биектау районнарында партоешма секретаре, колхоз рәисе; соңрак Биектау районының Ямаширмә авыл советы рәисе булып эшләде. Ул елларда Ямаширмә авыл советы 12 авылны берләштерде. Безнең өйне «Дом советов» дип йөрттеләр. Кешеләр әтине эштә туры китерә алмаса, туп-туры өйгә киләләр иде.

Әниебез Зөләйха Минһаҗ кызы – үзе дә авыр тормыш юлы узган, сынауларны күп күргән кеше. Сугыш елларында һәм сугыштан соңгы чорларда Кукмара районында прокуратура тикшерүчесе булып эшләгән ул. Аның тарихы болай: Арча педагогика училищесын бик яхшы тәмамлаган дүрт кызны, ризалыкларын да сорап тормыйча, кыска сроклы юридик курсларга юллыйлар. Ир-ат тикшерүчеләр – сугышта, бары-югы өчен кулга алынганнарның эше тартма-тартма булып өелеп ята. Әле балалыктан да чыгып җитмәгән әнигә менә шул эшләрне тикшереп, карар чыгарырга туры килә. Аңа берничә мәртәбә аталар да. «Авылларга атка атланып чыга идек», – дип сөйләгәне истә. Югары педагогик белемне әни соңрак, өч бала анасы булганнан соң алды. 35 ел Биектау районы Ямаширмә урта мәктәбендә рус теле укытучысы, уку-укыту бүлеге мөдире булып эшләде. РСФСРның атказанган укытучысы дигән мактаулы исемгә һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденына лаек булды. Ул гомере буе әбигә – кайнанасына, ә Бибиәсма әби безнең әнигә рәхмәт укып яшәделәр.

Әтинең арабыздан киткәненә 26 ел. Сугыш турында сөйләргә яратмый иде ул. Алай да әтидән ишеткән берничә сугыш хатирәсе күңелдә әле. «Сталинград янында Идел яна иде, – дип сөйләгән иде ул. – Бу тәмуг иде». Чигенгәндә, фашистлар ягулык цистерналарын шартлатканнар, Иделгә агып төшкән ягулыкка ут кабып, елганы көймә белән кичүчеләр тереләй янып үлгән ул чакта.

Көз көне Сиваш сазлыгында элемтә сузып, өч тәүлек ач килеш салкын су эчендә үзебезнең фронт килгәнен көткәннәрен сөйләгәне булды. Шул вакытта әтинең ике як үпкәсе дә кабара. Соңрак шул авыруы гомеренең вакытсыз өзелүенә сәбәпче дә булды.

Өченче эпизод Варшава шәһәрен азат итү белән бәйле. Бер йорт подвалыннан яшь бала тавышын ишетә ул. Безнең сугышчыларга ялгыз гына йортларга керү тыелган була, чөнки фашистлар аларны миналап калдыра. Ләкин әти үзәк өзгеч тавышка түзә алмыйча, үзе генә подвалга төшә. Аннан әнисенең үле гәүдәсе янында елап утыручы 2-3 яшьләрдәге кыз баланы алып чыгып комендатурага тапшыра.

Бүген без әтинең истәлекләрен барлыйбыз. Ярый әле сугыш ахырында эшләгән альбомын, сугышчан бүләкләрен, үз кулы белән ясаган картасын безгә тапшыра алган ул. Бу истәлекләрне без үз варисларыбызга тапшыра алабыз.

Алсу ЯРУЛЛИНА,
Татарстан Фәннәр академиясенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

яшәеш

МӘХӘББӘТ КҮКЛӘРДӘН ГЕНӘ ИҢМИ

Бәхеткә юллар һәрчак урау. Хатын-кыз бәхетенә – бигрәк тә. Нигә шулай икән дип уйлыйсың да, кайчак сәбәпнең бары үзеңдә икәнен аңлап, аптырап та каласың. Бәхет киләсе юлга, «ярамый»лардан таш кыя өеп куйгач соң... Күңелең ишекләрен мең йозакка бикләгәч... Иң мөһиме – вакытында тукталып, уйлана белергә кирәк. Күңелеңдәге сорауларга җавап табарга. Дөресрәге – үз-үзеңне табарга... Казан федераль университетының өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Резеда САФИУЛЛИНА моны эшли алган. Ә хатын-кыз бәхетле икән – аның янәшәдәге якыннары да бәхетле.
Ачыктан-ачык сөйләшәбез.



Улым өйләнгәч, күңелемдә үзәк өзгеч бер хис туды. Барысы да шуннан соң башланды... Хәзер аңлыйм, бу яңалыкны болай авыр кабул итүемнең берничә сәбәбе булган.

Беренчедән, ул минем олы балам. Аны тәүге тапкыр кулыма алганда ук миңа шундый ачык итеп, шундый тирәннән карады! Әллә нинди хикмәтләрне аңлаган күз карашы иде ул... «Бу баланың анасы булырга хакым бармы икән? Мин моңа әзерме? Бу балага лаекмы?» – дип уйлаганым истә... Аммарга шуңа да кечкенәдән мөнәсәбәтем башка булды, бик хөрмәт иттем. Бер елдан инде газиз, сөйкемле кызым туды. Моңарчы улыма гына биргән ана назы, ана җылысы икегә бүленде. Моның өчен дә үземне гаепле дип саныйм... Аннан без әтиләре белән аерылыштык һәм гаиләдәге ир-ат роле Аммарга йөкләнде. Ир-ат булмаган гаиләдә күп очракта бу вазыйфа шулай малайлар өстенә төшә икән. Башка кешегә кияүгә чыга алам дип уйламадым да. Ачы тәҗрибә күз алдымда булды бит. Әни, ире үлгәч, кабат гаилә корып карады. Үги әтинең ни икәнен күрдем... Үземне гел әнинең бәхетенә бер киртә итеп сизә идем. Балаларымның да моны кичерүләрен теләмәдем. Шуңа да кабат-кабат ирем белән кушылдым. Өч тапкыр! Никадәр стресс бит бу! Кушылганда «бар да әйбәт булачак» дип өметләнәсең. Мөнәсәбәтләрне өр-яңадан корасың. Кемдер белән бу йортны кабат төзегәнче, нигезен, диварларын күтәргәнче, аны кабат шул белгән кешем белән торгызып карыйм дип уйладым... Әмма...

Бу бала шундый атсмосферада үсте. Күз алдыңа гына китер: әтисе белән әнисе талаша да аерылыша, талаша да аерылыша... Җитмәсә, машина карыйсы бар, йорт ремонтлыйсы (үз йортыбыз белән яшибез, ир-атсыз мондый йорт тоту бер дә җиңел түгел: әле монда нидер төзәтәсе, әле тегендә)... Ана белән бала арасындагы сепарация – психологик яктан бер-беребездән аерылу чоры булмады безнең.

Йөргән кызы белән беренче тапкыр таныштыруын хәтерлим. 9 Май бәйрәме алды иде. Аммар «Туган авылым» күңел ачу үзәгендә ниндидер проект оештырды. Шул кичәгә Әдинә дә килде. Аның Аммарга ничек яратып (һәм шул яратуны яшермичә!) каравына шунда ук игътибар иттем. Әни кешегә тагын ни кирәк?! Мин аны шунда ук якын иттем.

Әйе, барысы да яхшы иде. Аннан туй көне җитте, һәм миңа әллә нәрсә булды. Кинәт үземне бик ялгыз хис итә башладым. Моңа гаепле дә табылды – Әдинә. Ул бит миннән улымны алып китәргә җыена... (Психологиядә моның сәбәбен болай дип аңлаталар. «Синдром брошенного ребенка» дигән нәрсә бар икән. Миңа турыдан-туры кагыла инде ул... Әни артист бит (Резеда – Татарстанның халык артисты, җырчы Гөлзадә Сафиуллина кызы. – *Г. С.*), гел юлда, гел гастрольләрдә. Аның назы миңа кечкенәдән җитмәгән... Башта авылда әби белән бабайда үстем, аннары – музыка мәктәбенең интернатында. Психологлар әйтүе буенча, кемдә бу синдром бар, үзенә бик якын кеше белән элемтәсе ерагаюны ул гел авыр кичерә.)

Барысы да кайнананың көнләшүеннән башлана.

Акыл белән аңлыйм – улымның юлына шундый әйбәт кыз очравы бик зур бәхет. Ә икенче яктан... үзем белән бернәрсә эшли алмыйм! Йөрәгем, җаным елый... Моны берәүгә дә белгертмәскә, яшерергә тырышам, тик шундый кызык моментлар булды. Хәзер кызык тоела инде, ә ул чакта...

...Иртәгә туй буласы көн. Бауман урамы буйлап барам. Бер фирмада Аммар белән Әдинәнең фоторәсемнәреннән видеоролик әзерләдек. Күз алдымнан бөтен балачаклары үтте... Күңелем мөлдерәмә тулды... Бауманда «Мин татарча сөйләшәм» акциясе бара. Мин башлаган акция! Ә мин елыйм... Тыела алмый елыйм. Нигә – белмим... Үземне шундый ялгыз тоям һәм кемдер эндәшүен телим, янымда андый кеше булмагач, үзем-үзем эндәшәм... Акциядә катнашучы яшьләр янына килеп җиттем. Барысы да исәнләшәләр... Кайчандыр мин оештырган чара хәзер шундый колач җәйгән, иртәгә улым өйләнә – мин дөньяда иң бәхетле кеше булырга тиеш кебек. Эчемдә нинди утлар янганын кемгәдер белгертсәм, аңламаслар, мөгаен. Җанда бушлык. Салкын бушлык...

Туй көнендә Әдинәнең күләш буларак үзен бик бәхетле итеп тоюын теләдем. Һәм шуның өчен барысын да эшләдем. Хәтта болар кайтасы йортка, алданрак барып, бөтен җиргә шәмнәр кабызып куеп, ишектән түшәккә кадәр чәчәк таҗлары сиптем... Аны тагын да бәхетлерәк итәргә, җылыга, рәхәткә төрергә тырыштым. Үземнең елыйсым килә – ә бит боларның берсе дә миңа эләкмәде...

Туйдан соң киленнең әти-әниләре безгә кунарга кайттылар. (Алар Чистайда яшиләр.) Озак кына сөйләшеп утырдык, чәйләр эчтек. Әтисенең кызга мөнәсәбәтен күзәтәм. Кызын шундый ярата! Кая гына кунакка барсалар да, алар беркайда да кунмыйлар, өйләренә кайталар икән. Ә монда калдылар! «Аларның бар да әйбәт икәненә ышанасым килә», – ди. Җаныма пычак белән җәрәхәт ясаган кебек булды... Мин бит әтисез үскән бала. Беркайчан шундый наз, кайгырту күрмәдем: мин болардан мәхрүм идем. Көнләшәм! Аңлыйсыңмы? Бер яктан, үземдә булмаганны киленемдә булдырырга тырышам, ә икенче яктан... Йөрәк әрнүенә түзәрлек түгел. Күңелдә шундый каршылыклы хисләр...

Иртән сәгать алтыда ук әни белән аяк өстендә идек. Шулпа куеп җибәрдек – кодаларны сыйларга кирәк. Ә бит йола буенча ничек булырга тиешлеген беләм: туйдан соң килен, алъяпкыч бәйләп, табындагыларны кунак итәргә тиеш. Осталыгын күрсәтергә аның чираты җитте... Ә алар әле һаман анда – мин чәчәк җәйгән түшәкләрдә... Токмач камыры ясарга тотындым. Ә үзем әнигә: «Бу бит килен токмачы булырга тиеш», – дим. Йола буенча шулай тиеш! Мин тырыштым, туйны

Сиңа дигән кеше каядыр бар
дип ышанырга гына кирәк икән.

үткәрдек, һәркемнең күңелен күрдек. Инде хөрмәт күреп утырасы иде бит... Әни: «Резеда, җитте инде. Күңелеңне киң тот», – ди. Мин бит тар күңелле түгел! Безнең өйдә гел кеше – мин үземне кунакчыл дип саныйм. Ә монда... үземне бернәрсә эшләтә алмыйм! Яхшы түгеллеген дә аңлыйм. Үземә оят, тик... туктый алмыйм. Боларга өч тапкыр шалтыратырга өлгердем. «Аммар, кайчан киләсез инде? Табынны көйләргә безгә ярдәм итегез», – дим. «Кызларына аңлатмаганнар», – дип, эчтән генә Әдинәнең әти-әнисен гаепли башладым. Кыскасы, бер көн эчендә классик кайнана булдым да куйдым. Үз-үземә шаккатам!

Камырны ясадым, тик җәймәдем. «Ул җәйсен. Килен токмачы икән, килен токмачы булсын!» – дим әнигә. Яшьләр килеп керүгә: «Әдинә, йола буенча килен сыйларга тиеш туйдан соң. Килен токмачын синнән көтәбез», – дим. Йөзе коелып төште. Аның тормышта бөтен нәрсәсе идеаль булырга тиеш, ә монда ул аптырап калды. «Мин бит белмәдем... Аммар, син нигә миңа әйтмәдең?» – ди. «Ә нигә моны Аммар әйтергә тиеш иде?» – дип уйлыйм тагын. Ярый, токмачны җәйде, ашны пешердек. Кунакларны табын янына чакырдык. Без өстәл әзерләгәндә Әдинәнең утырып торуы миңа ошамый гына бит. Шулкадәр ваклык миндә – үземдә мондый нәрсәне гомер күргәнем, сизгәнем юк иде. «Әдинә, син безгә булышырсыңмы?» – дип төрттерәм. Ул бала тагын коелып төште. Ә мин ачуланып түгел, елмаеп әйтәм. Тик елмаюым бер дә җылы килеп чыкмый... (Башка әниләр белән соңыннан бу хакта бик күп сөйләштем. Килennәрен беренче көннән үз баласы кебек кабул итүчеләр байтак. Яратуга коенып үскән кеше, башкалар белән аны бик теләп бүлешә һәм ул ярату аңарда саекмый. Ә миңа, әйткәнемчә, алардан читтә булганга, әти-әни яратуы җитмәде. Үзем яратуга туймаган, шуңа да аны башкаларга биреп бетерә алмыйм. Шактый нечкә психологик момент бу, кемдер аңлап та бетермәс.)

Ярый, кунакларны озаттык, яшьләр дә үзләренә китте. Ә миңа начар! Үземне кая куярга белмим... «Әни, нишләргә икән?» – дим, елыйм. «Кызым, син Аммарны югалттым дип уйлыйсың. Юк, син аны югалтмадың, хәзер улың һәм тагын бер кызың бар», – ди ул миңа. Әнине ишетмим... Кызым Ширинны да котыртам: «Әдинә шундый, мондый», – дим. Сүзләрем аның күңеленә дә бал-май булып ята – ул да бит абыйсын көнләшә. Ә әни бездән акыллырак: «Туктагыз, сез нишлисез?» – ди.

Аммар икенче көнне: «Әни, хәлләрегез ничек?» – дип шалтыратты. Ә җаным бит тоташ яра! «Улым, әйтерсең, ярты ягымны кисеп алганнар», – дим. «Әни, син нигә алай әйтәсең?» – диде ул аптырап. Аңа да моны ишетү җиңел түгеллеген дә уйламыйм – җанымдагы авыртуны гына тоям. Чынлап та шулай, йөрәгемнең яртысын кисеп алганнар да, ул әрни дә әрни кебек... Янында ирең булса, бу кичерешләр бөтенләй башкача узадыр. Ә без өч хатын-кыз калдык. Йөрәгем авыртып, «ашыгыч ярдәм» чакырткан чаклар да булды. Чыга гына алмыйм бу халәттән!

Аммар безгә килә, ә минем йөзем гел караңгы. (Сатлыкҗан бит ул!) Ширин да учакка утын өсти – минем яклы. «Әни, аңламыйм – нәрсә булды, мин үземне гаепле сизәм», – ди Аммар. Ул, Әдинә, мин – өчәү бер көнне утырып сөйләштек. «Син мине дөрес аңла, Әдинә, – дидем. – Аммарны бик яратам. Моңарчы ул яраткан хатын-кызлар без өчәү идек. Ә хәзер ул мәхәббәтен синең белән дә бүлешә... Сезнең өчен бик шатмын, бәхетле булуыгызны телим, тик миңа әлегә җиңел түгел. Бу вазгыятькә иялэшергә кирәк». «Мин сезне аңлыйм», – диде ул.

Мин аңа матур итеп әйттем. Күпләр болай ачыктан-ачык әйтми, ә әйтергә кирәк.

Дус кызыма шалтыратам: «Вероника, мине бөтен кеше котлый. Шундый шатлык, диләр. Хәсрәтемнең зурлыгын белсә икән алар?! Нинди хәл соң бу минем белән? Оят, нишләргә белмим. Үземә үзем нәфрәтләнәм», – дим. «Әйе, тагын бер дус кызым улын өйләндергәч: «Бөтенесе «котлыйм» диләр, ә минем бүре булып улыйсым, тәгәрәп елыйсым килә», дип шаккаттырган иде», – диде ул. «Миндә генә түгел икән бу хәл», – дим. Алай ук начар кеше түгелмен икән әле... Шуннан уйлана башладым. Бездә улын өйләндергән кайнананың хис-тойгыларын чагылдырган әдәби әсәр юк икән бит. Ә мин китап укып тәрбияләнгән бала. Төрле ситуацияләрендә үзеңне ничек тотарга икәнен матур әдәбияттан укып өйрәнгән – тормыш моделен китаптан алганмын. (Дөрес, алар алдавыч модельләр булырга да мөмкин. Бездәге иллюзияләрнең күбесе әдәбияттан килә.) Шунда аңладым – бу ситуациягә әзер түгел икәнмен. Матур әдәбиятта бүгенге кичерешләремне чагылдырган әсәрне очратмадым. (Минем кебек, үз-үзен битәрләүчеләр тагын бардыр ул. Бәлки, бу язманы укыгач, гаеп үзләрендә генә түгеллеген алар да аңлар.)

Әкрен-әкрен мин дә тормышымдагы бу яңалыкка иялэшә төштем. Аннары тагын бер нәрсәне аңладым. Беренче ирем белән аерылышу җиңел генә узмады: җанда ярасы, сызлавы калды. Шуңардан качу өчен, мин моңарчы гел эш, балалар дип яшәдем, шәхси тормышым булмады. Ширин тиздән кияүгә чыгар, Мурад та өйләнер, ә мин берүзем калырмын. Яраларым белән... Ничек яшәрмен соң? «Тукта, Резеда, үзеңне яңа тормышка әзерләргә кирәк», – дим. Эш – яшәвебезнең мәгънәсе булырга тиеш түгел ләбаса. Күпләр шулай алданып яши. Чын бәхет исә үз-үзең белән гармониядә булу ул. Эшкә, иргә, балаларга, әти-әнигә яраклашу түгел. Миңа ялгызлыктан арынырга – шәхси тормышымны корырга кирәк иде...

«Tatarlove» танышу сайтына игълан яздым. Җәен, ял иткән көннәрдә башыма килде бу уй: «Карале, шундый

сайтлар бар бит, мин дә анкета тутырып карыйм әле. Күз күрер... Берни дә килеп чыкмаса, яңа бер тәҗрибә булыр», – дим. Кызык итеп яздым. Уңган да мин, булган да, матур да, акыллы да, тик бер кимчелегем бар – дөреслекне маңгайга бәреп әйтәм. Ир-ат минем янда үзен көчле хис итсен өчен көчсез булып күренергә җыенмыйм. Үз-үзләренә ышанычы булмаганнар, язмагыз, дидем. (Хәзер тренинглар хатын-кызны ир-атка ул теләгәнне генә әйтергә, аңа яраклашып яшәргә өйрәтә. Бу, бәлки, дөрестер дә, тик бу бит мин түгел!)

Кызык тормыш башланды! Хатлар ява: укыйм, җавап бирәм. Тирә-юнемдә ир-атларны күрә башладым! Моңарчы студентларны күрә идем, олы галимнәрне, хезмәттәшләрне. Баксаң, янымда ир-атлар да бар икән бит! Арада кызыклы гына шәхесләр дә очрый. Языша башлауга, әңгәмәдәшең белән интеллект дәрәҗәсе бертигезметүгелме икәне, эрудиция, яшәү тәҗрибәсе, тормышка мөнәсәбәт – бар да ачыклана. Минем өчен ул кешенең балалары белән элемтәсе ныклыгы, гаилә тәҗрибәсе булу мөһим иде. Шул чакта гына ул мине аңлаячак, шул чакта гына ике арада өзгәләнмәячәк идем.

Әнвәр миңа игъланны куюга яза башлады. Ул миннән 15 яшькә өлкән. Тормышын сөйләде – зур сынаулар аша узган. 16 яшьлек улын үзе белән чит илгә алып киткән. 10 ел инде икәү генә торганнар. Мин дә бит журналист – аңа сораулар яудырам. Бернәрсә дә килеп чыкмаса, һичьюгы язмышын язармын дип уйлыйм. «Мин – Швециядәге татар язучысы», – дип язды ул миңа. (Без хыялыйларга банкир түгел, язучы кызыграк!) Повесте чыккан – автобиографиясен швед телендә язган. Рухи кыйммәтләребез туры килә. Мин намазда, шуның белән берррәттән йога, медитация белән кызыксынам, ул да шулар аша үткән: әле туксанынчы елларда, армиядә үк кызыксына башлаган – бер телдә сөйләшәбез! «Ә сезгә хатын-кыз нәрсәгә?» – дим. «Аңларсызмы, юкмы, – дип язды ул. – Кеше күңелендә гармония тойсын өчен, инь һәм янь комплекста булырга тиеш». Мин дә шулай уйлыйм бит! Барысы да туры килә кебек...

Аннан ул Казанга килде. Институтта күрештек. Яшь арасы зур дип барыбер борчыла идем – без аны сизмәдек. Беренче мизгелдән үк җиңел аралашып киттек. Ел азагы, иң тыгыз вакыт – мин эштә кайныйм. Буш вакытым бөтенләй юк диярлек. Ул лекциямә керде дә миңа карап утырды. Рәхәт! Безне бер-беребезгә магнит кебек тарта. Дәрестән соң кафега кереп каһвә эчтек. Көлешәбез, шаяртабыз... Аралаша-аралаша тагын да якынайдык. Тик куркасың! Мәхәббәткә ышанырга куркасың. Авыр тәҗрибә бар бит... Күңел кабат җәрәхәтләнмәсме? Ә ышанасы, яратасы, яратыласы килә. Мин шундый кеше: кем кемгә җылыны күбрәк бирде, кем күбрәк назлады, кем түләде... дип, аптекадагы кебек санап утыра алмыйм. Бу миңа хас түгел. Яратам икән – бөтен барлыгым белән яратам...

Бәхеткә тиз генә ияләшә алмыйсың икән. Һәр борылыш артыннан нинди дер күңелсезлек көтәсең. Кытыршы моментлар бар, билгеле, әмма күңелләрдә мәхәббәт булганда барысын да җиңәсең. Кайсыбызда кимчелек юк?! Аңлашылмаучанлык килеп туганда гел шуны искә төшерәм.

Никах укыттык, кечкенә генә туй ясадык. Сиңа дигән кешене табу, очрату – вакыт эше икән. Хәзер бит төрле тренинглар бик күп, хыялыңны визуальләштерергә өйрәтәләр. Ә алар чынлап та эшли! Ничек кенә әле! Тормышымның башка төсмере барлыкка килде. Ә мин бит бары бу яңалыкка үз тормышыма керергә рөхсәт иттем.

Улымны киленемнән көнләшү күптән онытылды. Мин Әдинәне бик яратам! Чиста күңелле ул. Шатлыгы да, борчуы да шунда ук йөзенә чыга – бу яктан үземә охшаган. Аммарны илһамландыра белә, аңа ышана. Ир кешегә тагын ни кирәк?! Аларга бик рәхмәтлемен – бәхетемә юл ачтылар! Минем бит әле кызым да бар. Ул да мәхәббәткә, гаилә бәхетенә ышана алсын өчен, модель кирәк. Үзең үрнәк була алмыйсың икән, күпме сөйләсәң дә, балаларны инандыра алмыйсың. Ширин шулай әйтте дә: «Әни, син дә бәхетеңне тапкансың икән, димәк, бу, чыннан да, мөмкин», – диде.

Кечкенә улым да безнең мөнәсәбәтләрне күрсен, мәхәббәтнең чын була алуына ышансын иде. Аңа да бит инде 16 яшь тула. Киләчәктә әтиләре белән минем модельне кабатлауларын телимим.

Рухи үсеш юлында юлдаш кирәк. Һәм янәшәңдәге кешенең дә максаты шул ук булырга тиеш. Әнвәр белән бер-беребезгә моны гел әйтеп торабыз. Без нәрсәгә очраштык соң? Бер-беребезгә тагын да яхшырак булырга булышырга түгелмени?

Бәхетле булуның сере нәрсәдә соң? Минем үзем өчен бер генә рецепт бар, ул – ихласлык. Үз-үзеңә тугры булу. Тик моның өчен үз-үзеңне аңлау кирәк. Безнең илдә инде ничә буын катаклизмнардан арына алмый яши: революция, гражданнар, Бөек Ватан сугышлары, үзгәртеп кору... Кая монда үз-үзеңне аңлау?! Үз теләкләреңне белү. Моны яшьтәшләремнең күбесе аңламый да. Алар нәрсә телим дип түгел, мин кемгә, нәрсә тиеш дип яшәргә ияләшкән. Ә бәхет ул – үз-үзеңне ишетү, үз-үзең белән гармониядә булу. Бу – ихласлык та, башкалар алдында да, үз-үзең каршында да ачык булу. (Без бит күп очракта үз-үзебездән дә качабыз. Мин менә эшкә, балаларга «качтым».) Кеше шуны аңлый һәм үз-үзенә кайтырга тырыша икән, бу очракта аның әле бәхетле булырга мөмкинлеге бар. Әмма универсаль рецепт юк. Хәтта үз ярыңны тапканда да. Аны саклар өчен дә бик күп хезмәт салырга кирәк. Без бит инде икебез дә формалашкан шәхесләр. Шуңа күрә кайчак йомшаклык та күрсәтергә кирәк, түзем, сабыр булырга да. Юл бирә белергә дә. Шул ук вакытта үзеңне дөрес бәяләргә дә онытмаска.

Әнвәрне очратканчы, соңгы догам: «Йә Раббым, мәхәббәт бир миңа», булды. Нинди дер бер ир-атны түгел, гомумән, кешеләрне ярату сәләте бир дип сорадым. Яралангач, йөрәк ябыла... Ә ярату булмаса, әллә нинди яхшы кешене дә янәшәңдә саклый алмыйсың. Мәхәббәт күкләрдән төшми...

Гөлнур САФИУЛЛИНА язып алды.

PRESSA



Без аның белән бергә алтмыш ел гомер иттек. Туган җирләребез арасы бик ерак иде. Ул Татарстанның көнчыгышында туып-үскән, мин – көнбатышында туган мишәрмен. Аны үстергән төбәк Ютазы районының Кәрәкәшле авылы, мин туып-үскән төбәк Чүпрәле районының Мунчәли авылы.

Нурмөхәммәт
ХИСАМОВ

ҖАНКИСӘГЕМ ФӘҺИМӘ

Танышуыбыз университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә кабул итү имтиханында булды: бер парта артында утырып, татар әдәбиятыннан инша яздык. Уку барышында бер-беребез белән нык кызыксынып дуслашып китү тиз булмады. Ул төркемебезнең старостасы иде, мин комсорг саналдым. Икебез дә иң яхшы билгеләргә укыдык.

Якын багланышка сәбәп икенче курсны тәмамлагач, Диләрә Гарифовна Тумашева җитәкчелегендә Түмән өлкәсенә себер татарлары телен өйрәнү өчен экспедициягә киткәч туды. Татар авылында башта концерт бирәбез, мин Муса Җәлил турында доклад ясыйм һәм җырлыйм, аннары авыл кешеләре белән очрашып, алардан сөйләм үрнәкләрен язып алабыз.

Бервакыт төркемебез икегә бүленеп, төрле авылларда эшләргә кереште. Без өчәү – Фәһимә, Шәүкәт исемле егет һәм мин – бер фатирга урнаштык. Фәһимә безгә аш пешерә, чәй кайната, шуннан халык арасына чыгабыз. Аның кешелек сыйфатларын шунда күрә башладым. Мин мәктәптә, гаиләдә ниләр күргәнемне сөйлим, шигырьләремне укыйм, зарларым белән уртаклашам, ул игътибар белән тыңлый, үз хәлләрен сөйли. Аның ике апасы укытучы булган, җизнәсе югары чинлы хәрби. Әтисе Миргали

Хатыным үтә яхшы күңелле кеше иде, студентларын үзенең балалары кебек күрде.

Сталинград сугышында һәлак булган. Әнисе Мәрхәбә апа да укымышлы, белемле булган.

Без экспедициядән сердәшләр булып кайттык, бер-беребездән аерылмас якынлык урнашты. Шул еллардагы хис-тойгыларым шигырь юлларына күчкән иде.

Мин эзләдем әллә кайлардан,
Йолдызлардан аны, айлардан,
Романтик хыял, җырлардан,
Ерак-ерак килер еллардан.
Ә йөргәнбез үзебез янәшә,
Бәхәсләшә, укый, көрәшә...
Җиргә кайтты хыял йолдыздан,
Мин дустымны таптым шул кызда.
Якын иттек ерак елларны,
Уртак иттек барыр юлларны.

Борчылу-шатлыкларны бары икәү уртаклашабыз, өченче курста өйләнешеп тә куйдык.

– Фәһимә белән гаилә корырсыз дигән уй һич башыбызга килмәде, ничек болай булды? – дип, иптәшләр сәерсенеп сорау бирәләр.

– Толстойның «Война и мир» әсәрен укыганыгыз бармы? Язучы «брак совершается на небесах» ди анда, – кебегрәк җавап бирәм.

Мин Фәһимәгә багышлап «Кәрәкәшлем» дигән шигырь яздым, композитор Рөстәм Яхин шуңа көй иҗат итте. Анда мондый юллар бар:

Ярышсыннар, әйдә, авыллар,
Ярышырлык синең даның бар.
Синдә үскән алсу иреннәр
Бөтен илгә данлы киленнәр.
Кәрәкәшлем, минем Кәрәкәшлем,
Ярышырлык синең даның бар...

Фәһимә, университет тәмамлагач, шунда ук эшкә калды. Аспирантурада укып, фән кандидаты булды, аннан соң доктор, профессор дәрәҗәсендә китаплар чыгарды. Мин аларны укып-укып куям да, галимәнең колачына, тирән фикерләвенә таң калам. «Татар теленең тарихи грамматикасы» дигән соңгы китабын үзе алдында укып чыктым да сокланудан елап җибәрдем. Ул югары дәрәҗәдә үсешкә ирешкән тел белгече иде.

Киленебез – профессор Венера Хисамова: «Фәһимә Миргалиевна – төрки-татар тел белемендә бөтен бер эпоха», – дип яза безнең җәмәгатем белән уртак юбилей китабына кергән «Кайнанам турында» («О моей свекрови») дигән мәкаләсендә.



■ Гаиләбездә өч улыбыз туды, кечеләре игезәк иде. Алар татар мәктәбендә укыды. Айваз – тарихчы, Айдар белән Нияз талантлы рәссам булып үстеләр. Фотода беренче улыбыз Айваз янында бала тудыру йортында. 3 декабрь, 1958 ел.

Фото: Хисамовлар гаиләсе архивыннан

Гомеренең соңгы еллары газапта үтте. Университетта илле ел дәвамында аяк өсте студентларга лекция укуның нәтиҗәсе буларак, аякларында варикоз барлыкка килде. Соңгы арада кулыннан тотып йөрттем. Бер кулында таяк булды, икенче кулыннан мин тота идем. Каракаршы чәй эчеп утырганда еш кына: «Син – минем бәхетем», – дия иде. «Ә минем бәхетем – син», – дип кабатлый идем.

Аңа өйдә йөрү дә коточкыч газап булды. Бүлмәдән бүлмәгә күчәргә мине чакырды. «Синең кулың» дигән шигырем аңа бик ошый иде, миңа гел, шул шигыреңне укы әле, дия иде. Ә мин укыйм.

Синең йомшак ак кулларың
Фәрештә кулы сыман.
Кулга-кул узган юлларым
Йолдызлар юлы сыман.

Ничекләр генә сынамас
Язмышның дулкыннары,
Кулга-кул безне сыгалмас
Җилләре, упкыннары.
Авыр йөктән курыкмый йөрәк,
Шифа булгач кулыңда.
Йомшак кулың иң нык терәк
Миңа гомер юлында.

Яктыра кебек безнең юл
Синең саф карашыңнан.
Атлыйбыз икәү кулга-кул
Йолдызлар арасыннан.

Мин бу шигырьне Төркиядә дә укыдым. Халыкара конференциягә җыелган галимнәр арасында минем кебек шагыйрьләр дә бар иде.

Узган елның сентябрендә шул гүзәл кешем – җанкисәгем Фәһимә якты дөньядан китте. Озату мәрасименә җыелган халыкның хисабы юк: Казанның бар күренекле кешеләре җыелган иде. Аларның байтагы Фәһимә ханымны «бөек галимә» дип атады.

Һәр шатлыгымны, һәр борчуымны аның белән уртаклашып яшәдем. Аңлый, үз итеп кабул итә, хәлне җиңеләйтә иде. Хәзер шундый чакларда күздән бары яшь килә. Минем өчен бөтен дөньяның яме Ул иде...









ЧҮЛМӘКЧЕДӘН КҮРМӘКЧЕ

Лилия ГӘРӘЕВА

Беренче карашка гади кебек тоела бу хезмәт. Ләкин беренче карашка гына шулай ул. Бер йомарлам балчыктан нәфис кувшин килеп чыксын өчен чүлмәкче тәгәрмәчен әйләндерәсе дә әйләндерәсе әле...

Бер чүлмәкченең өйрәнчеге булган. «Син инде остардың, үз эшеңне ач», – дигән аңа оста. Укучысы, туган шәһәренә кайтып, остаханә ачкан. Ләкин ничек кенә тырышмасын, аның чүлмәкләре останыкы кебек килеп чыкмаган. Сәбәбен укытучысыннан барып сораган егет. «Син берәр савыт ясa, ә мин яныңда карап торам», – дигән остаз. Барысын да ул өйрәткәнчә башкарган укучысы, ләкин, чынлап та, чүлмәккә нидер җитешми кебек тоелган. Сәбәбен тиз ачыклаган оста: «Мичтән алгач, тузанын өрмәдең һәм кулың белән сыпырмадың бит», – дигән ул. Чүлмәкче турындагы бу кыйссаны искә алуыбыз юкка түгел. Язмабыз герое әйтүенчә, монда һәр хәрәкәт, һәр ымның үз фәлсәфәсе бар. Җаныңа рәхәтлек алып эшләгәндә генә чүлмәкләрең чын сәнгать әсәренә тиң була һәм үз хуҗасына куаныч китерә.

Бу эштән дә борынгырак һөнәр, мөгаен, юктыр да. Тимергә тотынганчы, башта балчыкны буйсындыра кеше. Безнең эрага кадәр 6 мең ел элек үк аннан үзләренә кирәк савыт-сабаны ясый башлаган инде адәм балалары. Андый савытта ризыкның озак саклануын белгән алар.

Шулкадәр мавыктыргыч шөгыль икән ул чүлмәк ясау. Әле кулың балчыкка орынганчы ук, күңелне бер хис биләп ала. Балчык үзе шундый сыгылмалы, шундый тыңлаучан… Балчык савытларның да җаны бар сыман. Аларны ясаучы оста үзе дә ниндидер бер тылсым ияседер кебек.

Рәссам-керамист Рафилә САКСОНОВА – чүлмәкләргә җан өрүче шул тылсым ияләренең берсе. Мәктәпне тәмамлаганнан бирле җанына рәхәтлек бирүче шушы эш белән мәшгуль ул. Ә бит кулына яңа гына аттестат алган яшь кызның нияте чүлмәкче түгел, бизәк төшерүче һөнәрен үзләштерү була. Тик ул елны Кунгур югары сәнгать училищесында бизәк төшерү серләренә өйрәтү өчен студентлар җыймыйлар. Документларын башка факультетка тапшырырга туры килә. Гомерлек хоббие булачак керамика эшенә әнә шулай кереп китә Пермь өлкәсенең Барда кызы Рафилә. Тормышының шушы юнәлешкә борылуын очраклылык дип бәяләми ул, Аллаһы Тәгаләнең үзен дөрес юлга күндерүе дип саный. Әниләреннән күреп, өч баласы өчен дә чүлмәкче эше хоббига әйләнгән.

Рафилә ханым белән без ул уздырган мастер-класста танышкан идек. Тирә-юнен бала-чага сырып алган, берсен-берсе уздырып, чүлмәкче тәгәрмәчен зырылдаталар. Гап-гади балчыктан уч төпләре астында чүлмәк яралу мизгеле шундый кызык аларга! Кайсыныкы – уңга таба авыш, кайсыныкы – сулга, аның каравы, үз куллары белән ясалган. Рафилә апалары ул савытларны мичтә яндырып, бер-ике көннән үзләренә тоттыргач, нинди шатлык кичерүләрен белсәгез!

Нечкә муенлы ваза, зур борынлы кувшин яки капкорсаклы май чүлмәге булып өстәлгә менгәнче, берничә этап уза кызыл балчык. Җир куеныннан

Дөньяда ике бертөсле кеше булмаган кебек, ике бертөсле чүлмәк тә юк. Бик теләсәң дә, алар бер-берсен кабатламый.

чыгаргач, аны башта суга салып чылаталар, аннары камыр кебек әвәлиләр, аннары чүлмәкче тәгәрмәченнән матур бер савыт булып кабаттан туа ул. Чүлмәк чын чүлмәккә әверелсен өчен, өч стихия: балчык, су, ут бергә туры килергә тиеш. Бары шунда гына утка да, суга да чыдам булачак.

Каршымдагы чүлмәкләрнең кайсы саргылт, кайсы караңгы коңгырт… Серен останың үзеннән белешәм. Бәлки, балчыгы төрле булганга шулайдыр. Юк икән, чүлмәкләрне сөт ярдәмендә шундый төрле төсләргә буйыйлар икән. Майлы сөт – балчыкка караңгы кучкылт төс бирсә, сыек сөт аксыл төскә кертә. Төс бирү – соңгы этап. 900 градуслы мичтә яндырып, киез белән ышкып шомартылган чүлмәкләрне сөткә чумырып, кабат мичкә урнаштыралар. Сөт белән каралту – борынгы технологияләрнең берсе. Рафилә ханымның үзенә дә борынгылык һәм табигыйлек бик якын.

– Балчык савытларны аллы-гөлле глазурь белән дә бизәргә мөмкин. Ләкин глазурь белән эшләргә яратмыйм. Андый чүлмәкләр ясалма кебек миңа. Балчыкның үз матурлыгы күренеп тормаса, чүлмәкнең җаны юк сыман, – ди ул.

Мине тагын бер сорау кызыксындыра: теләгән һәркем өйрәнә аламы бу һөнәргә, әллә соң ул талантлылар гына яулый алырлык өлкәме? Оста бермәл уйга кала.

– Мөгаен, гади генә савытларны һәркем ясый аладыр. Аның өчен кулны өйрәтү дә җитә. Иң мөһиме – сабырлык һәм түземлек кенә булсын. Беләсезме, балчык белән эшләү организмга да шифалы бит ул. Йөрәкне дә ныгыта, буыннарны да… Җылы бинада җылы балчык белән генә эшләргә кирәк. Элек аны суга болгатып эчкәннәр дә хәтта, – ди Рафилә Саксонова. – Әмма бу эшнең чын остасы булыр өчен аны бик нык яратырга кирәк. Акча эшлим дип кызыгучылар өчен дә түгелдер бу хобби. Бизнес һәм сәнгать, гомумән, үзара янәшә туры килә алмый торган төшенчәләрдер дип саныйм мин.

Чүлмәк ясау эшендә генә түгел, теләсә кайсы һөнәрдә дә уңышка ирешүнең төп сере – аны ярату, шул эшкә бар барлыгың белән бирелү. Нәкъ Рафилә ханым турында инде бу. Әнә шуңа күрә дә үзен бик бәхетле саный ул. Көенгәндә җанын тынычландыручы, тамагын туйдыручы, күңеленә рәхәтлек бирүче эше – зур бәхете аның.

КАМБОДЖА



Дөньяның табышмак кебек серле һәм куркыныч илен барып күрү, джунглида югалып калган шәһәрдә йөрү хыялы күптән бар иде инде миндә. Хыял белән чынбарлык арасына шактый еллар ятты. Шулай да мин үз дигәнемә ирештем: тылсымлы гыйбадәтханәләр, үтә алмастай джунглилар иленә аяк бастым. Ничекләр генә тасвирласаң да, Камбоджадагы матурлыкның йөздән бер өлешен дә җиткереп булмастыр.



Рәмзия КАШАПОВА

Табигатьнең һәм кеше куллары тудырган матурлыкның әйтеп аңлата алмастай серләреннән тыш, күңелле вакыйгалар, төрле маҗаралар һәрдаим озата барды безне. Иң беренче шаккаттырган нәрсә – Таиланд белән Камбоджа чиген узу булгандыр... Шау-шулы шәрык базарын күз алдына китерегез. Аның кыл уртасындагы шлагбаум аша бертуктаусыз төрле кирәк-ярак күтәргән кешеләр, йөк төялгән машиналар агыла. Алай гынамы, печән һәм җиләк-җимеш төягән мотоцикллар, буйволлар уза. Шлагбаум янында басып торган кеше бер күзе белән документларны, справкаларны тикшерә, икенче күзе белән чик аша узучыларны баштанаяк карап үткәрә. Азия турындагы комедияләрдән һич ким түгел. Бернинди чик сакчылары да, полиция йә хәрбиләрнең кырыс контроле дә юк монда. Чит ил кешеләренә йә ак тәнлеләргә махсус паспорт контроле бар барын. Камбоджа корольлегенә (илнең элеккеге исеме Кампучия) виза алгач, ерак юлдан арысак та, күтәренке күңел белән машинага таба атладык. Илнең тарихи истәлекле урыннары белән танышырга кирәк.

Өйдә идарә итүче әбигә караганда, кайчак дәүләт башлыгы белән килешү күпкә җиңелрәк.



Икенче шаккаттыргыч әйбер – «вандоллар» булды. Су, төрле эчемлекләр, магнитлар, җыен вак-төяк 1 долларга сатыла. Шуңа күрә бу илне без «Вандоллар» дип атадык. Акчаны ярыйсы эшлиләр. Бер шешә су 1 доллар торсын әле. Таиландта ул 30 цент. Ә Камбоджада бер долларга 20 кг дөге алырга була! Кунакханәдә краннан ага торган су да безнең өчен күңелле яңалык булды. Урнашу белән үк душка йөгердем, тропикның артык дымлы һавасы җәзага тиң икән: киемнәр юеш, тәнгә сылаша. Югач та кипми җәфалыйлар әле. Бу хәерче илдә аз гына уңайлыклар өчен дә сөенерсең. Әмма Камбоджада да таң калырлык әйберләр җитәрлек икән. Краннан аккан су шулкадәр йомшак, чиста иде – тән тиресе шундук ял элләкән кыяфәткә керде, ефәк кебеккә әйләнде. Мондый суга Россиядәге теләсә кайсы санаторий кызыгырлык. Безне тантаналы кичке ашка чакырдылар. Анда кхмер халык эпосларыннан төзелгән концерт программасы да күңелгә хуш килерлек иде. Кызлар сыгылмалы бармаклары белән шундый классик па күрсәтteләр, кунаклар кычкыра-кычкыра алкышларга күмде. Биючеләргә балачактан ук сыгылмалылык күнекмәләре сеңдерелә икән, милли биюләрне матур башкарыр өчен озак еллар өйрәнергә кирәк, диделәр. Шуңа күрә кызларны һәм малайларны кечкенәдән, 5-6 яшьтән үк хореография мәктәпләренә бирәләр. Матур бию өстенә, алар үзләре дә бик матурлар. Гомумән, кхмерлар күрше илләрдә яшәүче вьетнам, лаос, тай халыкларыннан шактый аерыла.

Ангкор Ват, Байон, Та Прохм – әйтеп аңлаталмаслык гаҗәеп урыннар! Ли исемле кхмер кешесе безнең гид иде, ул изге Кайлас тауларының Камбоджадагы Ангкор Ват комплексы прототибы булуын сөйләде. Меру мифик тавын гәүдәләндерүче искиткеч биек манаралар, барельефлар белән бизәлгән затлы галереялар... Башка беркайда күрмисең боларны. Ангкор Ват комплексына керү юлындагы китапханә бин алары мине аеруча тәэсирләндерде. Биредәге китапханәләр борынгы заманнарда хатын-кызларныкына һәм ирләрнекенә бүленеп йөртелгән бит. Таң атканда – төньяк-көнчыгыш, кояш баеганда төньяк-көнбатыш манара итәгеннән Ангкор-Ватның үзәк манарасы шаһиналәрчә күренә! Без таң атканны каршыладык! Кояш акрын гына илаһи Ангкор манаралары ягыннан күтәрелде, суда гыйбадәтханә шәүләләре чагылды, чәчәктә утырган лотослар гына илаһи бер тынлыкта. Бу гүзәл күренештән таң калып, күпләр гыйбадәт кылды, кытайлар, гадәттәгечә, фотоаппаратларын черт тә черт китереп, кычкырып сөйләште.

Ангкор Ват һәм башка гыйбадәтханәләр комташтан һәм агачтан төзелгән. Шуңа күрә әлеге тарихи һәйкәлләрне саклау проблемасы да юк түгел. Комлы таш вакытлар узудан һәм джунглилар тәэсирендә акрынлап җимерелә, сугышлар барганда ул гыйбадәтханә ванда-

Еш кына Голливуд режиссерлары Ангкор Ват янында һәм джунглиларда фантастик фильмнар төшерә.



■ Ангкор Ват – индусларның Камбоджадагы гаҗәеп зур гыйбадәт комплексы, дөньяның иң атаклы археологик һәйкәлләреннән берсе XII гасырның беренче яртысында король Сурья-варман II идарә иткән чорда Вишну алласына табынып төзелгән.
Ангкор ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелгән.



лизмга дучар була: агач корылмалар бөтенләй диярлек сакланмаган. Әлеге гыйбадәт сарайларын XXI йөз башына кадәр җимергәннәр һәм талаганнар. Борынгы заманнарда индус аллаларының скульптуралары алтын һәм зиннәтле ташлар белән бизәлгән булган. Джунглилар ул зиннәтле сарайларны акрынлап йота барган. Куәтле агачлар таш корылмалар аркылы үсеп чыккан. Болары да фантастик фильмнарга декорация булырлык. Анджелина Джоли уйнаган «Лара Крофт расхитительница гробниц» фильмын нәкъ менә Камбоджада төшергәннәр инде. Камбоджа малаен актриса үзенә уллыкка алган.

Ангкор комплексы X–XII гасырларга карый. Заманында дөньяның иң зур шәһәрләреннән берсе була ул. Сарайларының даны кхмерлар империясеннән ерак-еракларга тарала. 1431 елда Сиам гаскәрләре шәһәрне тәмам тар-мар итә. Шуннан соң Ангкор һәм тагын йөздән артык сарай тропик урманнар ышыгында кала. Бу галимнәр фаразы, ләкин ни өчен кинәт кенә шаулап утырган шәһәр бушап калган, аның халкы кая китеп югалган? Фаразлар күптөрле. Берәүләр дини ызгышлар кешеләр китүгә сәбәп булган дисә, икенчеләр, Аллаһы Тәгалә кушуы буенча шулай эшләнгән, диләр. Дөресрәге, индуизм тарафдарлары Һиндстанга, тарихи ватаннарына киткән булырга тиеш.

Дөнья мәдәнияте өчен Ангкор Ватны француз сәяхәтчесе Анри Муо ача. Хәтта Редьярд Киплинг Маугли турындагы атаклы «Джунглилар китабы»н шушы урыннарны күреп кайткач язган, диләр.

Истәлеккә ни дә булса алып китәсем килде. Вьетнамга сәяхәтем вакытында өч көндә күлмәк тегеп кигән идем. Камбоджада вакытым да, андый теләгем дә булмады. Ангкор янындагы сувенирлар лавкасында актарына-эзләнә торгач, майлы буяулар белән ясалган Ангкор Ват пейзажына тап булдым. Картиналар бик күп иде, ләкин мин сайлаганы чын рәссам кулы белән эшләнгән, авторның имзасы да куелган, мул буяулары Винсент Ван Гогның яраткан стилендә импасто техникасы буенча ясалганын сиздереп тора.

Экскурсиядән соң ашыкмый гына машинабызга таба атладык, каршыга шулай ук ашыкмый гына маймыл көтүе килә иде. Джунгли хуҗаларына күз салмаска тырышып, тиз генә таю ягын карадык. Бу комплекста маймыллар үзләрен теләсә ничек тота: күп вакыт әрсезләнәләр, кайчак хәтта агрессивка да әйләнәләр. Кайберәүләр аларны сыйламакчы була. Киңәш итмәс идем. Маймыллар төркем белән яшәргә күнеккән, кәефләре кинәт үзгәрү шундук барысына да күчә, һәм гел көтелмәгән күңелсезлекләр килеп чыгуы бар. Киңәшем шул: маймылларга ел-маймагыз, аны алар янау дип кабул итәргә мөмкин. Аларны сыйламагыз, күзлек, фотоаппарат, телефон ише әйберләрегезне яшеребрәк куегыз. Маймыл «халкы» бик әрсез.

Ангкордан кайту юлында машина йөртүчедән җирле халык алачыгы янында туктавын сорадым: лотос орлыкларын аласым килгән иде. Тропик илләрдә ике тапкыр булдым инде, бу тылсымлы чәчәк орлыкларын һич сатып алалганым юк. Кхмер хатыннары инглизчә



Автор фотолары

белми, шуңа алар белән ишарәләр һәм пантомима ярдәмендә аңлашырга туры килде. Орлыкны алып, җиргә утыртып, аннан матур лотос чәчәге үсеп чыгуны кулларым белән төрле хәрәкәтләр ясап маташуларымны, ниләр кылануымны күрсәгез иде... Ниһаять, өченче тапкырында аңлап алып, авызларын ерып, «вандоллар» дип кабатлап, миңа үзем кызыккан орлыкларны сатып җибәрделәр. «Вандоллар» мәңге онытылмаслык булып хәтергә сеңеп калды...

Пол Потның канлы режимы һәм Вьетнам белән сугыш берничә ел элек Камбоджаны төрле кисәкләргә таркаткан. Пол Пот режимы милләтнең тәмам башына җиткән. Баш миенең фикерләү процессын юкка чыгарыр өчен, кешеләрне тимер мичкәләргә тыгып тәгәрәткәннәр, Бөек Ватан сугышы чорындагы сыман концлагерьларда җәзалаганнар. Юлбашчылары үз халкын юк иткән. Геноцид шул хәлгә китереп җиткергән: бүген теләсә кайсы кхмер берничә мәгълүматны берьюлы кабул итә дә алмый. Кхмерга эш кушканда эзлеклелекне сакларга кирәк, юкса ул берничә биремне исендә калдыра алмый. Күп нәрсә бүген дә әле шул куркыныч көннәрне искә төшереп тора. Гыйбадәтханә диварларындагы пуля эзләре, җирдә калган миналар... Кхмерлар үзләре җирдәге миналар илнең һәр гражданины на җитәрлек, ди. Сием Рип шәһәрендә бөтен инфраструктура туристларга исәпләнгән. Туристларга тәкъдим ителгәннәр белән кхмерлар тормышы арасында шундый контраст! Монысы шаккаттырды безне. Ә алар тормышларыннан бик канәгать үзләре.

Ли сөйләве буенча, Камбоджада матриархат бик көчле икән. Без дәррәү көлеп җибәрдек. Ә Ли бик җитди кыяфәттә Камбоджадагы традицияләр турында сөйли. Кхмер гаиләсендә әби кеше бөтенесенә – баш, дөресрәге, гаиләдә иң өлкән хатын-кыз идарә итә, еш кына ул кайнана яки хатынның әнисе булырга мөмкин. Ни гаҗәп, күп очракта хатынның әниләре командалык итә икән. Барысы да эшли, ә өйдәге акча әби кулында була. 70 яшьтән соң хатын-кызлар башларын такыр итеп кырдыралар: бердән, югары дымлылык өлкән яшьтә озын чәч йөртергә комачаулый, икенчедән, алар менә шулай будда монахлары кебек үзләренең Аллага якынаюларын күрсәтәләр.

Такыр башлы, кызгылт-сары киемле монахларны да очраттык. Ә Камбоджа хатын-кызларының барысының да чәче озын, кыскан чәч йөрүчеләр юк анда. Кхмерлар – миндальсыман күзләре белән аерылып тора, кытай, вьетнамнарныкы кебек кысык күзле түгел алар. Иреннәре кабарып тора, борын тишекләре итләч, үзләре, нигездә, индусларга охшаган.

Камбоджа кухнясы да ошады миңа. Тайларныкы кебек яндыра торган зәһәр түгел ул, ә аш тәмләткечләргә бай менә. Төп ризыклары дөге, әлбәттә. Иң шәп дөге нәкъ менә Камбоджада үстерелә, ә чимал буларак аны төрле илләргә чыгаралар. Эшкәрткәннән соң, ул илләр аны үзләренеке итеп сата. Шулай итеп, бу дөге Кытайга, Һиндстанга, Таиландка, Япониягә китеп бара. Иң атаклы һәм тәмле ясмин дөге Камбоджа үзәннәрендә үсә.

Кхмер кухнясының классик ризыгы лок-лак (соуста маринадланган ит), амок (кокос сөте һәм карри соусы кушып банан яфракларында пешерелгән балык) һәм тәмләткеч үләннәр салып пешерелгән ашлар. Экзотика яратучылар чикерткә белән бакадан әзерләнгән ризыкларны авыз итә ала.

Камбоджа, элеккеге исеме белән әйтсәк, Кампучия – контрастлар, традицияләр, яхшы күңеллелек, елмаюлар, борынгы гыйбадәтханәләр, ышаныч һәм мәхәббәт иле ул. Кхмерлар үзләренең үзенчәлекләрен югалтмасын, туристлардан акча суыру машинасына әйләнмәсен, гел шулай ягымлы һәм кунакчыл булып калсын иде. Ә без тагын килербез әле. Бер күрү генә җитми, ашыкмыйча, иркенләп, һәр мизгелдән тәм табып танышырга кирәк.

Текмерек соусы



Фото: www.pixabay.com

Сием Рипада борынны яра торган борыч җитештерүчеләр Текмерек соусы рецепты серләрен чишә.

Тигез өлешләрдә кызыл, ак, кара борыч (берәр чәй калагы), лайм яки 2 лимон согы, 4-5 аш кашыгы сойя соусы, берничә төш сарымсак алабыз. Барысын бергә блендерда болгатып, шешәләргә тутырабыз, суыткычка урнаштырабыз. Соусны төрле ашларга да кушып була, аеруча ит һәм балык ризыкларын тәмләтеп җибәрә ул.

PRESSA

«ТОРМЫШНЫ ИР-АТ ТАРТЫРГА ТИЕШ»



Вил УСМАНОВ, Татарстанның халык артисты, композитор;
гаилә стажы – 26 ел;
кызлары – Гөлгенә һәм Гөлнар.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Мин үзем башта хатын-кызның күзенә карыйм. Аның күзендә нур булырга тиеш дип саныйм. Гөлфиянең башта нәрсәсенә игътибар иттем икән? Хәзер инде хәтерләмим... Без бит бер авылда туып-үстек: ул гел күз алдында иде.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Күп сөйләшүендер... Хәер, моны ишетмәс өчен чыгып китәргә дә була. Озаклап телефоннан сөйләшүләренә дә түзәсең – анысы бит инде замана чире. Син шалтыраткан-да ул алмаса, бик ачу чыга инде без, ир-атларның: башка шунда ук төрле фикерләр килә башлый. Әмма соңыннан, бар да әйбәт икәнен аңлагач, әлбәттә, гафу итәсең, дөресрәге, онытасың. Чынлыкта – вак-төяк болар.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Моңа ир-ат кына түгел, хатын-кыз да бер үк җавапны бирер: иң авыры – якын кешеңнең сине алдавыдыр. Читләр сине төп башына утыртканда, аны әле аңларга, кичерергә була. Шуның өчен дә чит бит ул. Ә син ышанган, син якын иткән кеше бу адымга барса, әйткәнемчә, ир-ат та, хатын-кыз да гафу итә алмыйдыр. Еш кына хатын-кыз кичерә, диләр. Билгеле бер чиккә җиткәнче генәдер. Әйе, элегрәк хатын-кызлар ир-атның мондый ялгышын оныта белгән. Безнең әти-әниләр чорын гына алыйк. Мин хыянәт турында әйтмим әле бу очракта. Тормыш иткәндә әни һәрвакыт «кеше белмәсен», «гаиләдән чыкмасын», «бала-лар хакына» дип яшәде. Әти шактый кырыс кеше иде безнең. Әни кайчак: «Сиңа да әтиеңнән бу сыйфат эләккән, күрәсең», – дип әйтеп куя. Болай карап торуга без барыбыз да йомшак кебек анысы...

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Хуҗабикә, әлбәттә. Безнең тормыш шундыйрак – күбрәк юлда йөрелә. Бәлки шуңа да өйдә җылылык булу мөһимдер. Ә җырны аны төрле халәттә язарга була. Ул каяндыр килә, аны аңлатып та булмый. Җыр язган саен илһам эзләп, хисләнеп, кемгәдер гашыйк булып йөрсәң...

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Ир-ат белән хатын-кыз дус була аламы соң? Бик шикләнәм... Дуслар, гомумән, күп була алмый. Андый очраклар, бәлки, бардыр, тик алар миңгә бердер... Гаиләдә дә шулай. Нәрсә генә димә, хатын-кызның кечкенә генә булса да үз сере була. Ирнең – үзенеке. Кайбер дуска ачылып сөйли торган сүзеңне хатыныңа сөйли алмыйсың.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Гөлфия белән бер авылда үскәнне әйттем инде. Ул миннән дүрт яшькә кечерәк. Азрак күзгә күренә башлагач та игътибар иттем бугай мин аңа. Ул Алабуга педагогика институтын тәмамлаганда Казанда идем. Миңа 25 яшь. «Әйдә, өйләнешик», – дип бер-ике тапкыр әйтеп карадым. «Юк, әле чыга алмыйм. Бер-ике ел акча эшләп, азрак киенәсем килә», – диде. Эшкә ул үзебезгә – Баулыга, күрше Салих авылына кайтты. Ул вакытта әле мәктәптә берничә бала бар иде... Өйдә безнең аралашып, очрашып йөргәнне беләләр бит инде. Ул елны Баулыда көрәштә җиңеп, батыр калдым һәм бүләккә «алтылы» машина алган идем. Әти белән әни: «Бу малай машинага утырып Казанга чыгып китсә, моны өйләндереп булмас», – дип уйлады бугай. Бер кичне: «Башлы-күзле булырга исәбең бармы соң синең?» – дип сүз кузгаттылар. «Исәп бар да... Әле акча эшләргә кирәк, ди бит», – дим. Киенделәр дә: «Әйдә, машинаңны чыгар», – диләр. Кичкә таба кыз сорарга китеп бардык шулай. Гөлфияләр өендә беркем бернәрсә белми, әлбәттә. Август ае иде. Көтүләр кайткан, маллар ябылган. Без килеп кергәч, Гөлфия шок хәлендә калды бугай. Әтиләре әкрен генә йокларга җыенып йөри. Кереп утыргач, башта дөнья хәлләрен сөйләштеләр, аннан төп сүзгә күчтеләр. «Кызым, син ризамы соң?» – дип Гөлфиядән сорадылар. «Сез каршы килмәсәгез, мин риза», – диде ул.

Казанга инде икәү килдек. Мин әле училищеның II курсын гына тәмамлаган идем. Танышларның фатирларында тордык. Укысам да, хатын акчасына карап ятма-

дым, билгеле. Күрәшәм, әле анда, әле монда җиңәм, бүләкләр алам. Барып җырлап та кайтам. Үзебезчә шулай яшәргә тырыштык инде.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Тормышны, әлбәттә, ир кеше тартырга тиеш. Хатын-кыз ышыгында, хатын-кыз акчасына яшәгән ир-атны хөрмәт итмим. Бу хакта сүзне башка дәвам итмәсәк тә була.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Мин андыйлардан куркам. Әйе, булгалый... Тик алар бит безгә ир-ат дип түгел, күбрәк җырчы буларак игътибар итә, сәхнәдәге образыңа гашыйк була. Беренче адымны ир-ат ясарга тиеш дип саныйм. Әмма чынлыкта барыбер хатын-кыз сайлый. Без сайладык, дип уйлыйбыз гына. Тормыш шуны күрсәтә.

Булды, каяндыр өй телефонын табып, шалтыратучылар да булды. Нишлисең, гаилә шуның белән ныгый... Гөлфия моны ничек кабул итсен – күңләште. Ул бит кияүгә артистка чыкмады. Мин ул чакта күбрәк спортчы идем. Киләчәгемне сәхнәдә дип күз алдыма да китермәдем. Башкалар кебек, Казанга сәхнәгә менәргә дип тә килмәдем. Миңа Баулыда да бик рәхәт иде. Ул чакта кечкенә генә матур бистә иде. Туксанынчы еллар башы бу. Тренер-инструктор булып эшлим. Мәдәният йортына ярты ставкага баянчы итеп тә алдылар. Яхшы гына баянчылары да бар иде, ләкин салгаларга яраталар. Ә мин күрәшәм, андый нәрсәгә бөтенләй якын килмим. Баянда уйныйм, концертларда катнашам. Хәтта үземнең иҗат кичәмне уздырырга да өлгердем. Тик белем җитми. 23 яшьтә, бөтен нәрсәне ташлап, нота өйрәнергә дип I курска училищега кердем. 15-16 яшьлек кызлар-егетләр белән укып йөрдем. Белем алам, өйрәнәм дә кайтам дип килдем. Максат шундый иде. Ә сәхнәгә чыгу... Яшәргә кирәк иде бит. Балалар туды. Укыганда ук бер группа белән авылларга чыгып чыгыш ясый башладык. Кайдан шикәр комы, кайдан ит алып кайтабыз... Үзем дә сизмәстән сәнгать дөньясына кереп киттем шулай.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Минемчә, аңа үз сүзен әйтә алган, үз сүзендә торган ир-ат кирәк. Ышык урын... Хәер, хатын-кызның да төрлесе бар. Кемгәдер янындагы ир-ат бозау булса – әйбәтрәк. Көчле хатын-кыз көчле ир-ат белән уртак тел беркайчан таба алмый, алар бер-берсенә баш бирми. Ә тормышта береңә барыбер аз гына йомшаграк булырга кирәк.

10 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.

– Инәйнең менә өйдә җиһазны күчерергә ярата торган гадәте бар. Кайткан саен өстәл урыныннан күчкән була. Өй эчен үзгәртеп, үзенә ниндидер бер рәхәтлек таба бугай. Ул гомер буе авылда, шул бер өйдә яши бит – бертөрлелектән туямы икән соң? Ярый ла ул без гел урын алыштырып торабыз. Ә Гөлфия... Ачуы килсә, Гөлфия нигәдер берәр эшкә тотына. Йә кер, йә идән юа... Аңлап та, аңлатып та булмый бу гадәтен. Ә идәнне бик еш юа ул...

11 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Хатын-кыз үз туксаны – туксан дип уйлый икән, монда инде бернәрсә эшли алмыйсың. Азрак читкәрәк китәргә генә кала. Мин үземнең очрактан чыгып әйтәм... Әмма күпчелек ир-атлар шулай эшли дип беләм. Без гомер буе бер-беребезгә нәрсәдер исбатлыйбыз. Син – дөрес, мин – дөрес дип. Нигә кирәк ул? Бик күп гаиләләрдә шулай бит. Әллә замана чире инде ул? Элегрәк бер-берсенә йомшаграк булганнар кебек. Хәзер стресслар күп – кеше һәрвакыт ярсыган халәттә. Шуңа да бер-берсенә сүзне уйламыйча да әйтә бугай. Үзе моны сизми дә кала. Бераздан исенә төшә, уйлый башлый, әмма инде соң була: сүзне кире җыеп алып булмый. Ул инде теге кешенең күңеленә кереп урнашкан, үзенең «эшен» эшли башлаган...

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән.

– Хатын-кызның арый торган гадәте бар инде аның – моның белән тулысынча килешәм. Мин нишләп арымыйм икән, дип уйлап куям кайчак. Без дә арыйбыз, әлбәттә. Юл йөрүләр эзсез генә узмый... Хәзер бит кафелар чат саен – чыгып китеп, тамакны ялгап керергә дә була. Тик кайнар ризык әзер булмаса да, өйдә ашарга барыбер нәрсәдер табыла инде ул... Ә үзем нәрсәдер әзерләүгә килгәндә... Авылдан 15 яшьтә чыгып киткән идем, 25 яшькә кадәр үземне үзем ашатып, тәрбияләп яшәдем. Шуңа күрә өйләнгәннән соң: «Җитте», – дидем. Без, ир-атлар, теләсә нәрсәне пешерә алабыз анысы. Танышлар арасында да андыйлар байтак. Бер дус музыкант гастрольләрдә йөргәндә, янда хатын-кызлар булса да, аш-суга үзе тотына. Аңардан да тәмле пешерүче юк! Ул өйдә дә ашарга үзе әзерли һәм моңардан рәхәтлек ала. Ә мин – юк. Шуңа күрә пешерергә яратам дип әйтә алмыйм.

13 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан.

– Соңга калу ачуны китерә инде ул. Кем соңга калуга карамастан. Сәгать алтыда чыгып китәргә кирәк икән, мин биштә кузгалабыз, дим. Башкача моның белән көрәшеп булмый... Көтмичә китеп барган чаклар да булды. Гастрольгә чыкканда, музыкантларны да калдырып киткәнем бар. Вакытны бит алдан чамалыйсың: юлның ничә чакрым икәнен, сәгать ничәдә барып җитәргә тиешлегебезне, аппаратураны куярга, көйләргә күпме вакыт кирәген... Алдан сөйләшкән вакытка килмәгән кешеләр калды шулай. Үз җайлары белән безне куып тоттылар аннары. Тик башкаларга мондый таләп куйганчы, иң беренче чиратта син үзең соңга калмаска тиешсең. Бар да үзеңнән башлана.

14 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша...

– Ошый, ошамый дип караганым юк: минем өчен энә дә бүләк, дөя дә. Игътибар мөһимрәк: кочаклап, бит очыннан пәп итсәләр, шул җитә. Ә үзем бүләк бирергә ятаммы дисәгез... Мин алай нечкә күңелле, сентименталь кеше түгел шул, кырысрак... Бәйрәмнән тыш, болай гына нидер бүләк иткәнемне хәтерләмим.



Тулысынча сайтыбызда: www.syuyumbike.ru



Талпан кадалса

Җәй җитте. Хәтфә болыннар, яшел урманнар үзенә дәшә. Ел буена җитәрлек итеп кояш нурын сеңдереп, табигать энергиясеннән көч алып каласы килә. Әмма... җәйге болын безне җиләкләре, чәчәкләре белән генә түгел, талпаннары белән дә каршылый шул. Үзебезне дә, балаларыбызны да күңелсезлекләрдән саклар өчен, югары категорияле табиб-эпидемиолог, Республика балалар клиник хастаханәсенең эпидемиология бүлеге җитәкчесе, медицина фәннәре кандидаты Илсөя ФАЗЫЛҖАНОВА үзенең киңәшләрен бирә.

Көннәр җылыну белән, зарарлы бөҗәкләр дә активлаша, шуның белән бергә тәненә талпан кадалган пациентлар саны да күбәя. Әлеге бөҗәк, иң беренче чиратта, талпан энцефалиты, иксод талпан боррелиозлары (Лайм авыруы) таратучы буларак куркыныч.

Талпан энцефалитының беренче билгеләре гадәти салкын тию белән охшаш. Тик берничә көннән соң ул югары температура, бизгәк тоту, баш авырту, косасы килү белән алмашына. Еш кына галлюцинация, саташу, сөйләм һәм хәрәкәтләрнең аңлаешсызлыгы да күзәтелә. Талпан энцефалиты белән бер авырган кешедә бу чиргә карата ныклы иммунитет барлыкка килә, икенче юлы аңа бу чир инде янамый.

Талпан боррелиозының характерлы билгесе исә – бөҗәк тешләгән урында тиренең кызаруы. Кызыл тап акрынлап зурая бара. Берникадәр вакыттан соң аның үзәк өлеше агара яки зәңгәрләнеп тора, боҗра рәвешенә керә. Тиешле дәва булмаса, тәндәге бу тап ике-өч атна буе саклана, аннан үзеннән-үзе юкка чыга. Талпан энцефалиты белән чагыштырганда, Лайм авыруы күпкә ешрак очрый һәм ул хроник формага күчүе белән дә куркыныч.

Мондый күңелсезлеккә тарымас өчен, беренчедән, табигатькә чыкканда ачык кием кимәскә, чәчләрне җыярга, баш киеме кияргә кирәк. Икенчедән, 10-15 минут саен киемне, тәнне тикшереп тору да зыян итмәс.

Моны белү мөһим

- Табигатькә чыкканда баланы дөрес итеп киендерегез. Талпан астан өскә таба үрмәли, шуңа да баланың аяклары ялангач булмасын, чалбар балагын оекбашына, ә күлмәген чалбар керешенә кыстырыгыз.
- Киемнең шома тукымадан тегелгәнен һәм молния белән каптырылганын сайлау отышлырак.
- Күлмәк якасы муенга тыгыз булып ятып торсын.
- Өйгә кайткач, баланы чишендереп, тәнен җентекләп карагыз. Аеруча касыгын, корсагын, култык астын, чәч төпләрен җентекләп тикшерегез.
- Урман яки болынга барыр алдыннан киемгә берәр төрле репеллент сиптерү дә яхшы нәтиҗә бирә.

Өйгә кайткач, өс киемнәрен салып селкергә һәм душта коенып чыгарга киңәш ителә. Шулай ук эт-мәчеләрегезне дә тикшереп торыгыз.

Талпан тешләгән очракта, иң дөресе – медицина учреждениесенә мөрәҗәгать итү. Андый мөмкинлек булмаса, бөҗәкне тәннән үзеңә алырга туры килә. Моның өчен талпанны чиста марля аша кул яки пинцет ярдәмендә кадалган урынга перпендикуляр итеп тотып, гәүдәсе тирәли сак кына боргалыйлар. Каты итеп тартырга кирәкми, башы өзелеп калмасын. Тәннең бөҗәк тешләгән урыны берәр төрле антисептик белән эшкәртелә (70 процентлы спирт, 5 процентлы йод, 3 процентлы водород перекисе), кулларны сабынлап юарга кирәк. Әгәр дә тиредә кара төртке булып бөҗәкнең башы яки борыны өзелеп калса, ул урынга йод сөртелә.

Тәннән алынган талпан 42 сәгать эчендә өсте ябык контейнерда лабораториягә тикшерергә китерелергә тиеш. Куркыныч авыру тудыра торган инфекциянең булуы ачыкланган очракта дәва курсы билгеләнә. Талпанда энцефалит инфекциясе табылса – иммуноглобулин, боррелиоз очрагында антибиотиклар кабул итми булмый.

Игътибар

Талпаннар Татарстан Республикасының Гигиена һәм эпидемиология үзәге лабораториясендә тикшерелә. Адресы: Казан шәһәре, Сеченов урамы, 13 нче а йорт. Эш вакыты: 9.00–17.00; ял һәм бәйрәм көннәрендә 9.00–16.00. Төшке аш вакыты – 12.00–13.00. Нәтиҗәне 221-79-05 телефоны буенча белешергә мөмкин.

Аналык төшү



Әлеге диагноз күпләребезгә таныш. Ул – хатын-кызлар арасында бик киң таралган проблема. Аналык төшү турында, аны дәвалау ысуллары хакында медицина фәннәре кандидаты, югары категорияле онколог-гинеколог Гөлшат ХӘМИТОВА белән сөйләшәбез.

Халык телендә «аналык төшү» дип йөртелсә дә, дөресе – аналык җиңсәсе проллапсы. Аналык үзеннән-үзе килеп төшми, ә мускуллар зәгыйфьлеге аркасында баштарак аналык җиңсәсенең алгы яки арткы стенасы төшә. Кайчак ике стена берьюлы да төшәргә мөмкин. Аналык җиңсәсе, үз чиратында, янәшә әгъзаларны – сидек куыгын, туры эчәкне, аналыкны да тартып төшерә. Аналык җиңсәсе проллапсы бала тапкан яки гомере буе бик авыр күтәреп эшләгән хатын-кызларда очрый.

Төп сәбәбе: бала тапканда аналык җиңсәсенең ертылуы, баланың артык зур булып тууы, бала тапкан хатын-кызның үзен сакламавы, чамасыз авыр йөк күтәрүе.

Аналык җиңсәсенең төшүе берничә стадиядә була.

1-2 нче стадиядә хатын-кыз җиңелчә дискомфорт тоя. Җенси якынлык вакытында бертөрле үзенчәлекле тавыш чыгарга мөмкин. Төчкергәндә, көлгәндә бәвелне тота алмау күзәтелә.

3 нче стадиядә аналык җиңсәсе зур җенес иреннәреннән күренеп тора башлый. Эчке киемгә гел ышкылып йөреп, ул каный, әрни. Төрле инфекцияләр килеп кушылып, ялкынсынулар башланырга мөмкин. Хатын-кыз анатомиясе буенча, җенес иреннәре аналык юлын тулысынча каплап торырга тиеш.

4 нче стадиягә китереп җиткергән очракта инде аналык үзе килеп төшә. Аның белән бергә башка органнар да урыныннан куба. Хатын-кызга кече йомышын йомышлау кыенлаша. Аналыкның эчке киемгә гел ышкылып йөреп җәрәхәтләнүе аркасында хәтта яман шеш тә килеп чыгарга мөмкин.

Әлеге проблема дарулар белән дәваланмый. 1-2 нче стадиядә аналык юлы мускулларын ныгыта торган күнегүләр яхшы нәтиҗә бирә. «Кегель күнегүләре» дип атала ул. Шуның ярдәмендә 1 нче стадиядәге аналык җиңсәсе проллапсыннан тулысынча арынып була. Аны бала тапканнан соң бер атна үтүгә ясый башларга киңәш ителә. Ул бик гади генә: арт юлны күтәреп, җиңсә мускулларын киеренке халәттә берничә минут тотарга, аннары җибәрергә. Көн дәвамында берничә тапкыр кабатларга.

Соңгы стадияләрдә инде операциясез булмый. Мин аны яшь ханымнарга хәтта 2 нче стадиядә булганда да ясарга киңәш итәм, чөнки яшь вакытта, әле мускуллар ныграк чакта күзәтелгән аналык җиңсәсе проллапсы, өлкәнәйгәч, катлаулы форма ала. Аналык үзе дә килеп төшкән очракта аны алып ташларга туры киләчәк. Операцияне күтәрә алмаучы пациентларга силиконнан ясалган писсария тәкъдим ителә. Ул аналык җиңсәсенә урнаштырылып, аның төшүенә юл куймый.

ТАБИБ КИҢӘШ ИТӘ

- Хатын-кызга 10 кг кадәр генә күтәрергә рөхсәт ителә.
- Баладан котылгач, 5 кг артыграк күтәрергә ярамый.
- «Кегель күнегүләре»н ясауны гадәткә кертегез. Мускулларның эшләп торганда гына тонуста булуын онытмагыз.
- Артык авырлыктан арыныгыз. Май катламы күп итеп гормоннар җитештерә, ә бу исә гормоннарга бәйле яман шеш китереп чыгарырга мөмкин.
- Елга бер тапкыр гинекологка күренеп торыгыз.



ПРОФИЛАКТИКА ОНКОЛОГИЧЕСКИХ ЗАБОЛЕВАНИЙ

**Основное направление клиники – профилактика онкологических заболеваний.
Нами разработаны оптимальные программы ежегодного обследования мужчин и женщин, направленные на раннее выявление начальных стадий онко-патологии, с целью своевременного начала лечения.**

Комплекс «Женский онкоскрининг»
- Консультация гинеколога
- Мазок на степень чистоты и онкоцитологию
- УЗИ органов малого таза
- Консультация онколога-маммолога
- УЗИ молочных желез
- Забор крови + анализ на онкомаркеры (СА-125, СА-15-3, СА-19-9, СА-72-4, SCC, АФП, РЭА)

Казань, Сибирский тракт, 23. Тел.: 8 (843) 215-00-03.
Часы приема: пн.-пт. с 8.00 до 20.00; суббота: с 9.00 до 18.00; воскресенье – выходной.

Лицензия: ЛО-16-01-006069 от 13 июня 2017 года.

РЕКЛАМА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

PRESSA

Мцвади – грузин шашлыгы



«Һәрбер кунак Аллаһының бүләге, ә чын дустың булмау – йөрәгең булмауга тиң», – ди грузиннар. Ә кунакчыллыкка килгәндә, грузин дустыгыз кунакка чакыра икән, баш тарту хөрмәт итмәү буларак бәяләнә. Туйга чакыруны кире каккан өчен генә дә гомерлек дошман булып калучылар да бар икән. Гомумән, грузин туйлары – аерым бер тема. Ике яктан да бөтен туган-тумачаны чакырып, зурлап уздыралар аны. Туй йолаларының иң кызыгы – кыз урлау. Кызның үзе белән дә, әти-әнисе белән дә алдан килешенеп кенә башкарыла ул. Кәләш кияү йортына аяк атлап керүгә, егет, түбәгә менеп, ак кош очырырга тиеш. Гомер буе җитеш тормышта яшәсен өчен кәләш өстенә йөзем һәм дөге сибәләр.
Грузин теле өйрәнү өчен иң җиңел телләрдән санала. Бездәге кебек, аларда да род төшенчәсе юк. Читтән карап торганда грузиннар үзара кычкырыша, бер-берсенә тавыш күтәрә кебек тоела. Бу да тел үзенчәлеге белән бәйле. Басым булмаганлыктан, төп авазны алар интонацияне күтәреп белдерә.
3 март – Грузиядә Ана көне буларак билгеләп үтелә. Хәер, ватаннарыннан читтә яшәүче грузиннар да бәйрәм итә аны. Бер генә бәйрәм дә супра – мул табынсыз үтми. Табынга һәрвакыт йөзем шәрабы куела.
Грузин кухнясы шулай ук борынгы һәм бай кухнялардан санала.
Табын түрендә, әлбәттә, икмәк – пури. Сыр кушып пешерелгән хачапурины авыз итми калган кеше бармы икән? Ә чакапули (слива белән томалап пешерелгән ит), харчо (кырку аш), чашушули, чурчхела, чирилар... Шулай да, грузин кухнясы диюгә, күз алдына иң элек мцвади – шашлык килеп баса. Шампурларга элеп, кайнар күмер өстендә пешергәне, авызда эреп китә торганы. Менә шундый шашлыкны пешерергә грузин ресторанының шеф-повары Рома МАИСУРАДЗЕ өйрәтәчәк.



Кирәк

- 1 кг сөяксез ит;
- 1 баш суган;
- 1 лимон;
- 1 тырнак сарымсак;
- 20 г тоз;
- тәменчә кара борыч;
- 20 г үсемлек мае;
- бер тотам кинза;
- 1 стакан ак шәраб. Шәраб урынына анар (гранат), лимон, виноград суты кулланырга була. Без нәкъ шулай иттек тә.













Фото: Анна Арахамия

Эш барышы

■ Итне эре, әмма юка итеп турыйбыз. Кисәкләрнең зурлыгы чама белән 10 см : 10 см, ә калынлыгы 1 см тирәсе.

■ Итне тирән савытка салып, тоз, борыч сибәбез, үсемлек мае тамызып, кул белән баскалап, тозны иткә сеңдерәбез.

■ Ваклап туралган кинза белән сарымсакны, ярым боҗралап туралган суганны кушабыз, лимонның сутын сыгып, яхшылап болгатабыз.

■ Шәраб урынына бер стакан анар суты салып, итне 12–13 сәгать маринадлыйбыз.

■ Әгәр дә шашлыкны яшь бәрән итеннән ясарга булсагыз, аңа тоз һәм борыч кына сибелә, башка төрле тәмләткечләр дә, итне маринадлап тору да кирәкми.

■ Маринадтан алган итне шампурларга кидереп, утлы күмер өстендә 20–30 минут кыздырабыз.

■ Рома Маисурадзе бер серне ачты: күмер ялкынлана башласа, аны тоз яки тозлы су белән генә сүндерергә ярый. Гади су сипсәң, күмернең кызуы сүрелә.

■ Әзер шашлыкны анар төше һәм туралган суган, помидор белән бизәп, кайнар килеш табынга чыгарабыз. Янына сливадан әзерләнгән ткемали яки томаттан әзерләнгән сацебели соусы белән тәкъдим ителә.

■ Ашларыгыз тәмле булсын!

Мастре-классны оештыруда ярдәм иткәннәре өчен Татарстан халыкларының Дуслык йортына рәхмәт белдерәбез.

Сациви



Фото: www.pixabay.com

Чикләвекле соуста пешерелгән тавык ите – грузин кухнясында иң популяр ризыкларның берсе. Дарчин, канәфер, шафран әлеге ризыкка үзенчәлекле тәм биреп, аны чын грузин ашы итә. Гадәттә, Грузиядә әлеге ризыкны бәйрәмгә әзерлиләр.

Кирәк:

• 1 тавык;
• 4–5 баш суган;
• ярты баш сарымсак;
• 1 тотам кинза;
• 1 аш кашыгы гранат суты яки шәраб серкәсе (винный уксус);
• 1 аш кашыгы төелгән кориандр;
• 1 аш кашыгы шафран;
• бер чеметем корица;
• тоз-борыч;
• суган кыздырыр өчен атланмай.

Эш барышы:

■ Тавыкны пешереп, шулпасын сөзәбез. Суганны вак итеп турап, үтә күренмәлегә әйләнгәнче кыздырабыз. Кинзаны ваклап турыйбыз.

■ Чикләвекне иттарткыч аша чыгарабыз яки комбайн белән ваклатабыз. Канәферне төябез. Сарымсакны вак угычтан уабыз. Барлык тәмләткечләрне дә чикләвек белән кушып, бер аш чүмече шулпа өстәп, туглыйбыз. Ул сыек ботка кебек булырга тиеш.

■ Калган шулпаны (1,2–1,5 литр) кабаттан кайнатып чыгарабыз һәм болгата-болгата чикләвекне өстибез. Өстен каплап, берничә минут пешерәбез. Аннары кыздырылган суганны, пешкән тавык итен салабыз, шәраб серкәсен кушабыз, тоз-борыч сибәбез. Биш минуттан аш әзер!



Фото: Камилә Димөхәммәтова

Баллы тәм-том кулланудан күбебезнең коты алынып тора. Зарарлы углеводларның фигурага нәфислек өстәмәвен беләбез. Әмма Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА тәкъдим иткән бу десерт белән үзегез дә, балаларыгыз да рәхәтләнеп сыйлана аласыз.

Файдалы десерт

Бу десертның төп ингредиенты – чиа орлыгы. Ул – иң файдалы ризыкларның берсе. Майя кабиләсе халкы һәм борынгы ацтеклар аның үзлекләрен әле шул чорда ук тиешенчә бәяләгән. «Чиа» сүзенең борынгы майа теленнән «көч» дип тәрҗемә ителүе дә юкка гына түгелдер. Ул кальций, марганец, магний, фосфор, B_3, B_1, B_2 витаминнарына, калий һәм цинкка бай. Аны боткага, йогыртка, смузиларга кушарга, суда яки сөттә җебетеп, дерелдәвек хәлендә кулланырга була. Суга салгач, бүртә ул. Безнең десерт та чиа орлыгының шул үзенчәлегенә нигезләнеп әзерләнә.

Организм өстәмә тукландыруга мохтаҗ булса, чиа орлыгын көн саен кулланырга кирәк. Моның өчен 250 мл чәйгә 1 чәй кашыгы орлык салып туглагыз да, сәламәтлек өстәүче коктейль белән рәхәтләнеп сыйланыгыз.

Кирәк

- 200 мл сыер яки үсемлек сөте;
- 4 аш кашыгы чиа орлыгы;
- үзегез яраткан җиләк-җимеш.

Эш барышы

■ Сөткә чиа орлыгын салып, яхшылап туглыйбыз. Мин 1 стакан сөткә 4 аш кашыгы орлык салам, ләкин күләм нисбәте якынча гына. Кемдер куерак, кемдер сыеграк булганын ярата. Беренче тапкырдан куерак чыкса, икенче тапкыр үзегезгә кирәгенчә генә салырсыз.

■ Стаканны суыткычка урнаштырабыз, сөт куерсын. Чама белән моңа 5 сәгатькә якын вакыт кирәк. Төнгә куеп калдырсаң кулай, иртәнгә инде әзер булачак.

■ Ә хәзер фантазияне эшкә җигеп, десертны әзерләп бетерәбез. Үтә күренмәле зур бокалга туралган төрле җиләк-җимешләр белән дерелдәвекне катлам-катлам итеп матурлап салабыз. Мин исә банан, издерелгән кура җиләге (аның урынына кара бөрлегән), аз калорияле манго җемы һәм миндаль кулландым.

Чиа орлыгын куллану өчен биш сәбәп

■ Теләсә кайсы бөртекле культура белән чагыштырганда, чиа орлыгындагы аксым ике тапкыр, банан йомшагы белән чагыштырганда калий ике тапкыр, ә сөт ризыклары белән чагыштырганда кальций биш тапкырга артыграк.

■ Чиа орлыгы – иммунитетны ныгыту һәм яшьлекне озайту өчен мөһим булган антиоксидантлар чыганагы.

■ Туклыклы чиа орлыгы аппетитны баса һәм организмны чистарта, шул рәвешле артык авырлыктан арынырга ярдәм итә.

■ Ул югары кан басымын төшерергә булыша һәм кандагы шикәр күләмен көйли.

■ Бу ризык организм өчен бик файдалы булган омега-3 һәм омега-6 май кислоталарына бай.

Кучкар. Гадәттәгечә, бу айда да эш белән мәшгульсез, шуңа да аның үткәнен сизми дә калырсыз. Нindидер чыгым булыр кебек фаразлана. Әмма ул файдалы чыгым, соңыннан кереме мул булыр.

Үгезбозау. Куанычлы вакыйгалар белән тулы ай көтелә. Дуслар, туганнар белән очрашырсыз. Күңелегез яңалыкка, үзгәрешкә тартылыр. Бераз үҗәтрәк һәм кыюрак булыгыз, барысына да ирешерсез.

Игезәкләр. Тышкы дөньяга түгел, эчке кичерешләрегезгә күбрәк игътибар итегез. Күп кенә сорауларга җавапны сез нәкъ үз күңелегездә табарсыз. Абруегыз финанс якны җайларга ярдәм итәр.

Кысла. Актив ай. Яңа дуслар, фикердәшләр табарсыз. Йөргән аякка җим иярә гыйбарәсе бу айда сезгә атап әйтелгән кебек: шәп тәкъдим кабул итәрсез, баш тартмагыз, ахыры хәерле булачак.

Арыслан. Һөнәри өлкәдә уңыш күренә. Тышкы кыяфәтегезне кайгырту да комачауламас, ул сезгә өстәмә көч һәм үз-үзегезгә ышаныч өстәр. Зур әйберләр сатып алу, зур эшләр башлау өчен яхшы вакыт.

Сөмбелә. Дөньяга карашларыгызны үзгәртә торган ай. Яңа белем алу, яңа шөгыль табу өчен уңышлы чор. Өстәвенә, күңелле яллар да көтелә. Вакыйгаларны ашыктырмагыз, бар да үз җаена барса, яхшырак булыр.

Бизмән. Ашыгудан сак булыгыз, эчке энергиягез гел әйдәкләп торса да, ашыгулар урынсыз. Якыннарыгыз белән мөнәсәбәтләр моңарчы күрелмәгән җылылык белән өртелер, ә бу исә күңелегезне канатландырыр.

Чаян. Тирә-юньдәгеләрне кирәгеннән артык туры сүз белән гаҗәпкә калдырырсыз. Нindидер катлаулы эшкә алынырга ниятләсәгез, айның урталарын сайлагыз, бу – сезнең өчен кулай көннәр.

Укчы. Эштә активлыгыгыз артыр, шуның белән бергә уңышларыгыз да күбәер. Иң мөһиме: коллегаларыгыз янында телегезне тешләп кала белегез. Бар энергиягезне эшкә юнәлтсәгез, нәтиҗәсе озак көттермәс.

Кәҗәмөгез. Күңелле очрашулар, яңа танышулар чоры. Ай дәвамында романтик кәефтә йөрерсез. Ай азагында сәфәр чыгу ихтималы зур. Ялгыз Кәҗәмөгезләр үз парын табар.

Сукояр. Тормышыгызга уңайлыклар өсти торган чор. Йортыгызга, фатирыгызга ремонт ясар өчен кулай вакыт. Инициативаны үз кулыгыздан ычкындырмасагыз, бар да сез теләгәнчә булыр.

Балык. Сезне юллар көтә. Ул ерак илләр дә, якын җирләр дә булырга мөмкин. Яңа танышлар булдыру өчен әйбәт чор. Гомумән, июль ае романтикага төренгән. Үз фикерегезне якларга туры килер.

АТА-АНА МӘХӘББӘТЕ

Бер гаиләнең бердәнбер уллары булган. Мәктәпне тәмамлагач, егет башкалага белем алырга чыгып киткән. «Мин укып бетердем, яхшы эшкә урнаштым», – дип, әти-әнисенә нибары бер хат язып салган ул. Шуннан бирле аннан бер хәбәр дә килмәгән, үзе дә кайтып күренмәгән. Әти-әнисе аны көтеп картайган. Карашларын көн дә күккә төбәп, көнбатышны – уллары яшәгән тарафларны күзәткән алар. «Бүген күк аяз, улыбызның бар да яхшыдыр», – дип куанган әнисе. Күк йөзе болытлы булса, картлар да хафага төшкән: «Балабызның берәр хәсрәте бар микән әллә?» – дип кайгырышканнар.

Аларның вафатыннан соң гына кайткан уллары. «Сине шулкадәр көттеләр. Икесе дә күзләрен күктән алмады», – дигән күршеләре. «Күккә карау ник кирәк булды икән?» – дип гаҗәпләнгән ир. «Әти-әниеңнең мәхәббәтен аңлар өчен, үзеңә дә бала үстереп карарга кирәк шул», – дигән кемдер. «Минем дә улым үсә. Ләкин андый юләрлек белән шөгыльләнмим инде», – дип җавап кайтарган ул. Еллар үткән. Бу ирнең дә бердәнбер улы китеп югалган. Аны бик сагынганда улы белән бергәләп утырткан агач янына килгән ата кеше. «Әле ярый сине утыртканбыз, – дип, агачның кытыршы кайрысын сыйпаган ул. – Кичә ботагың сынганны күреп, улыма берәр нәрсә булдымы дип бик борчылдым. Бүген әнә яфракларың бик күңелле леперди, баламның хәлләре яхшыдыр...»

* * *

Җир йөзендә бала бытылдавыннан да тантаналырак гимн юк.

Виктор Гюго (француз язучысы)

Гомер кыска, ләкин балалар аны тагын бер кат яшәргә мөмкинлек бирә.

Анатоль Франс (француз язучысы)

Балаларны яхшы кешеләр итеп үстерүнең иң шәп ысулы – аларны бәхетле итү.

Оскар Уайльд (инглиз язучысы)

Кырыкка җиткәндә бүлмәң балалар чыр-чуына күмелмәсә, ул авыр тойгылар белән тула.

Шарль Сент-Бев (француз язучысы, тәнкыйтьче)

Без балаларга үз белемнәребезне бирергә телибез, ләкин аннан да бигрәк, үз мавыгуларыбызны тагарга омтылабыз.

Шарль Монтескье (француз философы)

Балаларыгызның күз яшен саклагыз, алар әле каберегез өстенә кояр өчен дә кирәк булачак.

Пифагор (борынгы грек философы, математик)

Хаталарың өчен балаларың түләвен белүдән дә зур җәза юк.

Уильям Самнер (Америка социологы)

Балалар хезмәтне – куанычлы, уңышсызлыкларны – түзәрлек, тормышны – ямьле, ә үлемне куркынычсызрак итә.

Фрэнсис Бэкон (инглиз галиме)

зирәк кешедән зирәк сүз

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен әзерләүче – Лилия ГӘРӘЕВА







Әкият, хыял, иҗат дөньясы

Казандагы 2 нче балалар сәнгать мәктәбе оешуга быел инде 60 ел була. Шул дәвер эчендә 3 мең ярым бала биредә матурлыкны танырга өйрәнә, сынлы сәнгать, архитектура, мәдәният, мәгариф өлкәсендә үз урынын таба. Араларында Халык рәссамнары, Республиканың атказанган сәнгать эшлеклеләре, мәдәният хезмәткәрләре күпме! Александр Иншаков, Зөфәр Гыймаев, Мәхмүт Ваһапов, Илгизәр Самакаев, Әлфия Җәмилова, Наталья Тишенкова, Наҗия Галләмовалар... Әлеге мәктәп турында күп нәрсәләр сөйләп булыр иде. Укучылар шигърият, театр, бию, кино сынлы сәнгать дөньясында кайнап яши. Сүз уңаеннан, талантлы рәссам, «Сөембикә» журналындагы әдәби әсәрләрне бизәүче Наталья Васильева да биредә укыта...

Мәктәпне тәмамлаучылар барысы да рәссам йә дизайнер да булып бетми, әлбәттә, әмма һичшиксез олы йөрәкле, зәвыклы кешеләр чыгачак алардан. Сәнгать мәктәбенең директоры Жанна Зиннәтулла кызы Шаһидуллина – үзе дә максатчан, җаваплы, чын профессионал булган лидер – әнә шундый фикердә. Казан шәһәренең Ибраһимов проспектына урнашкан әлеге сәнгать мәктәбен күп әти-әниләр, рәсем ясарга һәвәс балалар үз итә икән, димәк, тикмәгә түгел.

Төрле хәйрия акцияләрендә, ярминкәләрдә катнашулар, шәһәр күләмендә үткәрелгән рәсем конкурсларындагы җиңүләр, Казан мэры стипендиатлары булулар...

2018 елда балалар сәнгать мәктәбе укучылары Анжела Вавилова исемендәге фонд белән берлектә искиткеч сувенир-календарь иҗат итә. Антуан де Сент-Экзюпериның «Нәни принц» әсәренә ясалган иллюстрацияләрдән исә яктылык, ихласлык бөркелә.


«Күренекле педагог Василий Сухомлинскийның, балалар матурлык, уеннар, әкият, музыка, рәсем, фантазия, хыял, иҗат дөньясында яшәргә тиеш, дигән сүзләре безнең өчен кагыйдә булып тора», – ди уку-укыту эшләре бүлеге мөдире Лилия Рифкать кызы Әхмәдиева.

Укучыларының эшләренә генә күз салыгыз! Төсләр балкышы, әкият дөньясы, самимилек, киңлек, иркенлек... Миллилекне дә, гаилә җылысын да, җиңелчә юморны да абайлап аласың ул сурәтләрдән.

...Класс бүлмәсендә тып-тын. Тәрәзәдән елмайган кояш, җилдә йөгерешкән чәчәкләр, лепердәшеп утырган яшел яфраклар үзләре үк иҗат итәргә булыша кебек. Кызлар-малайлар, хыял канатларында ерак-еракларга очып, этюдларына текәлгән. «Тик икәү без: уй да мин генә» менә шушы илаһи мизгелләрдер инде. Күңелдә яңгыраган музыка, моңлы көйләр, балачак әкиятләре җете төсләрне сайлаша. Яшеле – болын төсендә, зәңгәре – һаваныкы, алсуы – таңнардан, кызылы – шәфәкъныкы... Кемдер салкын тоннар сайлый, кемдер – җылыны... Һәм киң болында томырылып атлар чаба башлый! Мәһабәт булып Казан Кремле калка! Тукай әкиятләре күз алдында җанлана! Су анасы, Шүрәле, Кисекбашлар каршыңа чыгып баса...

Ә менә бер рәсемдә ике әби чөкердәшеп чәй эчеп утыра. Калфаклары, бәби итәкле күлмәкләре ничек килешә үзләренә. Тәрәзәдән мәчет манарасы шәйләнә. Диварга шәмаилләр эленгән. Самавырлары җырлап торадыр инде. Табында чәкчәк, гөбәдия, өчпочмаклар... Рәсемдәге сары төсләр тынычландыра, җылыта, үзенә бер рәхәтлек бирә. Нәкъ өйдәге кебек!

Эльмира ЗАКИРОВА














Фото: Анна Арахамия





**«Почта России»ның «Подписные издания»
(ПАП) рәсми каталогы буенча
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ИНДЕКСЫ П2204**

**Татарстаннан читтә яшәүчеләр
әлегә «Роспечать» каталогындагы
элеккеге индекс буенча язылa алалар 73002**

**яртыеллыка язылырга өлгерми калучылар
һәр айның 15 нә кадәр язылып,
журналны киләсе айдан алдыра ала**



Сайтта: www.syuyumbike.ru
ВКонтактеда: vk.com/suumbike
Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike
Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal

**Журналыбызга онлайн режимда :
http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып)
язылырга мөмкин**



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була.
iPad һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була.

16+

РЕКЛАМА